АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
им. Г. ИБРАГИМОВА

**О.Р. Хисамов**

# ОЙКОНИМИЯ ЗАПАДНОГО ЗАКАМЬЯ ТАТАРСТАНА

Казань
2017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**О.Р. Хисамов**

# ТАТАРСТАННЫҢ КӨНБАТЫШ КАМА АРЪЯГЫ ОЙКОНИМИЯСЕ

Казан
2017

**УДК 811.512.145´373**
**ББК 81.2Тат-3**
**Х 51**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Фәнни редактор**
филология фәннәре докторы, профессор **Г.Ф. Саттаров**

**Рецензентлар:**
филология фәннәре кандидаты, доцент **Г.К. Һадиева,**
филология фәннәре кандидаты **Г.С. Хаҗиева-Демирбаш**

**Хисамов О.Р.**
**Х 51** **Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы ойконимиясе** / Олег Ришатович Хисамов. – Казан: ТӘhСИ, 2017. – 176 б.
ISBN 978-5-93091-223-4

Монографиядә Татарстан Республикасының Көнбатыш Кама аръягындагы татар авылларының атамалары тарихи-лингвистик яктан анализлана. Авыл атамаларын топонимика фәнендә ойконим дигән термин белән атыйлар. Ойконимнарда күптән онытылган сүзләр, формалар саклана. Алар безгә халык, аның тарихы, мәдәнияте, теле турында кыйммәтле мәгълүмат җиткерәләр. Ойконимнарны тарихи – лингвистик яссылыкта анализлау, шулай ук, татар халкының килеп чыгышы мәсьәләләренә ачыклык кертергә дә булыша.

Хезмәт галимнәргә, аспирантларга, студентларга, туган як тарихы белән кызыксынучыларга адреслана.

**УДК 811.512.145´373**
**ББК 81.2Тат-3**

**ISBN 978-5-93091-223-4**

© Хисамов О.Р., 2017
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2017

# КЕРЕШ

Топонимнарның бер өлеше булган ойконимнарны өйрәнү зарурлыгы, актуальлеге шик тудырмый, чөнки дөрес лингвистик нәтиҗәләр ясау өчен телнең сүзлек составының барлык элементларын да, өлешләрен дә өйрәнергә, тикшерергә кирәк. Нәкъ менә ойконимнарда күптән онытылган сүзләр, формалар саклана. Алар безгә халык, аның тарихы, мәдәнияте, теле турында искиткеч кыйммәтле мәгълүмат җиткерәләр. Шулай булгач, ойконимнарны тирән итеп өйрәнү күп кенә фән тармаклары өчен дә файдалы.

Татарстанның Көнбатыш Кама арьягы ойконимнары монографик планда махсус рәвештә тикшерелмәгәннәр. Күпмедер күләмдә генә алар Г.Ф. Саттаров, Ф.Г. Гарипова, Р.И. Куряева хезмәтләрендә чагылыш табалар. Ләкин нәкъ менә шушы регионны гына фәнни рәвештә комплекслы итеп, тарихи-лингвистик планда тикшерү үткәрелмәде. Мондый тикшерү безгә географик атамаларның үсеш-үзгәреш закончалыкларын өйрәнү мөмкинлеге тудыра, ойконимнарның лексикага карый торган башка тармаклар белән бәйләнешен ачык күрсәтә. Татар теле тарихының башка, билгесез якларын өйрәнүгә өстәмә материаллар да бирә.

Ойконимнарны тарихи-лингвистик яссылыкта анализлау татар халкының килеп чыгышы мәсьәләләренә ачыклык кертергә дә булыша.

Тикшерү объекты итеп нәкъ менә Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы ойконимнары алыну бу өлкәне ойконимик яктан тикшерүнең фәнни ихтыяҗы барлыгы белән аңлатыла. Дөресен әйткәндә, мондый тикшеренүләр татарлар яшәгән бөтен регионнарда алып барылырга тиеш. Шуннан соң гына, лексиканың башка тармаклары мәгълүматларын да кушып, лингвистик һәм тарихи яктан берникадәр гомуми нәтиҗәләргә килә алабыз.

Кама елгасының Казаннан аръяктагы, ягъни сулъяктагы территориясе «Кама аръягы» дип атала һәм республикабызның иң зур өлешен били. Татарстан районнарының егермесе Кама аръягына урнашкан.

Тау ягы татарлары Кама аръягы территориясен, анда тигез далалы сөрү җирләре – кырлар күп булудан чыгып, «Кыр ягы» дип йөртәләр.

Шушы «Кыр ягы»ның көнбатыш территориясенә Аксубай, Алексеев, Әлки, Яңа Чишмә, Норлат, Спас, Чирмешән, Чистай районнары керә. Бу шактый зур территория.

Аксубай районы җирлегендә 85 торак пункт бар. Аларда 33 мең 200 кеше яши. Алексеев районында 59 торак пункт бар, 23 мең 400 кеше яши. Әлки районында 73 торак пункт бар, 23 мең 400 кеше яши. Яңа Чишмә районы территориясендә 33 торак пункт, 1 мең 315 кеше яши. Норлат районындагы 92 торак пунктта 55 мең 100 кеше яши. Спас районы территориясендә 48 торак пункт бар, 23 мең 200 кеше яши. Чирмешән районы территориясендә 51 торак пункт бар, 1 мең 864 кеше яши. Чистай районында 61 торак пункт бар. Аларда 17 мең кеше яши. Гомумән алганда, бу регионда 504 торак пункт бар. Аларда 172 мең кеше яши.

Торак пунктлар саны ягыннан да, халык саны ягыннан да, территориясе (2332 км$^2$) ягыннан да иң зур район – Норлат районы. Ә иң кечкенә район – Яңа Чишмә районы. Территориясе – 1315 км$^2$ (Татарстан республикасының административ-территориаль бүленеше. Казан, 1992).

Регионда татарлардан башка руслар, чувашлар, марилар һәм мордвалар яши.

«Татарстан АССР тарихы»нда (Казан, 1970) нугайлар һәм калмыклар һөҗүменнән саклану өчен, 1652 – 1656 елларда Кама аръягы ныгытма линиясе төзелүе хәбәр ителә. Кама аръягы линиясен төзүдә татарлар, чувашлар, марилар, мордвалар катнашкан. Шушы линияне саклау өчен, XVII гасырның икенче яртысында һәм XVIII гасырда байтак кына йомышлы татар-мишәрләр Сембер, Түбән Новгород, Пенза губерналарыннан гаиләләре белән күчерелеп китерелэләр. Идел-Кама Болгары җимерелгәннән соң, өч-дүрт гасыр дәвамында буш яткан дип әйтерлек Кама аръягының көньяк-көнбатыш җирләрендә бик күпләгән татар-мишәр авыллары әнә шул чорда (моннан 250–300 еллар элек) барлыкка килгән. Бу территориядә татар теленең көнбатыш диалектына карый торган Чистай сөйләше таралган.

Шулай итеп, Кама аръягы территориясендә төрле милләт халкының шактый тыгыз аралашып яшәгәнлеге мәгълүм. Бу күренеш авыл атамаларында да чагылыш таба.

Әлеге хезмәтнең төп максаты – Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы ойконимнарына тарихи-лингвистик анализ ясау. Шушы максаттан чыгып, без түбәндәге бурычларны куйдык:

– Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы ойконимнарының формалашу процессын өйрәнү;

– аларның этнолингвистик катламнарын барлау;

– ойконимнарның лексик-семантик калыпларын аерып чыгару;

– ойконимнар барлыкка килүнең төп үзенчәлекләрен күрсәтү;

– бу региондагы ойконимнарның төп ясалыш үзенчәлекләрен анализлау;

– Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы ойконимнарының кыскача сүзлекчәсен төзү.

Тикшеренүнең төп чыганаклары булып «Татарстанның республикасының административ-территориаль бүленеше» (Казан, 1992), И.А. Износков хезмәтләре, халык санын исәпкә алу кенәгәләре, якташлык җәмгыятьләре чыгарган китаплар, 1999 елның август, 2000 елның июль айларында үткәрелгән экспедиция

мәгълүматлары, тарихчылар, археологлар, этнографларның хезмәтләрендә чагылыш тапкан фактлар тәшкил итте.

Бу монография Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы ойконимнарын фәнни итеп тарихи-лингвистик яктан комплекслы анализлауга багышланган беренче хезмәт.

Эшнең практик әһәмиятенә килгәндә, аның нәтиҗәләре, фактик мәгълүматлары лингвистлар, географлар, тарихчылар этнографлар, туган якны өйрәнүчеләр өчен файдалы булачак.

# 1. ТАТАРСТАННЫҢ КӨНБАТЫШ КАМА АРЪЯГЫНЫҢ ТАРИХИ-ГЕОГРАФИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

## 1.1. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы территориясенә физик-географик характеристика

Кама аръягы – Татарстанның иң зур географик зонасы. Бу зонага Камадан көньякта һәм Иделдән көнчыгышта яткан җирләр керә. Табигатьнең төрлелеге һәм табигый байлыклары ягыннан Кама аръягы республикабызда алдынгы урыннарда тора.

Рельефы һәм табигатьнең башка яклары буенча Кама аръягы ике төрле: көнбатыш өлеше – түбәнлек, көнчыгыш өлеше шактый биек калкулыклардан гыйбарәт.

Көнбатыш Кама аръягы түбәнлеге Иделнең сул ягындагы түбәнлекләрнең дәвамы булып тора. Ул диңгез өсте тигезлегеннән 50–100 метрга өстәрәк. Җир өсте шактый тигез, бик аз ергаланган, чөнки бу регион геологик яктан Татарстанда яшь район булып санала. Бозлык дәвереннән элегрәк булган неоген чорында Кама аръягы түбәнлеге киң җәелеп ташучы елгалар һәм төче сулы диңгез култыклары белән капланган булган.

Түбәнлекнең көнбатыш өлешен Иделнең сул террасалары алып тора. Киң террасалар акрынлап субүләргә күчә.

Кама аръягының көнбатышы, бигрәк тә аның көньяк-көнбатыш өлеше – коры климатлы. Көнбатыштан искән дымлы җилләр явымнарны Идел буе калкулыгында калдырып, Идел аръягына коры һава китерәләр. Җәйнең беренче яртысында көньяктан еш кына коры җилләр исеп, корылыкны арттыралар. Җәй шактый эссе, ә кыш салкын була. Норлат районының көньяк-көнбатышындагы Чулпан метеорология станциясе күзәтүләре буенча, июльнең уртача температурасы

19,2°С, гыйнварның – 14,6°С, явым-төшемнең уртача еллык күләме 428 мм.

Мондагы елгалар, Олы һәм Кече Чирмешән елгаларыннан башкалары, бик аз сулы. Вакытлыча корый торган елгалар да шактый күп.

Көнбатыш Кама аръягы – типик урман-дала районы. Районның төньяк һәм көнбатыш өлешләре Идел һәм Кама елгаларының сул ягы буйлап йөзәр километрга сузылган киң тигезлектә урнашкан. Кайчандыр монда дала ландшафты өстенлек иткән, хәзер исә зур мәйданны кара туфраклы иген басулары били. Элеккеге киң яфраклы урманның күп өлеше инде киселгән, ләкин әле бүген дә урманнар шактый.

Субүләр тигезлекләрендә соры һәм карасу-соры урман туфраклары таралган. Урман массивлары Кече Чирмешән, Олы Чирмешән һәм Олы Сөлчә елгалары араларындагы тигезлекләрнең көньяк өлешләрендә сакланган. Территориянең урман белән капланган өлеше – 17,7%. Юкә, имән, каен һәм усактан торган урман дистәләрчә километрларга сузылган.

Кара туфрак Кама аръягының төп туфрагы санала. Мондый туфрак Көнбатыш Кама аръягында авыл хуҗалыгы җирләренең 60% ын алып тора. Көнбатыш Кама аръягының мондый кара туфраклы басу территорияләренә Актай, Бизнә, Бахта (Алексеев районында), Чистай (Талкыш елгасы бассейны һәм Кама буйлары), сулъяк Шушма буе, Чирмешән-Кондорча (Октябрь районында) тигезлекле массивлары керә.

Кама аръягының климаты типик континенталь. Мондый климат тигезлекләрдә далага хас табигать шартлары саклануга ярдәм итә. Ләкин бу климат артык коры түгел, җәйге эсселек тә урманнар үсүенә комачауламый.

Район территориясеннән Норлат станциясе аша Ульяновск – Уфа тимер юлы һәм Казан – Чистай – Әлмәт автомобильләр трассасы уза. Кама елгасында Чистай һәм Болгар пристаньнары урнашкан.

Кама аръягы районына хуҗалыкның аграр-индустриаль юнәлеше хас. Сәнәгатенең үсеш дәрәҗәсе буенча Кама аръ-

ягы, бер яктан, индустриаль алга киткән Төньяк-Көнчыгыш, Төньяк-Көнбатыш һәм Көньяк-Көнчыгыш районнар белән, ә икенче яктан, аграр Кама алды һәм Идел алды районнары белән тоташа.

Кама аръягының төп сәнәгать тармагы – машиналар төзү, нефть чыгару, төзү материаллары җитештерү һәм авыл хуҗалыгы продуктларын эшкәртү. Сәнәгать тармаклары ике үзәктә – Чистай һәм Норлат шәһәрләрендә урнашкан.

Кама аръягында Татарстан авыл хуҗалыгы эшчеләренең – 18,5% ы һәм сәнәгать эшчеләренең 3,7% ы тупланган. Кама аръягы районы – республиканың ашлык җитештерү районы. Район сабан һәм уңыш бодае, арыш, солы, борчак, тары үстерүдә специальләшкән. Шулай ук бәрәңге, техник культуралардан шикәр чөгендере, силос өчен кукуруз, күпьеллык үлән үстерү зур урын алган. Терлекчелекнең төп тармагы – ит-сөт терлекчелеге – сыер, дуңгыз асрау һәм сарык үрчетү [Тайсин, Хуҗиев, 1995, б. 175–176].

## 1.2. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы халкы этник составының формалашу тарихы

Идел һәм Кама бассейнында иң беренче кешеләр бозлык чорында, урта палеолит заманында ук күренә башлаганнар.

Палеолит – таш гасыры, кешелек тарихының иң борынгы чоры һәм кешелек тарихында өч миллион чамасы елларны били. Үз чиратында ул өч этаптан тора: Түбәнге палеолит, Урта һәм Югары палеолитлар. Әгәр дә иң борынгы кеше, аның хайваннар дөньсыннан аерылу тарихы Евразиянең көньяк юнәлешләрендә һәм экваториаль Африкада барган икән, аның Көнчыгыш Европада, шул исәптән Идел-Камада килеп чыгуы нәкъ урта палеолит чоры белән бәйле [Фәхретдинов, 1996, б. 11]. Таш гасырда яшәгән беренче кешеләрнең эзләре Спас һәм Алексеев районнарында табылган.

Безнең эрага кадәр 4 һәм 3 меңьеллыкларда кеше яңа таш гасырга – неолит чорына – аяк баса. Бу чорда Идел һәм Кама буйларында кешеләр инде күбрәк күренә башлый.

Неолит чорында таш корал ясау эше камилләштерелә: кешеләр балта, пычак һәм башка коралларның йөзен шомарту, үткенләү ысулларын уйлап табалар. Коралларны шундый нык һәм үткен итеп эшләгәннәр ки, пычаклар белән хәтта кырыныр-лык булган. Таш балталарны һәм чүкечләрне әүвәлгечә таякка бәйләп беркетү белән генә канәгатьләнмичә, аларны тишеп агач сапка утыртканнар. Якынча шушы чорга караган таш пычак Әлки районының Иске Матак авылы янында табылган.

Кешелек тарихында беренче тапкыр буларак, неолит чорында утрак яшәү рәвеше барлыкка килә, иген үстерү һәм хайван асрау башлана, аучылык итү камилләшә, балык тоту җиңеләя, кешеләр көймә ясарга өйрәнәләр. Тукучылык һәм балчык савыт ясау уйлап табыла.

Бронза чорында бу якларда кешеләрнең күпләп яшәве билгеле. Бронза безнең эрага кадәр III меңьеллыкта ук табылган булса да, ул бары II меңьеллыкта гына киң кулланылышка керә. Бронза чорында кешелек цивилизациясенең учаклары булып көньякта Мисыр һәм Греция, якын Көнчыгышта Кытай һәм Һиндстан кебек югары үсешкә ирешкән колбиләүчелек дәүләтләре барлыкка килә. Ә Евразиянең төньяк өлешендә, шул исәптән безнең төбәкләрдә, борынгы ыруглык җәмгыяте өстенлек итә.

Бронза гасыры заманында бүгенге Татарстанның бөтен җирендә диярлек кешеләр яшәгән. Камадан көньяктарак (без тикшергән өлкәдә) борынгы Көнчыгыш Европаның иң зур археологик культурасы булган Бура культурасы (Срубная культура) кабиләләре көн иткәннәр. Әлеге кабиләләр, кеше үлгәч, аны кабер эченә кертеп ясалган кечкенә бураларда күмә торган булганнар. Культурага исем дә шартлы рәвештә шул йолага нисбәтле бирелгән [Фәхретдинов, 1996, б. 20].

1960 еллар башында профессор А.Х. Халиков җитәкчелегендәге археологик экспедиция Урта Әлки авылының көньягында безнең республикадагы иң борынгы курганнарның берсен таба. Ул каберлек-курганнар моннан 3,5 мең ел элек өелгән булганнар.

Бура кабиләләре яшәгән урыннарда табылган бронза урак, бөртек угычлары, китмәннәр, хайван сөякләре шул халыкның тер-

лекчелек һәм игенчелек белән шөгыльләнүләре турында сөйли. Зур осталык, зәвыклы рәсемнәр белән бизәлгән һәм чокып төрле катлаулы орнаментлар төшереп эшләнгән савыт-сабалар аларның чагыштырмача югары мәдәни үсешкә ия булуларын күрсәтә.

Галимнәр раславынча, бура кабиләләре һинд-европа телләренең берсендә сөйләшкәннәр. Моннан 3 мең еллар элек Казан буе кабиләләренең кысрыклавы нәтиҗәсендә, «буралылар», бу якларны ташлап, көньяк-көнбатыш өлкәләргә (Украинага) күчеп китәләр һәм элгәреге тимер чорына караган атаклы скиф культурасын формалаштыруга өлеш кертәләр.

Бронза дәвере чагыштырмача озакка бармый – б.э.к. II меңьеллыкка гына туры килә. Металл әйберләр куллану төсле металлургияне үстерүгә, алардан затлырак булган алтын һәм көмештән бизәнү әйберләре ясауны көйгә салып җибәрүгә юл ача.

Хәзерге Татарстан җирендә һәм аңа күрше районнарда тимер дәверенең баштагы чорын – б.э.к. I меңьеллыкны үз эченә алган вакытны – шактый мәгълүм булган берничә зур археологик культура аша күзалларга мөмкин.

Б.э.к. VIII–II гасырларда урта Идел һәм Кама буеның байтак төбәкләрендә фин-угыр телле Ананьино культурасы кабиләләре яшәгән. Исеме Алабуга районының Ананьино авылы исеменнән алынган. Узган гасырда ук шул авыл янында әлеге культураның бик бай истәлекләре өйрәнелгән. Ананьино культурасы чоры – Урта Идел буе халкының, хәтта антик дөньяга кадәр барып җитеп, бик күп кабиләләр һәм халыклар белән тышкы элемтәләр урнаштыру вакыты. Шушы археологик культурага хас бронза кельт сугыш балталары Югары Әлки авылы янында табылганнар.

Татарстан җирендә борынгы ыруг строеның таркалу чорында яшәгән иң соңгы зур кабиләләр берләшмәсе фәндә Имәнкискә культурасы исеме белән билгеле. Лаеш районының Имәнкискә янында бу кабиләләрнең зур шәһәрлеге табылган [Фәхретдинов, 1996, б. 22]. Бу культураның яшәү чоры безнең эраның IV–VIII гасырларына туры килә. Ул – Көнчыгыш Европада катлаулы этник үзгәрешләр башланган чор. Шул заманнарда Татарстанның борынгы җирләрендә яшәгән халыкларга көньяк-

көнчыгыштан халыкларның Бөек күчеше нәтиҗәсендә төрки телле яңа кабиләләр килеп кушылган.

Имәнкискә кабиләләре төрки телле кабиләләр булып саналалар. Алар, башлыча, авылларда яшәгәннәр, әмма балчыктан биек үрләр белән уратып алынган ныгытма-шәһәрчекләре дә булган. Үлгән кешеләрне яндырып күмгәннәр. Бу кабилә кешеләре нигездә игенчелек белән шөгыльләнгәннәр. Алар бу территориядә беренчеләрдән булып җирне ат ярдәмендә тимер сукалар белән эшкәртә башлыйлар, көньяк халыклары белән тыгыз элемтәдә торалар, актив сәүдә эшләре алып баралар.

Әйтеп үткәнебезчә, имәнкискәлеләр төрки кабиләләр булганнар. «...Төрки сүзе – түрк этнонимыннан гарәп-фарсыча ясалган түрки сыйфатының Идел-Уралдагыча „ү“не „ө“гә үзгәртеп әйтелеше. Түрк этнонимы тарихның киң сәхнәсенә б.э. V–VI гасырларында менә. Соңга таба ул төрки телләрне һәм аларның хуҗаларын җыеп, гомумиләштереп атау өчен кулланыла. Тарихи яктан ул (түрк, түрки, төрки), әле үзе сәхнәгә чыккынчы, башка исемнәрдә, мәсәлән, сөн (һүн-һун), сак (сака), скиды (скиде, скиф), барсия, саwир, аwар, алан, сармат кебек исемнәрдә күп мең еллар элегрәк яшәгән төркиләрне дә җыеп, гомумиләштереп атый» [Зәкиев, 1998, б. 19].

Урта Идел буена төрки кабиләләр беренче тапкыр кайчан килеп чыккан соң? Озак вакытлар буена бу җирләрдә төркиләшү безнең эраның VII гасыры тирәләрендә, ягъни бирегә борынгы болгарлар күченеп килү белән генә башланган, элек бу якларда фин-угыр кабиләләре генә яшәгән, дип исәпләнә.

Әлбәттә, Идел-Урал төбәгенең бик борынгыдан фин-угыр халыкларының туган җире булуында бернинди шик юк. Ләкин, төрки халыклар бирегә соңгы дәвердә генә килеп чыкканнар, дип нәтиҗә чыгарырга ярамый. Соңгы берничә дистә елда Идел һәм Урал буйларында үткәрелгән археологик тикшеренүләр нәтиҗәсендә бик кыйммәтле мәгълүматлар алынды. Алар борынгы төркиләрнең безнең якларга килеп төпләнгән вакытларын ераккарак күчерергә мөмкинлек бирәләр [Фәхретдинов, 1996, б. 27]. Сүз IV гасырда яши башлаган Имәнкискә археоло-

гик культурасы турында бара. Бу – нәкъ халыкларның Бөек күчеше башланган һәм һуннарның беренче тапкыр Европага килеп чыккан чоры. Имәнкискә культурасының төркиләргә каравы инде бәхәс уятмый, тик менә үзеннән соң шундый культура калдырган кабиләнең тарихи исеме генә хәзергә билгеле түгел. Алар турыдан-туры һуннар булмаган очракта да, һун кабиләләре берләшмәсе белән бәйле булганнар, дип фараз итәргә мөмкин. Һәрхәлдә, һуннар урдасы составындагы төрки кабиләләрнең кайсыдыр бер төньяк төркеме борынгы Татарстанга – аның далалы көньяк өлешенә килеп чыккан булуы бар. Бу фаразлау яңа археологик мәгълүмат – бөтен Урта Идел өчен дә уникаль булган табылдыклар белән раслана [Фәхретдинов, 1996, б. 27].

Идел буена һуннар урдасы составында башка төрки кабиләләр дә килеп утырганнар. Безнең якларда алар имәнкискәлеләр белән бер үк вакытта янәшә яшәгәннәр. Татарстанның көньяк, Кама аръягы районнарында, Чирмешән һәм Сөлчә елгалары буенда һәм тагын да көньяктарак аларның торулыклары табылган. Аларның керамик әйберләре – кул белән әвәләп ясалган күпләгән балчык савыт ватыклары – имәнкискә керамикасына бик тә охшаган. Шул ук вакытта алар үзләренә хас билгеләре белән имәнкискәлеләрдән аерылып та торалар. Кызганычка, имәнкискәлеләр дә, аларның кабиләдәш күршеләре дә безгә үзләренең исемнәрен дә, тел мирасларын да калдырмаганнар. Әмма археология мәгълүматлары ачык дәлиллиләр: Урта Идел буена болгарлар килеп утырганчы ук анда төрки телле кабиләләр яшәгәннәр һәм Идел-Урал төбәге халыкларының, шул исәптән татар халкының Урта гасырлар тарихына өлеш кертеп калдырганнар. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы территориясе Идел Болгарстанының үзәген тәшкил иткән.

«Болгар этнонимы – аның тар мәгънәсе – Болгар дәүләтен төзегән кабиләне атауга, киң мәгънәсе исә бик зур территориядә төзелгән Болгар дәүләте эчендәге барлык төркиләрне гомумиләштереп атауга кайтып кала. Традиция буенча болгар атамасы зыялылар арасында XX гасырга кадәр кулланылган [Зәкиев, 1998, б. 22].

Болгарлар һәм хәзәрләр, алар белән бергә оешып яшәгән башка кабиләләр хакында кыскача тагын шунысын өстәп әйтергә мөмкин: бу кабиләләр – хәзәрләр дә, болгарлар да, шулай ук савирлар да һәм бүтәннәре дә – кан-кардәшләр булганнар. Әгәр дә хәзәрләр Ашин ыруыннан башланып киткәннәр икән, болгарлар аңа якын Дуло ыруыннан чыкканнар. X гасыр чыганагында әйтелгәнчә, бу ике халык бер телдә сөйләшкән. Ниһаять, хәзәрләр дә, болгарлар да һәм аларның кабиләдәшләре дә һуннар империясе таралганнан соң барлыкка килгән Төрки каганлыгы буйсынуында калганнар. Әмма аннары, бу бәйлелектән котылып, үз дәүләтләрен оештырганнар [Фәхретдинов, 1996, б. 32].

Болгарларның Урта Иделгә күченеп килгәнлеген археологик мәгълүматлар раслый. Татарстанда һәм аңа янәшә төбәкләрдә, мәсәлән Ульяновск өлкәсендә, тикшерелгән матди культуралар калдыклары көньякта Азов-Кубан буендагы болгар җирләрендә табылган археологик истәлекләрнең материаллары белән бик охшаш. Ике төбәктә дә – көньяк-көнбатыштагы протоболгар дөньясында һәм Урта Иделдә яңа болгар җирләрендә – мәетне җирләү рәвешләре һәм каберлекләрдән табылган әйберләр (кием һәм корал калдыклары, йола савытлары һ.б.) бер-берсен кабатлыйлар яисә бер-берсенә бик охшаганнар.

Татарстан җирендә элгәреге болгарларның каберләре Тәтеш районының Олы Тархан, Спас районының Тамкеевка һәм Алексеев районының Зур Тигәнәле авылы, шулай ук Ульяновск өлкәсенең Кайбеле авылы янында табылганнар.

Идел Болгары заманына күрә зур мәйдан биләгән. X–XI гасырларда аның төньяк чиге – Каманың уңъяк яры, көнбатышта сул тармаклары белән бергә Зөя елгасы, көнчыгышта Шушма елгасы буйлап үткән, ә көньяк чикләре хәзерге Самара тугаена – Жигули таулары янында Иделнең зур борылышына кадәр барып җиткән.

XII гасырда дәүләтнең социаль-икътисади һәм сәяси үсеше нәтиҗәсендә аның чикләре киңәйгән. XVI гасырдагы «Казан тарихы» дигән русча язмада, татар тарихи чыганагы булган

«Дәфтәри Чыңгызнамә»дә Идел белән Камадан Җаекка кадәрге җирләр болгар җирләре дип аталган [Фәхретдинов, 1996, б. 63]. Болар болгарларга буйсынган җирләр. Болгарлар үзләре яшәгән җирләр бу чорда да, аңа чаклы да көнчыгышта Шушма елгасы чигеннән үтмәгән. Көньяк-көнчыгышта бу чик Олы Чирмешән елгасының югарыгы агымына барып җиткән һәм көньякка таба Иделнең сулъяк ярында бер тар аралык булып Самара тугае буйлап сузылган.

Идел Болгарында аның сәяси, икътисади һәм мәдәни йогынтысы астында яшәүче кабиләләр дә булган. Барыннан да элек болар болгарларның иң якын күршеләре – фин телләре гаиләсенә керүче кабиләләр, хәзерге мари, удмурт һәм көнчыгыш мордва-мукшыларның бабалары. Кайбер төрки телле кабиләләр дә болгарларга шундый ук бәйлелектә яшәгәннәр.

Болгарларның көнбатышта, фин-угыр җирләре артындагы ерак күршеләре – Киев Русе халкы. IX–X гасырларда бу ике дәүләт арасындагы дустанә мөнәсәбәтләр урнаштырыла, киеренкелек бераз соңрак башлана.

Болгар хуҗалыгының шактый алга киткән төре булып игенчелек санала. Җирне авыр сабаннар һәм җиңел сукалар белән сөргәннәр. Бодай, арпа, тары, ясмык чәчкәннәр. Бу хакта X гасыр башында ук әле Ибне Рустә язып калдырган: «Болгарлар игенчелек белән көн күрүче халык һәм һәртөрле иген ашлыгы үстерәләр, әйтик: бодай, арпа, тары вә башкалар». Болгарларның игенчелек продуктлары һәм гомумән ничек тукланулары хакында шуңа охшашлы сүзләрне аз гына соңрак Ибне Фадлан да әйткән: «Аларның ризыгы – тары белән ат ите, һәм бодай белән арпа да бик күп, һәм ни чәчкән, аны үзе өчен җыеп ала» [Фәхретдинов, 1996, б. 66].

Игенчелектән башка терлек асраучылык белән дә шөгыльләнәләр: ат, сыер һәм вак хайван тотканнар. Болгарлар сунарга да йөргәннәр: сусар, тиен, кондыз һәм башка төр җәнлекләр аулаганнар, балык тотканнар, кыргый бал җыю белән дә кәсеп иткәннәр. Бу байлыкның да бер өлеше башка илләр белән алыш-биреш итүгә тотылган.

Болгарда төзү эше һәм һөнәрчелек нык алга киткән. IX–X гасырлар чигендә, ярым күчмә тормыш сакланып, җәйләрен кешеләр тирмәләрдә яшәүгә күчсәләр дә, шәһәрләр барлыкка килү белән архитектура үсә башлый, төзү эше колач җәя. Кирпечтән һәм ак таштан сарайлар, мәчетләр, җәмәгать мунчалары, хәтта торак йортлар да салганнар.

Металлургия зур үсеш алган. Тимердән күп санлы эш кораллары һәм тормыш-көнкүреш әйберләре ясаганнар. Тимерчеләр арасында сугыш кораллары ясаучылар аеруча дан токан.

Болгарда бакыр һәм сөяк эшкәртү, чүлмәк ясау, тире иләү, эрләү һәм туку, ташка сурәт төшерү һәм башка шундый һөнәрләр югары дәрәҗәдә үсеш алган. Алтын һәм көмештән бизәнү әйберләре ясаучы осталар еракларда шөһрәт казанганнар. X гасырда ике зур шәһәрдә – Болгар белән Суарда – көмеш акчалар сукканнар.

Болгар илендә хәрби ныгытмалар төзүгә аеруча игътибар бирелгән. Шәһәр һәм кирмәннәр биек җир өемнәре һәм тирән чокырлар белән әйләндереп алынган, өемнәр өстенә ике рәтле имән стена – кура – һәм шактый биек манаралар эшләнгән булган. Бу хакта Суар, Болгар, Бүләр һәм башка кайбер шәһәрләрнең урыннарын казып тикшерү вакытында табылган материаллар, шулай ук Ашлы, Бүләр шәһәрләренең хәрби ныгытмалары турында рус елъязмалары калдырган мәгълүматлар сөйли.

Ибне Рустә болгарлар атка атланып йөриләр, көбә кием кияләр һәм баштанаяк коралланганнар, дип язып калдырган.

Идел Болгары гадәти феодаль дәүләт булган. Илдә әмир хакимлек иткән. Дәүләт оешкан башлангыч чорларда аның башлыгы Эльтебер дип аталган. Шул ук вакытта кайбер авторлар, беренче чиратта Ибне Фадлан, гарәп дөньясында гомуми кабул ителгәнчә, болгар хакимен уртак термин белән патша мәгънәсендә «мәлик» дип тә атаганнар. Ибне Фадлан шулай ук Болгар дәүләтендә мәҗүсилек булу хакында беренчеләрдән булып язып калдырган.

Болгар дәүләтендә беренче шәһәрләр X йөзнең 20 нче еллары башында күренә башлый. Бу хәл элекке ярымкүчмә тор-

мыштан утраклашып көн итүгә күчү белән бәйле. Беренче болгар шәһәрләренең үсеп чыгуы ислам кабул итү чорына туры килә.

Урта гасырларның гарәп-фарсы чыганаклары X гасырның 20 нче елларыннан ике болгар шәһәрен – Болгар белән Суарны – телгә ала башлыйлар. Бу шәһәрләр хакында беренче кыйммәтле мәгълүматларны Әл-Бәлхи язмаларыннан укырга мөмкин. «Болгар – ил исеме, аның халкы ислам динен тота. Ул шулай ук шәһәр исеме дә, анда җамигъ мәчете бар. Ул шәһәрдән ерак түгел икенче бер шәһәр Суар урнашкан. Анда да җамигъ мәчете бар. Мөселман хатибы әйтүенчә, ике шәһәрнең халкы 10 меңгә җитә». 10 мең халык дигәндә, сүз сугышчы ир-атлар турында гына бара, чөнки Урта гасырларда берәр шәһәрнең күпме халкы барлыгын аның гаскәр санына карап билгели торган булганнар.

Бүгенге көнгә Урта Идел буендагы Урта гасыр шәһәрчекләренең исемлеген төзү тәмамланган. Бу тарихи-археологик җыелма 161 истәлектән тора. Алар өч төркемгә бүленәләр: 38 шәһәрлек – элекке шәһәр яки шәһәр кирмәне, 73 феодал кирмәне, 39 хәрби ныгытма-крепость (мәгълүматлар тулы булмау сәбәпле 11 истәлекнең биләмәсе ачыкланмаган). Дөрес, барлык бу шәһәрләр, кирмәннәр һәм ныгытмалар борынгы болгар чорына гына карамый. Аларның байтагы Алтын Урда чорында да яшәвен дәвам иткән, шәһәрләрнең бер өлеше Алтын Урда дәверендә барлыкка килгән, Казан ханлыгына кагылышлы шәһәрләр дә юк түгел.

Болгар дәүләтендә, шәһәрләрдән, тыш бик күп авыллар да булган. Бүгенге көндә 200 дән артык авыл урыны билгеле. Аларның кайберләре шәһәр кремле ныгытмасыннан тышта, бистә сыйфатында барлыкка килгән. Әмма күбесе мөстәкыйль авыллар булып утырган. Кайберләре бик зур булып, 80–100 гектарга якын җир биләгән, ә күпчелегенең мәйданы 3–6 гектардан артмаган. Авыллар уртача 20–40 йорттан торганнар. Югарыда әйтелгән 200 дән артык авылның өчтән икесе Болгар чорына карый, башкалары, кайбер шәһәрләр шикелле үк, соңрак дәвердә – Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорында – барлыкка килгәннәр.

Идел Болгарында ислам кабул итү белән гарәп язуы гамәлгә кергән. Югары катлау кешеләренең генә түгел, гади халыкның, шул исәптән һөнәрчеләрнең дә, гыйлемлеген археологик табылдыклардагы язулар раслый. Гарәп язуын кабул итү Шәрык белән тыгыз элемтә урнаштыру, әдәбият, мәгърифәт һәм төрле фәннәр үстерүгә ярдәм иткән. X–XII гасырлардагы гарәп-фарсы дөньясының язма чыганакларында болгар тарихчылары, табибләры, фәлсәфәче һәм хөкемдарлары турында төрле хәбәрләр очратырга мөмкин. Мәсәлән, Әл-Гарнатый Болгар шәһәрендә казый Йакуб бине Ногман язган «Болгар тарихы» китабын укыган. Галим Борһанетдин бине Йосыф дарулар ясау турында китап язган, Урта Азия философларының әхлак-этика турында, риторика хакында хезмәтләренә аңлатмалар эшләнгән.

Болгар дәүләтендә матур әдәбият һәм халык авыз иҗаты үсеш алган. XI гасырда аларда кайбер гомумтөрки әсәрләр таралу хакында хәбәрләр сакланган. Мәсәлән, борынгы татар әдәбияты белгечләре 1069 елда Баласагун шәһәрендә Йосыф бине Хаҗип язган «Котадгу белек» әсәренең Болгар дәүләтендә дә киң таралуын әйтәләр. Мәхмүт Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрек» исемле мәшһүр сүзлеге, һичшиксез, Идел буенда да таралган булган [Фәхретдинов, 1996, б. 88].

Болгар дәүләте Урта гасыр дөньясының бик күп илләре һәм халыклары белән икътисади һәм сәяси элемтәләр урнаштырган. X – XIII йөзләрдә яшәгән һәм бу ил турында язган географ һәм сәяхәтчеләрнең барысы да диярлек, беренче чиратта, Болгар дәүләтенең киң сәүдә элемтәләре булганлыгын күрсәтәләр. Бу халыкара мал алмашуның географиясе бик киң булган. Көньяктан һәм көнчыгыштан – Хәзәр иле, Кавказ, Урта Азия, Фарсы, хәтта Төньяк Һиндстан, Төньяктан һәм Көнбатыштан – Төньяк кабиләләре, Русь, Балтик буе һәм Скандинавия илләре, Византия Болгар белән сәүдә иткәннәр.

X гасыр азагы авторы Әл-Мөкатдәси 985 елда «Климатларны өйрәнүдә иң яхшы бүленеш» исемле бик әһәмиятле хезмәтен язган. Анда Урта Азиянең Урта гасырда эре цивилизация үзәкләреннән берсе булган Харәземгә Болгардан китерелә һәм

аннан Шәрык дөньясына озатыла торган әйберләрнең тулы исемлеге бар: «Кеш, тиен, аю, сусар һәм урман сусары, төлке, кондыз мехлары, куян һәм кәҗә тиресе, балавыз, уклар, эре балык, бүрекләр, кырпы җилеме, балык тиресе, кондыз агынтысы, гәрәбә, йомшак күн, чикләвек, барслар, кылычлар, көбәләр, каен агачы, славян әсирләре, сарыклар, мөгезле терлек. Болар һәммәсе Болгардан».

Читкә чыгарылган бу әйберләрнең берише үзләрендә эшләнгән, кайберләре күршеләреннән – төньяк кабиләләреннән, хәзәрләрдән, кайберләре башкорт, бортас, чирмеш, ар һ.б. кебек якын күршеләрдән һәм Русьтан кайтартылган. Кайбер мехлар, куян һәм кәҗә тиресе, терлекнең бер өлеше, уклар, бүрекләр, күн, көбә, бал, чикләвек, каен агачы болгарларның үзләренеке булган. Кыйммәтле мехларның байтагын төньяк кабиләләреннән һәм якындагы фин-угыр күршеләрдән алганнар. Башкортлардан сарык, Русьтан ике ягы да үткен туры кылыч, Балтик буеннан гәрәбә һәм Хәзәрдән затлы балыкның кайбер төрләрен алганнар.

Халыкара товар алмашуда әһәмиятле арадашчы буларак, Болгар бу сәүдәне үз кулында тоткан: болгар әмире, халыкара килешенгән кагыйдә нигезендә, һәр чит илнең су һәм коры җир кәрваннарыннан дәүләт файдасына товарларның уннан бер өлешен алып калган. Шул ук вакытта болгар маллары үзләре дә Евразия сәүдә әйләнешендә яхшы бәя тотканнар, аннан да дәүләткә зур файда килгән, илнең икътисады үскән.

Киев Русенең Идел Болгары белән сәяси мөнәсәбәте нигездә тынычлыкка корылган булса да, XII гасырда, үзәге Владимирга урнашкан Төньяк-Көнчыгыш Русе оешу белән яңа дәвер башлана. Атап әйткәндә, ул Андрей Боголюбский һәм аның варисларының Болгарга бер-бер артлы яуга чыгулары белән башланып китә. Киев Русе шулай да Болгардан ерактарак, аның сәяси үзәге дә Днепр буенда. Ә менә үзәге Югары Иделдә булган Төньяк-Көнчыгыш Русь барлыкка килгәч, славяннар өчен көнчыгыш һәм көньякка таба юнәлештә, Иделдән Каспийга һәм шуннан бөтен Шәрык дөньясына юл ачылган.

Ләкин бу юлда Идел буйлап чак кына түбәндә, Шәрык капкасын ябып, Болгар дәүләте утыра. Шуңа күрә дә Боголюбский башлап җибәргән яулар Болгарга ябырылган.

Монгол яуларына кадәр Русь белән ике арада тынычлык урнаша. Үзара ярдәмләшү, сәүдә мөнәсәбәтләре җайга салына. Тыныч мөнәсәбәтләрне саклау өчен әйбәт җирлек тә әзерләнә. Әмма монголларның бөтен Көнчыгыш Европаны басып алуы аркасында бу ике ил һәм ике халыкның язмышы башка төрлерәк юнәлеш ала. Болгар бәйсезлеген югалта һәм яңа дәүләт – Алтын Урдага кушыла, Русь иле дә Урдага буйсындырыла.

Билгеле булганча, монгол гаскәре 1236 елда Европага юнәлә. Берсе арты берсе Суар, Болгар, Бүләр, Җүкәтау һ.б. шәһәрләрне яулап ала – Болгар иле буйсындырыла. Шулай да ул Алтын Урданың эчендә иң көчле. Җучи улусының үз шәһәрләре калкып чыкканчы, Идел буенда сәүдә үзәге буларак, дәүләтнең мәркәзе вазифасын да үти, җучи тәңкәләрен дә иң әүвәл икътисади ныгып өлгергән Болгар каласында суга башлыйлар.

XIV гасырда сәяхәт иткән Марко Поло язып калдырганча, Алтын Урданың ханнары Сарай Бату белән Сарай Бәркәдән торып та, Болгардан торып та идарә итәләр. Ә инде XIV гасырда Болгар каласы Алтын Урданың аеруча зур һәм мәшһүр шәһәрләренең берсенә әверелә.

Дин, тел берлеге, мәдәни уртаклык – архитектура, зәркән сәнгате һәм һөнәрчелек охшашлыгы Болгарны Алтын Урдага бик нык бәйли, аның аерылгысыз өлешенә әйләндерә. Нәкъ менә шушы дәвердә Болгар җирендә зур үзгәрешләр башлана, чуен коела, утлы корал кулланыла башлый һ.б.

1380 елда тәхеткә Тuктамыш хан утыргач, Урданың бердәмлеге аеруча ныгый, әмма нәкъ менә XIX гасырның 80 нче еллар азагында Алтын Урда җимерелә-таркала башлый. 1391, 1395 еллардагы сугышларда Аксак Тимернең Туктамыш ханны җиңүе бу җимерелүне тизләтә.

Шулай ук рус ушкуйниклары да шактый каза китерә. Идел буйлап көймәләрдә яу белән килеп, Кострома, Углич, Нижний

кебек рус калаларын талап, бөлгенлеккә төшереп йөрүче юлбасар ушкуйниклар Сарайда да 1360, 1366, 1374, 1391 елларны Болгарга, Иделдәге һәм Камадагы бүтән кайбер шәһәрләргә ябырылалар. Рус кенәзләре дә Урта Иделгә 1370, 1376, 1431 елларда яу белән киләләр.

XV гасыр азагына Көнбатыш Кама аръягы бөтенләй диярлек бушап кала. Сөрүлек җирләрне урманнар, сазлыклар каплый. Болгар һәм Кама аръягы (Җүкәтау, Тубылгытау) болгар кенәзлекләре кешеләре күпләп төньякка – Кама аръягына, көнбатышка – Идел аръягына, көнчытышка – Урал буйларына күчеп утыралар. Илнең яңа сәяси, икътисади һәм мәдәни үзәгенә әверелгән Казан тирәсендә туплану көчәя. XIV – XV гасырларда Казан кенәзлеге сәяси яктан мөстәкыйль оешма буларак тәмам оешып җитә [Халиков, 1992].

Болгар дәүләтен һәм аның аерым шәһәрләрен өйрәнүгә П.С. Паллас, И.И. Лепехин, П. Сваньин, А.К. Шмит, Х.М. Френ, Н.Н. Кафтанников, Ф.И. Эрдман, М.С. Рыбушкин, Н.И. Второв, А. Кавелин, И.Н. Березин, А.Ф. Риттих, В.К. Савельев, К.И. Невоструев, А.Ф. Лихачев, С.М. Шпилевский, П.В. Васильев, Н.И. Золотницкий, В.А. Казаринов, Т.А. Хлебникова, А.Г. Мөхәммәдиев, Р.Г. Фәхретдинов, А.Х. Халиков һ.б. бик күп галимнәр зур өлеш кертә. Ә Мәскәү профессоры А.П. Смирнов болгар дәүләтен, Болгар шәһәре тарихын эзлекле рәвештә өйрәнүгә бөтен гомерен багышлый.

Казан ханлыгы вакытында элекке Болгар җирләрендә яшәүчеләр аз кала. Ханлык җимерелеп, аның бөтен җирләре рус хакимияте кулына күчкәч, болгар-татар тарихында бөтенләй башка чор башлана.

Идел, Кама буенда яшәүче алпавытларга күчмә халыклар һөҗүм ясап торалар. «Татарстан АССР тарихы»нда (Казан, 1970) нугайлар һәм калмыклар һөҗүменнән саклану өчен 1652–1656 елларда Кама аръягы ныгытма линиясенең төзелүе хәбәр ителә. Бу линияне төзүдә татарлар, чувашлар, марилар һәм удмуртлар катнашкан. Шушы линияне саклау өчен, XVII гасырның икенче яртысында һәм XVIII гасырда байтак

кына йомышлы татар-мишәрләр Сембер, Түбән Новгород, Пенза губерналарыннан гаиләләре белән күчерелеп киterеләләр. Идел-Кама Болгары җимерелгәннән соң өч-дүрт гасыр дәвамында буш яткан дип әйтерлек Кама аръягының көньяк-көнбатыш җирләрендә татар-мишәр авыллары әнә шул чорда (моннан 250 – 300 еллар элек) барлыкка килгән.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: безнең бурычыбыз – тикшерелә торган регионга тарихи экскурс ясау, җирләрнең җанлы тарихын укучы күз алдына китерү. Тикшерелә торган регионның Идел Болгарстаны составында булганлыгын истә тотып, Болгар дәүләте тарихына аеруча басым ясадык. Белгәнебезчә, Болгар тарихы – татар халкы тарихының бер этабы, һәм дә бик мөһим, киеренке этабы.

## 2. ТАТАРСТАННЫҢ КӨНБАТЫШ КАМА АРЪЯГЫ ТОРАК ПУНКТ АТАМАЛАРЫНЫҢ ЭТНОЛИНГВИСТИК КАТЛАМНАРЫ

Татарстанның Көнбатыш Кама арьягында төрле халыклар яшәгән. «Татар халкы һәм теле формалашуда Идел болгарлары төп роль уйнаса да, алар составына шулай ук төрки телле печенеглар, кыпчаклар, мишәрләр, татар-монгол яулары белән килгән төркиләр, аз булса да монгол телле монголлар, фин-угырлар һәм хәтта славяннар да төрлесе төрле дәрәҗәдә катнашкан» [Зәкиев, 1977, б. 188]. Әлеге этногенетик бәйләнешләр топонимиядә дә чагылыш таба.

Татарстанның Көнбатыш Кама арьягы ойконимнарында без түбәндәге генетик катламнарны аерып чыгабыз:

Төрки катлам.

1. Борынгы төрки катлам.
2. Болгар катламы.
3. Татар катламы.
4. Чуваш катламы.
5. Башкорт катламы.

Фин-угыр катламы.

Монгол катламы.

Гарәп-фарсы катламы.

Рус катламы.

Бу катламнарны аеру – шактый авыр эш: бер үк атама берничә катламга карарга мөмкин. Төрки катламның үзен аеру читен. Без бу проблеманы үзебезчә хәл итәргә тырыштык. Мәсәлән, Байтирәк ойконимы антропонимга нигезләнгән. Бүгенге татар телендә бу кушма сүзнең элементлары аерым-аерым кулланылышта йөрсәләр дә, кушма сүз буларак ойконимда гына сакланып калган. Шуңа күрә бу атаманы борынгы төрки катламга

кертеп карыйбыз. Яки Чирмешән атамасын алыйк. Бу атаманы без ике катламга да кертеп карыйбыз. *Чирме* элементы болгар теленә нисбәтле. Ул бүгенге чуваш телендә дә бар, ләкин чуваш теленә ул болгар теленнән мирас булып калган. Шуңа күрә бу элементны болгар катламына кертәбез. Икенче компонент – *шән-шөн-сән-сөн* сүзе борынгы төрки кабиләләр телендә *елга* мәгънәсендә йөргән. Димәк, әлеге атаманы борынгы төрки һәм болгар катламнарына кертәбез. Чирмешән формасында бу атама болгар чорында формалашкан булса кирәк.

## 2.1. Төрки катлам

### 2.1.1. Борынгы төрки катлам

Көнбатыш Кама арьягы борынгы төрки катлам ойконимнарын анализлауны Аксубай атамасыннан башлыйбыз. Югарыда әйтеп үткәнчә, бу атаманы тикшерүне ике катламга да кертеп карарга була.

Татар антропонимиясендә *ак* сүзе катнашында ясалган кушма төзелешле борынгы кеше исемнәре бик күп, мәсәлән, Акбатыр, Акъегет, Акбуга, Аксубай һ.б.

Аксубай исеме *ак* + *субай* сүзләреннән тора. Борынгы төрки телгә фарсы теленнән килеп кергән *сыбай* сүзе атлы сугышчы төшенчәсен белдергән [Саттаров, 1984, б. 56].

Әлки районында Иске Алпар һәм Яңа Алпар исемле татар авыллары бар. Әлеге атамалар Алпар дигән борынгы төрки кеше исеменә нигезләнеп ясалганнар. Татарлар арасында аз булса да очрый торган Алпаров фамилиясенең (мәсәлән, профессор Гыйбадулла Алпаров) асылында да шушы исем ята.

«Борынгы төрки сүзлек»тә *alp* сүзенең

а) меткий стрелок

ә) герой, батыр, витязь

б) отважный, храбрый, смелый

в) отвага, храбрость, мужество мәгънәләрен белдерүе күрсәтелгән [ДТС, 1969, с. 7]. Шушы сүзгә нигезләнеп байтак кына борынгы кеше исемнәре барлыкка килгән. Алпар атамасының

борынгы төрки телгә нисбәтлелегенә С.Е. Малов хезмәтендә дә игътибар ителә. Автор *alp* сүзенә Күл-Тәгин ядкарендәге *Alp ar* исемен мисал итеп китерә [Малов, 1951, с. 375]. Г.Ф. Саттаров та бу атаманың төрки телгә нисбәтлелеген күрсәтә [Саттаров, 1973, б. 55].

«Пәһлевәндәй гәүдәле, батыр болгар кешесен – Алыпны» – Ибне Фадлан да үзенең юлъязмасында телгә алып үтә.

Иделнең уң ягында Мәскәү–Урга тимер юлының Рузаевка станциясеннән ерак түгел мордва җирендә, Рамадан районында Алпар авылы бар. Менә шул авылдан күченеп килгән ләмберә мишәрләре 1695 елда хәзерге Әлки районының Иске Алпар авылына нигез салалар. 1995 елда авыл 300 еллыгын билгеләп үткән.

Бирегә күченеп килүчеләрнең иң өлкәне – Алпар бабай. Ул үзе белән биш гаилә татар-мишәрләр, бер гаилә мордва, бер гаилә мари һәм бер гаилә чуваш алып килә. Авылның иң борынгы урыны хәзерге пекарня һәм кибет тирәсендә булган. Биредә Алпар бабай йорты була. Аның белән янәшәдә мордва, аннан соң 4 татар гаиләсе килеп төпләнә. Каршы рәттә чувашлар яшәгән. Урамның исеме дә чуваш урамы дип йөртелә. Алпар авылы җирләренә төньяк-көнчыгыштан Мораса елгасы яны, аннан соң Зирекле Миләшлеге тирәләре кергән.

Спас районында Аграмаковка исемле рус-татар авылы бар. Ойконим Аграмаков фамилиясенә нисбәтле. Фамилия үз чиратында Аграмак кушаматыннан алынган. Аграмак сүзе борынгы төрки телдән алынган, дип саныйбыз. «Аграмак» сүзе «аргамак» сүзенең фонетик үзгәреш кичергән варианты. Монда метатеза күренеше күзәтелә.

Әлки районында Апак исемле рус-татар-чуваш авылы бар. Русча атамасы Аппаково. Шундый ук атамалы авыл Әлмәт районында да бар. Р.И. Куряева фикеренчә, бу атама Аппаков фамилиясенә нисбәтле. Ә фамилия Апак исемле кеше исеменнән ясалган [Куряева, 1990, с. 45]. Бу фикер белән өлешчә килешергә була, ләкин атама фамилиядән алынгандыр, дип уйламыйбыз. Авылның татарча атамасы Апак. Бу атама борынгы төрки

кеше исеме Аппакка нисбәтле. Татар авылларын русчалатып язганда аларга *-ово, -ова* кушымчалары кушу гадәти хәл. Авылга нигез салган кеше Аппаков фамилияле түгел, ә Аппак исемле булгандыр дип уйлыйбыз.

Кайбер атамаларны без берничә катламга кертеп карыйбыз. Мәсәлән, Актау һәм Акташ, Акъяр атамалары. Бу атамалар җирле географик объектның төсен белгертүгә нигезләнеп барлыкка килгәннәр. Оронимик терминнар соңрак ойконимнарга әверелгәннәр.

Актау атамасы, Э.М. Мурзаев язганча, ялгызлык исеме буларак, Төркиядән Хакасиягә кадәр зур җирлектә кабатлана. Бу атама барлык төрки халыкларның да телендә бар: *актаг, акдаг, актау, актоо, актуу, ахтаг* [Мурзаев, 1996, с. 107]. Димәк, бу атама борынгы төрки телдә дә булган. Атама татар телендә дә актив кулланылышта йөри. Шуңа күрә аны татар теленә дә нисбәтле итеп карыйбыз. Калган ике атама белән дә шул ук хәл.

Кече Акташ – Аксубай районында чуваш, Акъяр – Яңа Чишмә районында татар авыллары. Һәр ике атама да гомумтөрки элементлардан тора. Акъяр атамасының *яр* элементы борынгы төрки телдә *jar*, үзбәк телендә *ер*, казак һәм кыргызда *жар*, алтайда *jar*, хакаста *чар*. Рус теленә дә кергән – Красноярск шәһәре һ.б. *Таш* элементы үзе генә дә шактый актив. *Таш, Ташлы, Ташлык, Ташту, Коктас* һ.б. Азәрбайҗанда күпер исеме – Дашкепри.

Югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, *ак* сүзе топонимнар ясауда да, антропонимнар ясауда да төрки халыкларда бик актив кулланыла, гидронимнарда да шактый күп очрый (Агыйдел, Актай, Аксу һ.б.).

Борынгы төрки атамаларга без Акбулат атамасын да кертеп карыйбыз. Акбулат авылы Чистай районында урнашкан. Атама ике компоненттан тора. «Ак» һәм «булат» сүзләре. Ойконим антропонимга нисбәтле.

Гомумән, *ак* сүзе борынгы кеше исемнәрен ясауда актив кулланыла. *Ак* чисталык, аклык, пакьлекне аңлата. Татар халкы бүгенге көндә дә үзенең аеруча ихтирам иткән картларына Ак әби, Ак бабай, Ак түти, Ак җиңги һ.б. дип эндәшә.

Атаманың икенче элементы *булат* борынгы төрки телдә корыч төрен, кылычны аңлаткан. Бу сүз XV гасырда татар теле аша рус теленә дә кергән. Исем төрле төрки халыкларда компонент сыйфатында исемнәр составына керә: Булатбай, Булатхуҗа, Акбулат һ.б. Татарларда аерым исем буларак та кулланылышта йөри. Яшел үзән районында Булат бистәсе бар.

Яңа Чишмә районындагы Новая Деревня дигән рус авылының татарча атамасы – Яңа Авыл. Шундый ук исемдәге авыллар тагын Алабуга һәм Зәй районнарында бар. Атаманың русча варианты татарчадан калька булса кирәк.

«Татар телендә авыл сүзе чагыштырмача соңрак кулланыла башлый. Казан ханлыгы чоры авыл атамаларында бу сүз очрамый» [Саттаров, 1989, б. 47–58]. Төрки телләрдә авыл сүзенең түбәндәге формалары бар: *авул, аул, ауыл, айыл, аил, агыл, ыол, йол, овул.* Борынгы төрки *агыл* сүзе «хайваннарны тота торган аралык» дип аңлатыла. И.Г. Добродомов исә авыл сүзен «аурга» (падать) төрки фигыленнән чыккан дип аңлата [Добродомов, 1986]. Татар телендә мондый фигыль чыннан да бар. Татар әдәби телендә бу сүз гадәттә *у* сузыгы аша языла: *ауды,* ә мишәр диалектында *в* авазы белән әйтелә: *авды.* Фигыльнең нигезендә борынгы төрки телдә «җыелырга» мәгънәсен белдерүче *ав* тамыры ята [ДТС, 1969, с. 69]. Ул чагында *авыл* күчмә тормыш күрүче төркиләрнең бергә җыелу урыны була. Күчмә халыкларда туктаган урында җиргә утыру (аву) гадәте булган. Бергә җыелган төркиләр басып тормаганнар, ә җиргә утырганнар. Э.В. Севортян да *авул* сүзен *ав* тамырына нисбәтле дип саный [Севортян, 1974]. Безнең фикеребезчә, *авыл* сүзе үзенең тамырлары белән, һичшиксез, борынгы төрки телгә нисбәтле. Ләкин бүгенге *авыл* формасы һәм бүгенге мәгънәсе татар телендә формалашкан. Без бу сүзне ике катламга да кертеп карау ягында.

Әлки районында Большая Полянка, Чистай районында Малая Полянка дигән ике рус авылы бар. Татарлар бу авылларны Зур Алан, Кече Алан дип йөртәләр. Бу авылларның русча атамалары татар теленнән калька булырга тиеш. Әлеге сүзнең башка төрки телләрдә дә булуы аның борынгы төрки телгә нисбәтле

булуын күрсәтә. Э.М. Мурзаев китабында бу сүзнең башка төрки телләрдәге түбәндәге формалары китерелә: *аклан, агы, йаланг, агак, йолон*. Борынгы төрки телдәге формасы: *jalan*. *Ялан* формасы татар телендә дә кулланылышта йөри. Мәсәлән, Чистай районында Кызыл Ялан дигән татар авылы бар. Якутиядә, Амур өлкәсендә һәм Хабаровск краенда Авлан елгасы бар, Эвенкиядә – Аглан һәм Аглакан елгалары һ.б. [Мурзаев, 1996, с. 212]. Алан сүзе рус теленә *елань* формасында кергән. Тагын *еланка, еланчик, еланок* формалары да кайбер рус диалектларында очрый [Мурзаев, 1996, с. 146]. Төрекмәнстанда Далимголон дигән торак пункт, Пенза өлкәсендә Большой Елань торак пункты һәм Елань елгасы бар. Елань исемле торак пунктлар шулай ук Чита, Кемерево, Самара һәм Төмән өлкәләрендә дә очрый.

Чиябашы һәм Сүлчәбаш исемле авыл атамаларының икенче элементы, *баш* сүзен борынгы төрки телгә нисбәтлибез. Төрле төрки телләрдә *баш, бас, пас, паш* формалары бар. Сүз географик атамалар составына еш керә. Тау башларын, елга башларын аңлатуда «начало» һәм «конец» мәгънәләренә ия. *Акбаш, Улубаш, Башкенд, Башбулок* һ.б. бик күп атамалар составына керә [Мурзаев, 1996, с. 38]. Сүлчәбаш авылы Яңа Чишмә районында урнашкан. Анда татарлар яши. Чистай районында Чаллыбаш дигән авыл бар. Рус Чиябашы һәм Татар Чиябашы кушылып, аралашып беткәннәр, хәзер авыл Чиябаш дип кенә йөртелә. Бу атама Кече Чирмешән кушылдыгы Чия елгасының шул авылдан башлануына нигезләнгән.

Чистай районында Байтирәк исемле татар авылы бар. Байтирәк дигән авыл Балык Бистәсе районында да бар. Ойконимның нигезендә борынгы кеше исеме ята. Бу исем удмуртларга һәм мариларга да кергән. Себер татарларында «пай тәрәк – зур агач, кабилә, ыру символы булырга мөмкин. Пүгүн йаман түш көрдүм, палам, үйүм артында пай тирәк көрдүм, палам, ү үстүнө йыгылды...» [Алишина, 1999, с. 21]. «Бай служило приставкой к названию мифического дерева, корни которого растут в подземном мире, ствол на земной поверхности, а вершина достигает небесной сферы. Таков образ в эпосе алтайцев тополя –

Бай терек» [Потапов, 1986, с. 235]. Хакасларда, алтайлыларда *байкайын* дигән термин да бар.

Бу агачлар изге саналганнар. Аларга төрле төстәге чүпрәкләр бәйләгәннәр. Тирәк агачы, гомумән, ныклы, яхшы агач саналган, һәм шул хәл тирәк сүзенең кеше исемнәрен актив кулланууына китергән булса кирәк. Урта гасырларда Мәскәүдә Байтирәк исемле нугай илчесе булганлыгы билгеле. Г.Ф. Саттаров фикеренчә бу исем ата йортында каласы малайга бирелгән булган [Саттаров, 1981, б. 42].

Татар Баганалысы авылы Чистай районына карый. Авыл картлары сөйләвенә караганда, бу урынга иң элек килеп утырган кеше Казан артындагы Балтач авылыннан була. Ул кеше килеп, бик матур чишмә таба һәм, бу урынга авыл урнашырга тиеш дип, багана утырта. Шуннан соң монда татарлар килеп авыл торгызалар [Гарипова, 1994].

*Багана – баганасы* – гомумтөрки сүз. Ул бөтен төрки телләрдә дә очрый. Татар һәм мордва авылларын бер-берсеннән аеру өчен берсен Татар Баганалысы, икенчесен Мордва Баганалысы дип атаганнар. Мордва Баганалысы авылы XVIII гасырның беренче яртысында оешкан.

Алексеев районында Балахчино дигән рус авылы бар. Ойконимның нигезендә Балахчин дигән кеше фамилиясе ята. Фамилия борынгы төрки Балукчы исеменнән ясалган [ДТС, 1969, с. 112]. Исем борынгы төрки сүз *балыгчы*га барып тоташа [ДТС, 1969, с. 80].

Барское Енорускино – Аксубай районындагы рус авылы. Безнең фикеребезчә, атаманың *Барское* элементы төрки телгә нисбәтле. Барское сүзе бу авылның бер боярныкы булуын күрсәтә. Рус телендә югары катлау вәкилләрен барин дип йөрткәннәр. Пенза һәм Самара өлкәләрендә Бариновка дигән авыллар бар. *Барин* сүзенең беренче варианты *боярин*. *Боярин* сүзе төрки телләрдән кергән. Төрки телләрдәге варианты *баер=байар*. Бай-ар.

Әлки районында Түбән Биктимер һәм Урта Биктимер авыллары бар. Биктимер исемен борынгы төрки телгә нисбәтлибез. Бүгенге көндә дә бу исем татарларда, башкортларда,

нугайларда, кумык һәм кырым татарларында кулланылышта йөри. Гомумән, тимер элементы кергән исемнәр тотрыклы булулары белән игътибарны җәлеп итәләр. Борынгы төрки заманнардан бүгенге көнгә хәтле төрле формаларда килеп җиткәннәр: Биктимер, Тимерхан, Җантимер, Минтимер, Тимер, Тимур һ.б. Һ.В. Йосыпов Биктимер исемен борынгы болгар исемнәре рәтенә кертеп карый [Юсупов, 1985, с. 101–111].

Бикүле авылы Норлат районында урнашкан. Атаманы борынгы төрки катламга кертеп карыйбыз. Ойконим ике элементтан тора – *Би+күле*, һәр ике сүз дә борынгы төрки телдә бар. *Би* сүзенең борынгы формасы *Beg* [ДТС, 1969, с. 92].

*Би* формасы беренче тапкыр кумык телендә XIV гасырда күренә, татар теле өчен искергән вариант булып тора, бүгенге көндә казак, төрек, караим телләрендә бар. Авыл атамасында татар теле өчен искергән *би* формасының булуы аның (авылның) борынгылыгын күрсәтә.

Атаманың икенче компоненты *күл* дә гомумтөрки эпитет. Бу сүз төрле фонетик төрдәшләре белән төрки телләрнең барысында да табыла. Мәсәлән, кумыкча – *кел*, нугайча – *къол,* кыргызча, хакасча, каракалпакча – *көл*, үзбәкчә – *күл,* чувашларда *куле* һ.б.

Борынгы төрки телдә *kol* [ДТС, 1969, с. 313]. Без тикшергән регионда *күл* компоненты кергән авыл атамалары: Урта Йорткүл, Кәкре Күл, Кыркүл, Каракүл, Күлбай-Мораса, Якты Күл. Гомумән, төрки дөньяда *күл* сүзе белән топонимик мисалларны күп китерергә мөмкин. Берничәне генә күрсәтеп китәбез: торак пункт һәм күл Каракүл (рус картографиясендә күл формасын куль рәвешле язу кабул ителгән), Бикүл, Акколъ, Гүйгүль, Алтынколь, Кюль-Юрех, Иссыккуль, Чатыр-Куль, Сон-Куль, Баграшкуль, Сасykколь һ.б. Бикүл авылы янындагы Би күле гидроним атамасының болгар чорыннан ук калганлыгын, Р.Г. Фәхретдиневның археологик дәлилләренә таянып, Г.Ф. Саттаров та күрсәтеп китә [Саттаров, 1973, б. 190].

Би сыйнфый катлам титулына нигезләнгән тагын бер авыл атамасы – Биккол. *Би* һәм *бик* формалары бер үк мәгънә аңлаталар, *бик, би* формасының яңгырашы гына бүтәнчә. Авыл

атамасының икенче элементы *кол* формасы турында кайбер лексик-семантик фикер төрлелегенә бераз гына урын кала. Бу төрлелекләр белән алдагы бүлектә таныштырырбыз. Генетик яктан караганда, Биккол атамасын, һичшиксез, борынгы төрки телгә нисбәтле итәбез. Биккол авылы да Норлат районында урнашкан. Бикулов Починок исемле авыл Самара өлкәсенең Кошкинский районында да бар.

Бугровка – Спас районындагы рус авылы. Бугровка исемле авыл Пенза өлкәсенең Белинский районында, Бугринка дигән авыл Самара өлкәсенең Большекунищий районында урнашкан. Ойконимнар нигезендә Бугров, Бугрин рус фамилияләре ята. Фамилияләр бугор «кечкенә тау, калкулык» дигән рус сүзеннән ясалганнар. Бу сүз рус теленә XVII гасырда керә. Аның этимологиясе шактый бәхәсле, ләкин төрки булырга мөмкин дигән фикерләр бар [Мурзаев, 1984, с. 97]. Без дә бу фикергә кушылабыз. *Бугор* сүзен борынгы төрки телдәге бугра (дөя) сүзе белән чагыштыралар. Моннан тыш, бу сүз төрек һәм азәрбайҗан телендә – *бугур* (дөя), төрек теле диалектларында *букуру*, *букру*, *бугру* – калкулык, *бөкереү*, татарда *бөкре*, башкортларда *букуру*, борынгы төрки телдә *букри* (бөкре, горбатый). Күренгәнчә, бу сүзне борынгы төрки телгә кертергә нигез юк түгел.

Алексеев районында Мордва Булагы исемле авыл бар. Татарстан җирлегендә *болак* (булак) үзе генә дә катлаулы атамалар составында да кулланыла. Мәсәлән, Тиган булак елгасы – Шонталы (Алексеев районы), Сары болак – Актай (Спас районы), Кара болак – Кече Чирмешән (Әлки районы), Озын болак – Майна (Спас районы) елгаларының кушылдыклары.

*Болак* сүзе төрле фонетик яңгырашы белән төрле төрки телләрдә – гагауз, төрек, казак, кыргыз, үзбәк, каракалпак, кумык, кабарда-балкарда – бар. Булаг формасында монгол телендә дә бар. Димәк, бу сүз гомум Алтай чорына ук барып тоташырга мөмкин. Төрки дөньяда составында *болак* сүзе булган топонимнар: Ташбулак, Булокш, Карабулак, Ташцог-булаг елгасы, Алтон-Булаг шәһәре, Кар-Булак елгасы. Борынгы төрки телдәге формасы – *bulag* [ДТС, 1969, с. 21].

Чистай районындагы Булдырь авылы атамасын уртак төрки-татар сүз хәзинәсенә кертәбез. *Булдырь* формасы татар теленнән кергән. Тамыры борынгы төрки телгә нисбәтле. Борынгы телдәге формасы – *bol* [ДТС, 1969, с. 111]. Болгар телендә *bol*, башкортта – *булыгу*, үзбәктә – *булнак*, караимнарда – *бол* [Хакимзянов, с. 69–70].

Батыр – Аксубай районындагы татар авылы. Атама борынгы төрки телдә берничә мәгънәдә кулланылган. Борынгы формасы *Batur* [ДТС, 1969, с. 89].

Әлки районындагы Иске Баллы Күл авылы татарныкы, Яңа Баллы Күлдә татарлар да, руслар да яши. Атаманың *баллы* элементы борынгы төрки телдә булган. Борынгы төрки сүзлектә «*bal*» (мед) формасы китерелә [ДТС, 1969, с. 86].

Бибай Чаллысы авылы Әлки районында урнашкан. Атаманың «Бибай» элементы борынгы төрки телгә нисбәтле булырга мөмкин. Борынгы төрки сүзлектә бу исемне тапмасак та, анда охшаш вариантлар китерелгән: *beg bars*, *beg buju*, *begcur*, *begtas*, *beg temir*, *bars beg* [ДТС, 1969, с. 91]. Исем ике кисәктән тора: *Би+бай*. Гадәттә ике элемент та башка компонентлар белән яңа исемнәр ясыйлар. Бу очракта сыйнфый катламның ике титулы бергә килеп бер исем ясаганнар.

Бахта – Чистай районындагы татар авылы. Бахтино дигән авыл Мари республикасының Новоторьянский районында да бар. Бу атаманы Р.И. Куряева Бахтин дигән рус фамилиясенә нисбәтли. Фамилия чуваш телендәге мәҗүси Бахти, яки татар телендәге Бахтый исеменнән ясалган [Куряева, 1992, с. 202]. Борынгы төрки сүзлектә *бахты* сүзе «бәхет» мәгънәсендә күрсәтелгән [ДТС, 1969, с. 89]. Татарларда бүгенге көндә дә Бәхтияр исеме еш очрый. Авылга исем борынгы төрки телгә караган елга атамасыннан бирелгән.

Алексеев районында Гоголиха дигән рус авылы бар. Шундый ук исемдәге авыл Чувашстанның Козловский районында да бар. Пенза өлкәсенең Земетчинский һәм Белинский районнарында Гоголев атамалы авыллар бар. Ойконимнарның нигезендә танылган рус фамилиясе ята. Фамилия кош исеменнән алынган.

Кошның исеме күп кенә славян телләрендә (рус, украин, чех, поляк һ.б.) дә очрый. Гоголь сүзенең төгәл этимологиясе әлегә төгәл ачыкланмаган. Без атаманы борынгы төрки телгә нисбәтлибез. «Гоголь» сүзенә яңгырашы ягыннан охшаган сүзләр: төрки телдә «гогул», кыргызда «когол», якутларда «когуллаах», шор телендә «когулас», бараба татарларында «кугулдий», тобол татарларында «куголчин», татарларда «күгәрчен». Китерелгән мисалларның барысын да борынгы төрки *когул=когал-гогол* сүзенә кайтарырга мөмкин. Сүзнең тамыры – *кок=гок* [Баскаков, 1979, с. 76].

Дүртөйле – Чистай районындагы татар авылы. Төрки телләрдә саннар системасы үзенең тотрыклылыгы белән игътибарны җәлеп итә. Мең ел элек кулланылган санау системасы әллә ни үзгәреш кичермәгән. Борынгы төрки телдә «дүрт» сүзенең фонетик яңгырашы «төрт» булган [ДТС, 1962, с. 581].

Аксубай районында Барское Енорускино, Удельное Енорускино авыллары бар. Ойконимның нигезендә чуваш телендәге Енарас мәҗүси исеме ята. Енарас исеме үзе татар диалектларында очрый торган Януразантропонимыннан алынган. Аның әдәби формасы – Янгураз. Исем борынгы төрки «яңа» сыйфатыннан һәм борынгы төрки *ураз/оруз* (бәхет) сүзеннән ясалган.

«Иске» һәм «яңа» сыйфатлары географик атамалар ясауда бөтен дөньяда катнашалар. Безнең регион да бу кагыйдәдән чыгарылма булып тормый. Көнбатыш Кама аръягында «иске» сүзе белән ясалган ойконимнар саны 31:

1. Иске Чуваш Әдәмсуы
2. Иске Мукшы
3. Иске Савруш
4. Иске Ибрай
5. Иске Илтерәк
6. Иске Кыязлы
7. Иске Кәрәмәт
8. Иске Татар Әдәмсуы
9. Иске Үзи
10. Иске Мулла иле

11. Иске Ямкино
12. Иске Үргәагар
13. Иске Баллыкүл
14. Иске Алпар
15. Иске Камка
16. Иске Матак
17. Иске Такталы
18. Иске Салман
19. Иске Кората

20–21. Иске Чаллы. Бу регионда ике авыл Иске Чаллы атамасын йөртә.

22. Иске Әмзә
23. Иске Иглай
24. Иске Әлмәт
25. Иске Авыл
26. Иске Рәҗәп
27. Иске Котыш
28. Иске Әлмәле
29. Иске Кади
30. Иске Үтәмеш
31. Иске Роман

«Иске» сүзе борынгы төрки телдә дә, хәзерге төрки телләрнең барысында да диярлек очрый: *эски* (ески), *иске* «старый» мәгънәсендә күп торак пунктлар атамалары составына керә. Мәсәлән, Төрекмәнстанда *эсги/эски* сүзе белән дүрт топоним бар: Эсгиарык, Эсгихоша һ.б. [Атаниязов, 1980, с. 327]. Башкортстанда «иске» сыйфаты белән ясалган 192 топоним бар: Искеболоклы, Искекамышлы, Искеуслан, Иске Валькино, Иске Ивановка [СТБ, 1980, с. 58–65, 185–195].

«Яңа» сыйфаты белән ясалган топонимнар «иске» сыйфаты белән ясалган топонимнарга караганда күп тапкыр артыграк. Чөнки бер «иске» авылдан берничә «яңа» авыл аерылып чыгарга мөмкин.

Казакстанда «ески» сүзе белән ясалган топонимнар өчәү: Ескитам, Ескимама, Ески-Камыслыбас [Титова, 1960, с. 17–18].

Азәрбайҗанда «иске» сүзе урынына «кохне» сүзе кулланыла, фарсы телендә «коһне» сүзе «иске» мәгънәсен белдерә. «Кохне» сүзе белән монда биш торак пункт бар: Кохне-Кышлак, Кохнекала, Кохнекенд һ.б.

Әлки районында Йолдыз дигән татар-рус авылы бар. «Йолдыз» формасында бу сүз татарныкы, борынгы төрки телдәге формасы «йулдуз». Йолдыз исеме татар-рус авылы Спас районында да бар.

Спас районында Урманасты Йорткүл, Урта Йорткүл, Кырый Йорткүл атамалы татар авыллары бар. Атамаларны тулы составлары белән борынгы төрки телгә нисбәтлибез. «Йорт» элементы борынгы төрки телдә дә актив кулланылышта йөргән. Бу сүзнең мең ел элек булган формасы бүген дә артык зур үзгәреш кичермәгән: *Jurt* [ДТС, 1962, с. 282].

Илюткино – Норлат районындагы рус-чуваш авылы, атамасы Илләт гидронимыннан алынган. Илләт елгасы Мари Эл һәм Татарстан җирләреннән ага. Агымның кайбер тирәләрендә катнаш, ә күпчелек җирендә ылыслы урманнар үсә. Илләт буйлары – бабаларыбыз яшәгән төбәк. Чөнки бу тирәләрдә мари географик атамаларының иң түбәндәге катламын төрки атамалар тәшкил итә.

1. Илләт сүзе ни аңлата? *Салман* топокомпоненты татар теленең Чистай сөйләшендә кулланыла торган *салман* (балчык кирпеч) сүзенә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән булуы мөмкин.

2. *Салман* топокомпонентының татарларга гарәп теленнән кергән Салман (Сәлмән) исеменә мөнәсәбәтле булуы да бар.

3. Салманның борынгы төрки татар кеше исеме булып, төзелеше буенча *сал* һәм *ман* (мән-мин-кеше) компонентларыннан тору ихтималы бар [Саттаров, 1973, б. 96]. Без өченче вариантны якынрак күрәбез.

Мәҗүси чуваш исемнәре арасында Салмандайның булуы, һичшиксез, игътибарны үзенә җәлеп итә [Магницкий, 1905, с. 72], ник дигәндә, мәҗүси чувашларның исемнәренең күбесе борынгы төрки чордан килә. Салман исеме кумыкларда да бар.

Бездә Салманов фамилиясе Салман исеменнән барлыкка килгән. Бу исемнең Салмай, Салмуш, Салук һәм башкалар кебек фонетик вариантлары бар. Болардан Салмаев, Салмушев, Салмыев фамилияләре ясалган. Мондый фамилияләр күбрәк көнбатыш диалект вәкилләре арасында очрый.

Салман суы – Актайга сул яктан килеп кушыла. Елга үзенә атаманы авыл исеме Салманнан алган.

Иске Салман авылы янында археологлар Болгар, Алтын Урда чорларына мөнәсәбәтле каберлек һәм авыл хәрабәләре, Салман авылы янында борынгы болгар заманнарына караган табылдык әйберләр билгеләгәннәр.

Чистай районында Рус һәм Татар Сарсазы авыллары бар. *Саз* сүзе Татарстан җөмһүриятендә унике авыл исемендә урын ала.

*Саз* һәм *сас* сүзләре борынгы төрки телдә дә кулланылышта йөргән. Бүгенге кыргыз һәм казак телләрендә *сас-саз*, венгр телендә *sar-sarat*.

Атаманың беренче компоненты «сар». Бу сүзнең этимологиясен төрле галимнәр төрлечә аңлаталар.

*Сара/сары/сар* сүзе дөньядагы күп халыкларның телендә очрый. Иран телләрендә бу сүз *систа* мәгънәсен, гарәп телендә *шатлыклы, көлүчән,* таҗик телендә *иң яхшы*, борынгы яһүд телендә *ханым, госпожа*, якут телендә *итек,* Оренбург татарлары телендә акч*а,* төрле телләрдә *сары төс,* фин-угыр телләрендә *сазлык* мәгънәләрен бирә.

Профессор Ф.Г. Гарипова Сарсаз атамасын *сары* һәм *саз* сүзләреннән тора дип карый: *сар* төрки телләрдә *сары* мәгънәсен белдерә, чаг: Царицын, төркичә *сарычин* – сары су, Саратов – төркичә сары тау [Гарипова, 1994, б. 172]. «... Бу атама, – дип яза профессор Г.Ф. Саттаров, – угыз яки болгарларның *сар-саз* һәм Казан татарларының шуңа мәгънәдәш *саз* сүзләрен бергә кушу нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Ул *саз+саз* конструкциясен тәшкил иткән хәлдә сарсаз мәгънәсенә ия, ягъни анда ике мәртәбә саз төшенчәсе кабатлана» [Саттаров, 1992, б. 38]. Биредә угыз, болгар, татар телләре мисалында *р-з* аваз-

лары тәңгәллеге (ротацизм) күренеше белән очрашабыз: *сар+-саз=саз*.

И.К. Инжеватов «Этимология мордовских топонимов и гидронимов с компонентом *сар*» мәкаләсендә болай дип яза: «... Чынлап та төрки телләрдә *сары* сүзе еш очрый. Ләкин күп кенә төрки телләрдә бу сүз сары ком, сары таулар, сары үсемлек мәгънәләрендә Урта Азия һәм көньяк-көнчыгыш Азиядә очрый. Мондый этимология фин-угыр (шул исәптән татарлар да. – *О.Х.*) яшәгән урманлы, яшеллекле, урман-сулы территория өчен дөрес була алмый. Бу сүзне тудырган табигый шартлар фин-угырлар яшәгән җирләрдә хәзер дә яхшы сакланганга күрә, *сары* сүзе аларда хәзер дә актив кулланылышта йөри. Төньяк-көнбатыш фин-угыр халыклары сүзлегендә *сары* сүзенең зур сазлыклар, сазлыклы елгалар мәгънәсе күрсәтелгән [Инжеватов, 1974, с. 4, 192–195].

Без дә, Сарсаз атамасы борынгы төрки-фин-угыр телләренең уртак ойконимик истәлеге, дигән фикердә торабыз. Сарсаз топокомпоненты белән түбәндәге авыл атамалары ясалган: Сарсаз (Буа районы), Сарсаз-Бли (Түбән Кама районы), Сарсазтау, Сарсаз тау (Минзәлә районы), Сарсаз-Баграж (Тукай районы), Свердлов өлкәсенең Красноуфим районында Беренче Сарсы һәм Икенче Сарсы исемле авыл атамалары бар. Сар элементы белән түбәндәге топонимнар ясалган: Саранск, Сара, Саргилка, Инсаровна, Соранка, Засарье, Инсар. Аксар – Зәй кушылдыгы. Аның янына Аксар авылы урнашкан. Аксар-Аксары чуваш мәҗүси исемнәре арасында бар. XV–XVI гасырларга караган кабер ташы язмаларында Аксар исеме табыла. Мари Эл республикасында Олы Аксарка һәм Кече Аксарка авыллары, Башкортстанда Аксары авылы бар. Пермь краеның Камышлы төбәгендә Аксариха авылы атамасы очрый. Чиләбе өлкәсендә Аксар районы теркәлгән. Татарстандагы Сарман районы атамасы да шушы сүзгә нисбәтле булырга мөмкин.

Без югарыда Көнбатыш Кама аръягында яшәүче халыкның күп милләтле булуын әйтеп киткән идек. Бер үк атамалы авыллар берничә очрый, аларда төрле милләт кешеләре яши. Шуңа

күрә аларны бер-берсеннән аеру өчен атамалар составына «татар», «рус», «чуваш», «мордва» кебек этнонимнар керткәннәр. Бу регионда татар этнокомпоненты белән ясалган унсигез ойконим бар:

1. Татар Сөнчәлесе (Аксубай районы)
2. Иске Татар Әдәмсуы (Аксубай районы)
3. Яңа Татар Әдәмсуы (Аксубай районы)
4. Югары Татар Майнасы (Алексеев районы)
5. Татар Суыксуы (Әлки районы)
6. Татар Мулла иле (Әлки районы)
7. Татар Шәпкесе (Әлки районы)
8. Татар Әхмәте (Әлки районы)
9. Татар Чиябашы (Әлки районы)
10. Татар Борнае (Әлки районы)
11. Иске Татар Әлмәте (Норлат районы)
12. Татар Такталысы (Спас районы)
13. Татар Гадельшасы (Чистай районы)
14. Татар Баганалысы (Чистай районы)
15. Татар Ялтаны (Чистай районы)
16. Татар Сарсазы (Чистай районы)
17. Татар Талкышы (Чистай районы)
18. Татар Утяшкиносы (Яңа Чишмә районы)

*Татар* этнокомпоненты иң күп кулланылган районнар – Әлки (алты атамада) һәм Чистай (биш атамада) районнары. Чирмешән районында исә бу компонент белән бер генә атама да ясалмаган.

А.И. Еремия *татар* сүзен Молдова ойконимнары арасында да таба: Татар-Копчак, Татарка [Еремия, 1982, с. 37]. Татар этнонимы Полтавадагы һәм Карпат янындагы утыз торак пункт атамасы составында кабатлана: Татары, Татарынци, Татаривка, Татарка һ.б.

*Татар* сүзенең этимологиясе турында күп хезмәтләр язылган, һәр галим бу этноним турында үз фикерен әйтергә тырышкан. Шуңа күрә бу өлкәдә нииндидер яңа сүз әйтү авыр. Без бары тик бу атаманы төрки телгә нисбәтләү белән чикләнәбез.

Г.Ф. Саттаров «татар» сүзе иран телендәге *тат* – «чит кеше» һәм борынгы төрки *ар=эр=ир* – «кеше, ир» сүзләреннән тора дип саный [Саттаров, 1980, с. 32–49]. Н.А. Баскаков төрек телендәге *татар* сүзен «гонец, посланец» мәгънәсендә китерә. Татар сүзе VIII гасырдагы орхон язмаларында ук бар, дип күрсәтә һәм, Казан татарлары бу атаманы Алтын Урда хәрби җитәкчесе Ногайның этисенең исеме Татарадан алганнар, дип саный [Баскаков, 1979, с. 122].

Борынгы төрки сүзлектәге *токуз татар* сүзтезмәсе «монгол кабиләләренең берләшмәсе дип аңлатыла [ДТС, 1969, с. 541, 578]. Татар сүзе турында сөйләгәндә Н. Остроумовның бу турыдагы фикере белән танышып китү урынлы булыр: «Татарлар (кытайча татань) Байкал күле буендагы яшәгән зур, көчле кабилә булган. Алар көнчыгыш Себердә, Кытай чикләре янында яшәгәннәр һәм инде XI гасырда ук билгеле булганнар. Чынгызхан династиясе вакытында, кытайларның җиңел кулыннан, бу атама Чынгызханга буйсынган бөтен кабиләләргә кушыла. Соңрак Чынгызхан империясенә кергән барлык халыкларга бирелә. Алтын Урда җимерелгәннән соң да аерым Казан, Әстерхан, Кырым ханлыклары үзләрен татарлар дип йөртәләр. Хәзерге вакытта без руслар төрки кабиләсенә кергән һәм ислам тоткан һәр халыкны татар дип карыйбыз. Бу халыклар үзләре исә үзләренең татар булмаган, ягъни монголларга хәтле булган исемнәрен, вакытларын яхшы хәтерлиләр» [Остроумов, 1876, с. 9].

*Татар* сүзе борынгы рус телендә беренче тапкыр 1223 елда теркәлә.

Тарханка – Аксубай районындагы чуваш авылы. *Тархан* сүзе кергән атамалар төрки дөньяда да, рус территориясендә дә киң таралган. Балык Бистәсе районында Тархановка авылы, Мордва республикасының Иколковский районында Тарханова исемле авыл бар. Моннан тыш тагын Краснодар өлкәсендә Тарханка исемле торак пункт, Кашкадарья өлкәсендә Дархан торак пункты, Ульяновск өлкәсенең Тарханка елгасы буенда Большие һәм Малые Тарханы авыллары, Саратов өлкәсендә

Тарханы, Мәскәү өлкәсендә Тархан сазлыклары, Керчь янындагы кыяларга да Тархан исеме кушылган [Мурзаев, 1996, с. 167].

«Тархан» сүзен борынгы төрки телгә, монгол һәм чуваш телләренә нисбәтләүчеләр бар. Лексик-семантик бәя бирүдә дә төрлелекләр бар. Алар белән без икенче бүлектә танышырбыз. Безнең фикеребезчә «тархан» сүзе борынгы төрки телгә нисбәтле. Борынгы төрки сүзлектә бу сүзнең *tarqon*, *tarxan* формалары күрсәтелә [ДТС, 1969, с. 538–539].

«Тархан» сүзе «торхань» формасында борынгы рус теленә дә кергән [Ушаков, 1938, т. 4, с. 656; Шипова, 1976, с. 310]. В.И. Волков үзенең «Край родимый Аксубай» исемле китабында «тархан» сүзен чуваш теленә нисбәтли һәм беренчел формасы итеп «таркан» сүзен китерә [Волков, с. 103].

Әлки районында Татар Төгәлбае һәм Рус Төгәлбае исемле авыллар бар. Бу атама борынгы төрки Төгәлбай исеменнән алынган, дигән караштa торабыз. Борынгы төрки сүзлектә *tukal* сүзе китерелгән [ДТС, 1969, с. 595]. Бу сүзнең кеше исеме булып йөрүе дә күрсәтелгән һәм *Tukalqara* (кеше исеме) мисалы китерелгән. Г.Ф. Саттаров та бу атаманы борынгы төрки телгә нисбәтли [Саттаров, 1973, б. 99]. Төгәлбай исеме *төгәл* + *бай* сүзләре кушылу юлы белән ясалган. Төгәлбайның синонимы булган Тулыбай исеме безнең республикада Тулбай (Минзәлә һәм Мамадыш районнарында) авыллары атамасына әверелгән. Борынгы төрки телдә Төгәлбота (*төгәл* + *бота* – дөя баласы) кебек башка шундый исемнәр булган.

Әлки районындагы Ташбилге дигән чуваш-татар авылы атамасының килеп чыгышы Ташбилге елгачыгы исеменә нисбәтле. Бу елгачыкның үз атамасының килеп чыгышы исә Ташбилге дигән борынгы төрки кеше исеменә мөнәсәбәтле булырга тиеш [Саттаров, 1973, б. 98].

Ташбилге исеме *таш* + *билге* компонентларыннан торган кушма төзелеш тәшкил итә. Таш компоненты борынгы төрки кеше исемнәре составында актив кулланылышта йөргән. Мондый исемнәргә Таш, Ташбай, Ташбулат һәм башкаларны мисал итеп китерергә мөмкин. *Билге* компоненты белән ясалган

атаклы исемнәрнең берсе – Билге каган исеме; борынгы төрки телдә бу сүзнең формасы *bilga* [ДТС, 1969, с. 99].

Идел-Кама болгарларының башкаласы Болгар шәһәреннән ерак булмаган Ташбилге авылында XVI гасырда Хисаметдин бине Шәрәфетдин Мөслими үзенең «Тәварихы Болгария» дигән атаклы тарихи әсәрен язган. Үзенең туган авылы турында әлеге хезмәтендә ул: «Безнең Мөслим бабамыз, ыругы исән, Ташбилге елгасына төшеп, Ташбилге ауыли булдый», – дигән мәгълүмат бирә.

Ташбилге исеменең борынгы төрки йола исеме булуы һәм хәзерге татар исем-фамилияләрендә бөтенләй урын алмавы шушы исем белән аталган Ташбилге авылының чал тарихлы икәнлеген раслый.

Норлат районында Төрнәс һәм Төрнәче исемле чуваш авыллары бар. Бу ике авылның да атамасы бер тамырга нисбәтле. Без бу ойконимнарны борынгы төрки-чуваш уртак ядкяре итеп карыйбыз. Борынгы төрки сүзлектә *turna* «соры торна» сүзе теркәлгән [ДТС, 1969, с. 588], татарча – торна. Төрнәс атамасы ике компоненттан тора – *торн*а + *яз* – «кыр, поле». Шулай итеп Төрнәс атамасы «торна кыры, басуы» мәгънәсен бирә. Шул ук мәгънәдә «торна» сүзе «турае» формасында мари теленә дә кергән [Марийско-русский словарь, 1956, с. 601].

Спас районындагы Тамкеевка һәм Тамино исемле рус авылларының атамалары борынгы төрки телдәге *tampaci* – «ясак җыючы», *tompa* – «печать, билге, тамга» сүзләренә нисбәтле булырга мөмкин [ДТС, 1969, с. 530]. Бу сүз түбәндәге хезмәтләрдә очрый: тамгалык [Боровков, 1963, с. 283], тамга [Изысканный..., 1978, с. 387], тамга [Муталлибов, 1968, с. 253] һ.б. Бүгенге көндә дә бу сүз татар, башкорт, караим, үзбәк һ.б. телләрдә кулланылышта йөри.

Аксубай районындагы Уткино, Чистай районындагы Утяково рус авыллары бар. Авыл атамалары Утка сүзеннән ясалган. Бу сүз үзе исә татар теленең *үтәк* сүзеннән фонетик вариация булып тора. Зур Өтәк исемле авыл Яшел Үзән районында да бар. Авыл атамалары Үтәк елгасы исеменнән алынган дип

уйлыйбыз. Үтәк елгасы – Иделнең сул кушылдыгы. Х гасырда аның башланган урыннарында – Суар каласы, ә түбәнге агымында – урлар белән әйләндереп алынган, аерым урыннарда хәрабәләре әле дә сакланып калган Зур Болгар шәһәре Күкрәт (Кокреть) шаулап утырган. Үтәк (Утка) язу кенәгәләрендә һ.б. тарихи чыганакларда очрый.

Болгар җирендә Ибне Фадлан тарафыннан телгә алынган әлеге елганы А.П. Ковалевский Утка суы белән бәйләп карый һәм аны «Ватыг» дип укый. Кабер ташларына язылган язмаларны укыганда сүз башында w урынына *о, ө, у, ү* язу мөмкинлеген искә алып, бу атаманы Ф.Г. Гарипова «Отыг» рәвешле уку кирәклеген әйтә. Атаманың үзгәрүе, ихтимал, әлеге юнәлештә баргандыр: *Отыг – Өтәг – үтәг* [Гарипова, 1994, б. 123].

Әле Болгар чорларында ук шушы исемдәге кала булуы мәгълүм. Аның хәрабәләре Татарстанның Яшел Үзән районындагы Зур Өтәк авылы янында сакланган. Бу хакта К. Насыйри: «Үтәк каласына игендер вә башка төрле малдыр җыеп илтүчеләр, байлар күп булгандыр», – дип яза. Зөя елгасының урта агымындагы Өтәк авылы янындагы шәһәрлекне С.М. Шпилевский искә алып үтә [Гарипова, 1994, б. 123].

Зур Өтәк авылы янында борынгы болгар чорына нисбәтле шәһәр һәм авыл хәрабәләре таптылар. Яшел Үзән районындагы элекке Үтәк шәһәре урыныннан ерак түгел Кече Үтәк (Тенибяково һәм Өтәк) Утяково авыллары бар. Шушы ук елга археологлар тарафыннан искә алынган, Олы Бахта елгасының уңъяк ярында, хәзерге Өтәк авылыннан ярты чакрым төньяк-көнчыгыш якта урнашкан борынгы Болгар чоры шәһәре Өтәк каласы хәрабәләре дә керә.

Тюркологлар бу атаманы төрки кеше исеме Утак белән бәйләп карыйлар. Чуваш телендәге формасы – Отяк [Магницкий, 1905, с. 63]. Г.Ф. Саттаров бу исемне борынгы төрки телдәге *отак* – «бурыч» [ДТС, 1969, с. 392] сүзенә нисбәтли. Күктән озак сораганнан соң дөньяга килгән балага кушыла, дип саный [Саттаров, 1981, б. 246]. Э.В. Севортян, *отак* сүзе *ота* фигыленнән ясалган, дип күрсәтә [Севортян, 1974, с. 169].

Борынгы төрки *ота* сүзенә барып тоташкан тагын бер атама – Яңа Чишмә районындагы Татар Утяшкиносы авылы исеме. Шундый ук исемдәге авыл Зәй районында да бар. Яшел Үзән районындагы авылның атамасы Утяшки. В.К. Магницкий ойконимны татар-чуваш Үтәш исеме белән бәйли [Магницкий, 1905, с. 89]. Бу исем шулай ук Отеш формасында үзбәк, казак телләрендә дә очрый. Утяша формасында мордва теленә дә кергән.

*Урман* сүзе төрле фонетик формаларда төрки халыкларның күбесендә очрый, борынгы төрки сүзлектә дә китерелгән [ДТС, 1969, с. 103]. Без тикшергән регионда дүрт авыл атамасы составында урман сүзе бар: Аксубай районында Үрмәндәй авылы, Алексеев районында Урманасты Шонталасы, Спас районында Урманасты Йорткүле, Чирмешән районында Урманасты Үтәмеш. Урмандәй авылында чувашлар яши, калган авылларда – татарлар.

Урман сүзе белән күп топонимнар ясалган: Пермь краенда Урман-Куль торак пункты, Башкортстанда Урман, Оренбург өлкәсендә Урман елгасы, Төмән өлкәсендә Обь елгасы буенда Урманный поселогы, Кырымда Урман-Усту һәм Орман-Кош таулары, Караганда өлкәсендә Орман торак пункты, Төркиядә Орманлы торак пункты бар. *Урман* сүзе ике компоненттан тора: *ор/ар* һәм *ман*: *ор/ар* – «тау, калкулык» мәгънәсендә [Мурзаев, 1996, с. 148–149]; *ман* сүзенең берничә мәгънәсе китерелә. Шулар арасында *урман* һәм *кеше* мәгънәләре бар [Камалов, 1973, с. 203].

Урмандәй атамасының *-дәй* формантасы турында төрле каршылыклы фикерләр бар. Башкорт ономасты А.А. Камалов болай дип яза: «Многие форманты типа *-тай, -дай, -зай* (Юртай, аратай, боландай, түбәтәй )... по существу представляют собой древние башкирские оронимические термины со значением „гора, камень“, формы которых восстанавливаются сравнительно-историческими исследованиями» [Камалов, 1973, б. 203].

В.Ф. Барашков исә бу формантаны монголизмнарга кертеп карый һәм мисал итеп түбәндәге атамаларны китерә: Конадай, Субәдәй, Угәдәй, Мәргидәй, Хондәй һ.б. *-тай/-тәй, -дай/-дәй* суффикслары монгол телендә сыйфатлар ясауда бүген дә киң кулланыла дип күрсәтә [Барашков, т. 3, 1973].

Безнең фикеребезчә, бу атаманы башкорт теленә генә нисбәт итү дөрес булмас иде. Бу форманта татар телендә дә очрый. Төрки телләрдә актив очрагач (Актай, Каратай, түбәтәй, Урмандәй), монгол теленә генә нисбәтләп калдыру да дөрес булмас иде. Ихтимал, бу форманта уртак төрки-монгол истәлегедер. Без шул фикердә торабыз. Формантаның берничә лексик мәгънәсе бар. Алар белән без икенче бүлектә танышырбыз.

Чистай районында Олы Талкыш, Кече Талкыш, Урта Талкыш рус авыллары һәм Татар Талкышы авыллары бар.

Һ.В. Йосыпов болгар эпитафикасында Талкыш исеме булуын күрсәтә [Юсупов, 1970, с. 251]. В.К. Магницкий да мәҗүси чуваш исемнәре арасында Талкышны күрсәтә [Магницкий, 1905, с. 84]. Г.Ф. Саттаров Талкыш кушаматы аерым бер шәхескә бик вакчыл булганлыгы өчен кушылган ди [Саттаров, 1973, б. 155–156]. Бу сүз борынгы төрки сүзлектә дә китерелә: *talkis* – «валять войлок» [ДТС, 1969, с. 529]. Димәк, атаманың тамырлары борынгы төрки телгә үк барып тоташа. Борынгы төрки телдә бу сүз әле кеше исеме буларак кулланылышта йөрмәгән күрәсең, һәрхәлдә сүзлектә күрсәтелмәгән. Кеше исеме буларак, ул болгар чорында кулланыла башлаган булса кирәк. Бу атаманы борынгы төрки-болгар-татар-чуваш уртак истәлеге итеп карау ягында торабыз.

Алексеев районында Кызыл Уракчы исемле татар авылы бар. Кызыл компоненты бу очракта Октябрь революциясенең символик төсе буларак кулланылган. Ә менә *Уракчы* сүзе борынгы төрки телгә үк барып тоташа. Уракчы сүзе *урак* + *чы* сүз ясаучы кушымчасыннан тора. Урак сүзе борынгы төрки сүзлектә китерелгән: *orjak* – «серп» [ДТС, 1969, с. 370]. *-чы, -че* кушымчасы татар телендә сүз ясауда нәтиҗәле кулланылса да, географик атамалар барлыкка китерүдә актив түгел: Йаңгырчы суы – Уратма елгасы (Зәй районы), Сукачы күле – Яуширмә суы бассейнындагы сулык (Чистай районы), Балыкчы суы – Үтәк елгасы кушылдыгы һ.б. Бу аффикс кергән антропонимнар борынгы төрки рун язма истәлекләрендә дә теркәлгән. Татар шәҗәрәләре исемлегендә М.И. Әхмәтҗанов шушындый антро-

понимнар билгеләгән: Туйчы, Яңгырчы, Кугачы, Алгачы һ.б. [Гарипова, 1994, с. 88].

Төрки халыклар яшәгән җирләрдә *-чы, -че* аффиксының кулланылыш дәрәҗәсе төрлечә. Шор һәм азәрбайҗан топонимиясендә бу кушымча белән ясалган географик берәмлекләр күп очрамый, ягъни ул топонимнар ясауда продуктив түгел. Чистай районында да Уракчы дигән татар авылы бар.

«Урта» сүзе бөтен төрки телләрдә дә кулланылышта йөри. Чүлдә дисеңме, кырдамы, даладамы төркиләр кояшка, йолдызларга карап кирәк җирләренә юлны оста тапканнар. Моннан тыш алар җирле географик объектлар ярдәмендә дә ориентлашканнар. Объектларның биеклегенә (югары, түбән), урнашу урынына (кырый, урта), үлчәме буенча (зур, кече), ясалу вакытына карата (иске, яңа) атамалар да кушканнар.

«Урта» сүзенең борынгы төрки телдәге формасы *orta* – «середина, средний». Без тикшергән регионда бу сүз белән җиде атама ясалган:

1. Урта Тигәнәле (Аксубай районы)
2. Урта Әлки (Әлки районы)
3. Урта Биктимер (Әлки районы)
4. Урта Камышлы (Норлат районы)
5. Урта Чаллы (Норлат районы)
6. Урта Йорткүл (Спас районы)
7. Урта Талкыш (Чистай районы)

Азәрбайҗанда Ортакенд, Ортакишлак, Ортасахахлы торак пунктлары бар. Дагыстанда Ортатобе; Орта Дересен – Джупаран өлкәсендә, Мангышлак өлкәсендә Ортаэспе, Талуы-Курган өлкәсендә Ортаузек, Якутиядә Орта-Балаган, Карын өлкәсендә Орто-Сырт, Ыссык-Күл өлкәсендә Орто-Токай, Ош өлкәсендә Орто-Кыштак һәм Орто-Мечит, Үзбәкстанда Уртааул, Уртасарай, Уртасалча, Ортатугай торак пунктлары бар. Башкортстанда топонимнар сүзлегендә «урта» сүзе белән 24 ойконим һәм гидроним китерелгән: Уртааул, Уртакуль, Уртаана һ.б. [СТБ, 1980, с. 155–156].

Чирмешән районында Урманасты Үтәмеш һәм Иске Үтәмеш авыллары бар. Авыл атамасы *үтә* сүзенә *-мыш* сыйфат фигыль кушымчасы кушып ясалган. Атаманы борынгы төрки телгә нисбәтлибез. *-мыш,-меш* кушымчасы хәзерге татар әдәби телендә сүз ясау өчен кулланылмый һәм шулай ук яңа топонимнар да барлыкка китерми торган (нәтиҗәлелеген югалткан) кушымчалар рәтенә керә. Бу кушымча хәзерге көндә сүзнең составында гына сакланган. Бөкмеш башы Мишә кушылдыгы, Армыш, Тумыш – Казан елгасы кушылдыклары. Ф.Г. Гарипова атаманы борынгы төрки телгә нисбәтли. «Борынгы төрки телдә *-мыш, -меш* сүз ясаучы һәм сүз төрләндерүче кушымча булган» [Гарипова, 1994, б. 86]. *-мыш, -меш* кушымчасы хәзерге угыз телләрендә үткән заман сыйфат фигыль мәгънәсен бирә. Бу мәгънәсе аның кыпчак телләрендә дә булган.

Тарихчы Һ.В. Йосыпов XIII–XVIII гасырларга караган болгар-татар кабер ташы язмаларында Суламыш, Еламыш, Кармыш, Батамыш, Сатылмыш, Туктамыш [Юсупов, 1960, с. 106–108] исемнәренең урын алуын яза. Бу исемнәрнең күбесенең *-ган* формасы да бар. Шушы җирлектә аларның параллель кулланылышы барлыкка килгән: Үтәгән (Үтәмеш), Караган (Карамыш), Туктаган (Туктамыш) һ.б. [Саттаров, 1973, б. 48].

Чистай районындагы Яңа Урал атамасы Урал таулары атамасына карата икенчел. Авылда татарлар яши. Урал атамасының килеп чыгышы һәм кайсы телгә нисбәтлелеге хакында төрле карашлар бар. Р.Г. Әхмәтьянов, атама угыр теленнән кергән, төрки телләрдә «урал» сүзе юк, дигән карашта тора [Ахметьянов, 1989]. Г.Ф. Саттаров фикеренчә, атама төрки телгә нисбәтле. Без дә шул фикердә торабыз. Атама борынгы төрки телдәге *орү, ур* тамырына мөнәсәбәтле [ДТС, 1969, с. 388]. Атаманың лексик мәгънәсе турында да бәхәсләр, каршылыклы фикерләр күп. Алар белән икенче бүлектә танышырбыз.

*Ор/ур* тамырына нисбәтле тагын бер атама – Әлки районындагы Яңа Үргәагар һәм Иске Үргәагар авылларының атамасы. Үргәагар сүзе ике элементтан тора *ургә + агар*. Борынгы төрки «үр» сүзенә *-гә* юнәлеш килеш кушымчасы кушылган.

*Ага* сүзенә киләчәк заман хикәя фигыль формасы *-р* кушылып «агар» компоненты ясалган.

«Ак» сүзе борынгы төрки телдә төсне генә аңлатып калмыйча, «агу, течь, протекать» мәгънәле фигыль ролендә дә килгән [Севортян, 1974, с. 119]. Шушы мәгънәсе белән күп кенә гидронимнар ясалган: Себердәге Терсахан, Акан, Агынакты, Суакынсай елгалары шуңа мисал [Мурзаев, 1996, с. 119]. Кайбер галимнәр [Койчубаев, 1974, с. 24–25] шушы ук рәткә Аккуль, Акозек, Аксу, Аксай атамаларын да кертеп карыйлар.

Чулпан – Норлат районындагы татар-рус авылы. Шул ук исемле авыл тагын Арча районында да бар. Югары Ослан районында Чулпаниха атамалы рус авылы бар. Ойконимның нигезендә төрки Чулпан дигән кеше исеме ята. Бу исем XVI–XVII гасырларда казан татарлары арасында ир кеше исеме буларак актив кулланыла башлый [Саттаров, 1981, б. 212]. Христианлаштыруга хәтле вакытта мордваларга да үтеп кергән.

Чирмешән районының исеме үзәге Чирмешән авылы исеменнән алынган. Бу ойконим исә Олы Чирмешән елгасы исеменә мөнәсәбәтле. Хәзер район үзәге булган Чирмешән авылы шул елга буена урнашканга Чирмешән дип аталган.

Ике Чирмешән атамасының һәрбере Г. Кандалый әсәрләрендә дә очрый [Гарипова, 1994, б. 117]. Ул төрле тарихи чыганакларда урын алган. 921–922 елларда Идел-Кама Болгарстанына Багдад хәлифәлегеннән килгән илчелек арасында булган Әхмәт бине Фадлан язмаларында ул *Carimsan* яки *Cerimsa* [Ковалевский, 1956, с. 131], рус елъязмаларында (1183) – Черемисан [Полное собрание русских летописей, 1856, с. 96], Әлки районының Ташбилге авылы янында табылган кабер ташы язмаларында Чәримсан рәвешендә бирелгән. Чирмешән тарихи актларда Казан, Самара, Сембер өязләренең торак пункт атамаларын исәпкә алу исемлегендә, тарихи-географик-статистик, тарихи-этнографик һ.б. документларда да телгә алына.

Олы Чирмешән – Идел суының сул кушылдыгы. Ул Самара, Ульяновск һәм Татарстан җирләреннән ага. Гомуми озынлыгы –

465 чакрым; Татарстан төбәгеннән аккан өлешенең озынлыгы – 160 чакрым.

Кече Чирмешән – Олы Чирмешән елгасы кушылдыгы. Ул Татарстан һәм Самара өлкәсе аша агып уза. Гомуми озынлыгы – 214 чакрым. Бу елга Олы Чирмешән суы белән параллель рәвештә ага.

Татарстан җирендә «чирмешән» сүзе белән байтак кына атамалар бар. Д.А. Корсаков тарафыннан бастырып чыгарылган чыганакта хәзерге Чистай районында Кече Чирмешән елгасы янында Чирмешән авылы күрсәтелгән. «Казан шәһәре язу кенәгәсендә» Казан артындагы Нурма суы бассейнында Чирмешән исемле авыл булуы әйтелгән һәм Д.А. Корсаков тарафыннан чыгарылган тарихи чыганакта шул ук төбәктәге Әшнәк елгасының уң кушылдыгы Чирмешән гидронимы булуы билгеләнгән. Тарихи чыганакларда хәзерге Апас районындагы Багыш исемле авылның элек өченче Чирмешән исемендә йөрүе күрсәтелә [Гарипова, 1994, б. 117–118].

Чирмешән атамасы Татарстаннан читтәге төбәкләрдә дә очрый. Карамсан һәм Чирмәсән – Башкортстандагы гидронимнар. Чирмәсән исемле кичү 1773–1775 еллардагы Пугачев хәрәкәте белән бәйләнешле документларда очрый. Элекке Пермь губернасының Верхотур өязендә Чирмешән елгасы һәм ярында Чирмешән авылы искә алына һ.б. Югарыда китерелгән барлык Чирмешән атамалары Идел-Кама болгарлары белән бәйләнешле. Чирмешән исемен Алтайда, Югары Иртыш бассейнында бер елга йөртә. Әгәр бу атама соңыннан барлыкка килмәгән булса, Чирмешән болгар чорларына кадәрге төркиләргә мөнәсәбәтле булып чыга. Шундый ерак регионнарда табылган су чыганаклары һәм торак пункт атамаларының борынгы төрки халыкларга мөнәсәбәте шик тудырмый [Гарипова, 1994, с. 119]. Борынгы төрки кабиләләр болгарлар арасына керсәләр дә, үз атамаларын югалтмаганнар, бергәләшеп гомер кичергәннәр. Чиләбе өлкәсенең Югары Уфалий районында Чирмешән исемендә шәһәр тибындагы поселок бар. Приморский краеның Дальнегорск районында да Чирмешән бистәсе теркәлгән.

Чирмешән сүзенең лексик мәгънәсе һәм этимологиясе турындагы фикерләр белән икенче бүлектә танышырбыз. Безнең фикеребезчә, Чирмешән уртак борынгы төрки-болгар сүзе. Атама *чирме* һәм *шән* сүзләреннән тора. *Чирме/чирмә* сүзе болгар теленә нисбәтле булса, *шән/шөн/сөн* борынгы төрки сүз. Күргәнебезчә, атама борынгы төрки чорга барып тоташа.

Чистай районында Чирүле Шонталысы исемле татар авылы бар. Русча исеме Служилая Шентала. *Чирүле* сүзе борынгы төрки телдәге гаскәр мәгънәсен аңлата, *-лы, -ле* борынгы телдә *-лык, -лек* кушымчасының фонетик үзгәреш кичерүе нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән [Гарипова, 1994, б. 85].

Халык сөйләвенә караганда, Чирүле Шонталысының җирләре патшага зур хезмәт күрсәткән Морат бабайга бирелгән. Аңа мөнәсәбәтле Морат бабай чишмәсе әле дә бар.

Д.А. Корсаков җыентыгында авылда 197 алпавыт крәстиәне, 32 керәшен һәм 152 йомышлы татар яшәгәнлеге күрсәтелгән [Сборник..., 1908, № 7, с. 211].

*Иске* сүзе белән ясалган атамаларны без югарыда күрсәтеп киткән идек инде. «Иске» компоненты белән янәшә йөри торган компонент – *яңа* сүзе. Искесе булгач, аның яңасы да булырга тиеш инде. Шулай да «яңа» топокомпоненты белән ясалган атамалар «иске» белән ясалганга караганда Көнбатыш Кама аръягында азрак. *Иске* сүзе белән ясалган авыл «яңа» авылга караганда регионнан читтәрәк урнашкан булырга мөмкин. Өйрәнә торган регионда «яңа» сүзе белән түбәндәге атамалар ясалган:

1. Яңа Үзи (Аксубай районы)
2. Яңа Чуваш Әдәмсуы (Аксубай районы)
3. Яңа Аксубай (Аксубай районы)
4. Яңа Ибрай (Аксубай районы)
5. Яңа Дума (Аксубай районы)
6. Яңа Кәрәмәт (Аксубай районы)
7. Яңа Татар Әдәмсуы (Аксубай районы)
8. Яңа Ямкино (Әлки районы)
9. Яңа Үргәагар (Әлки районы)
10. Яңа Салман (Әлки районы)

11. Яңа Алпар (Әлки районы)
12. Яңа Такталы (Әлки районы)
13. Яңа Чаллы (Әлки районы)
14. Яңа Чишмә (Яңа Чишмә районы)
15. Яңа Авыл (Яңа Чишмә районы)
16. Яңа Әмзә (Норлат районы)
17. Яңа Иглай (Норлат районы)
18. Яңа Тумба (Норлат районы)
19. Яңа Әлмәт (Норлат районы)
20. Яңа Рәҗәп (Спас районы)
21. Яңа Котыш (Чирмешән районы)
22. Яңа Урал (Чистай районы)

Яңа Аксубай, Яңа Дума, Яңа Чишмә, Яңа Тумба, Яңа Котыш, Яңа Урал атамаларының «иске» парлары без тикшергән регионда юк. Алар башка регионнарда урнашканнар.

*Яңа* сүзе борынгы төрки телләрнең барысында да диярлек бар: *ангы/енги/диангы/жангы* һ.б. Бу сүз белән топонимнар ясалган. Төрекмәнстанда *янгы* сүзе белән җиде атама ясалган: Янгыарык, Янгыгола, Янгыгуйы һ.б. Башкортстанда «яңа» сүзе белән 302 топоним ясалган: Яңаул, Яңаакбаш, Яңакарга, Яңа Алексеевка һ.б. [СТБ, 1980, с. 185–195]. Азәрбайҗанда *ени/енги* сүзе белән унике топоним бар: Енибад, Ениел, Енгиен һ.б. [Бушуева, 1971, с. 91].

Ямкино – Алексеев районындагы рус авылы. Мордва республикасында *ям* сүзе белән түбәндәге атамалар бар: Новоямская Слобода, Новоямские Выселки, Староямская Слобода, Ямщимо. Аларны *ям* тамырыннан ясалган дип уйлыйбыз. *Ям* сүзенең килеп чыгышы турында каршылыклы фикерләр бар. *Ям* сүзе рус теленә «почта станциясе» мәгънәсендә XIII гасырда төрки телләрдән килеп кергән. Сүзнең төрки телдән кергәнлеген Р.И. Куряева [Куряева, 1994,с. 190–191], Ә.М. Ахунҗанов, Э.М. Мурзаев [Мурзаев, 1996, с. 207] күрсәтәләр. Н.К. Дмитриев *jam* сүзе борынгы төрки сүзлектә бирелмәгән, ул монгол теленә нисбәтле, дип күрсәтә [Дмитриев, 1962, с. 554]. Ләкин бу дөреслеккә бик үк туры килми. Бәлки Дмитриев *jam* сүзенең «поч-

та станциясе» мәгънәсе юклыгын күрсәтә торгандыр. Чынлап та борынгы төрки сүзлектә *jam* сүзенең мондый мәгънәсе юк. Сүзлектә *Jam* сүзе кеше исеме буларак китерелә. Ямкино авыл атамасы «почта станциясе» мәгънәсен аңлатмыйча, кеше исеменә нисбәтле булырга мөмкин. Күпмедер дәрәҗәдә Ямкино атамасының тамыры белән Ямбакты атамасының тамырлары охшаш. Ямбакты атамасы да *ям* һәм *бакты* сүзләреннән тора. Ямбакты, кеше исеме буларак, борынгы төрки телдә үк кулланылган булса кирәк. Борынгы төрки телдәге [ДТС, 1969, с. 81] *бакты* сүзе белән Айбакты, Байбакты, Дәүләтбакты кебек исемнәр ясалган. Ямбакты авылы Спас районында урнашкан. Шундый ук исемдәге авыл Тәтеш районында да бар. Д.А. Корсаков Ямбакты авылында 240 йомышлы татар һәм ике керәшен яшәгәнлеген хәбәр итә [Сборник..., 1908, № 56, с. 198].

Болгар җирләренең үзәгендә утырганга булса кирәк, авыл оешу турындагы риваятьләрдә авыл халкы Болгар дәүләте белән бәйләнешле итеп күрсәтелә. Авылга Шәһри Болгардан килеп утырган Ямбакты нәселе кешеләре нигез салган икән. Ямбакты баба заманында Биләр, Болгар, Суар шәһәрләреннән галимнәр, шәехләр аңа зиярәткә килгәннәр. Ул заманда Болгардан Ямбактыга, Ямбактыдан Ширбәтлегә, аннан Шәһри Болгарга йөри торган юл булган. Шулай ук Ямбакты авылыннан Гәрәй хан шәһәренә, аннан Ташбилге авылына кара урман эченнән дошманнарга билгеле булмаслык итеп юл салынган. Авыл халкы атаманы гарәп теленнән кергән дип аңлата.

Ясак – Чирмешән районындагы чуваш авылы. Ульяновск өлкәсендә Ясачный Сызган, Ясашная Ташла, Ясашная Помряскино исемле авыллар бар. Борынгы төрки сүзлектә бу сүз очрамаса да, борынгы төрки телдә ул булган, дигән фикердә торабыз. Бүгенге көндә бу сүз татар телендә – *ясак*, телеут телендә – *йассак*, төрек телендә – *ясак*, чагатай телендә – *йасак* формасында бар [Фасмер, 1964, с. 564]. XV гасырда *ясак* сүзе татар теленнән рус теленә дә кергән.

Норлат районында Ялаур дигән татар-рус-чуваш авылы бар, Чистай районында Рус Ялтаны, Татар Ялтаны авыллары

бар. Ялтан һәм Ялаур атамалары икесе дә борынгы төрки телдәге *jal* тамырына [Мурзаев, 1996] мөнәсәбәтле булырга мөмкин. Топонимиядә бу сүз «ташлы калкулык» мәгънәсен бирә. *Чаг.:* монгол телендә шул ук мәгънәдә *ээл* сүзе йөри. *Боиг-Дэл-эле* топонимы бар.

Борынгы төрки сүзлектә *jugaruk* сүзе китерелә [ДТС, 1969, с. 284]. Бу сүз белән төрки дөньяда күп топонимнар ясалган. Башкорт топонимнары сүзлегендә *югары* сүзе белән 9 атама ясалган: Югары Карга, Югары Юлдаш һ.б. [СТБ, 1980, с. 174–180]. Татарстандагы гидронимнар: Югары Кымдыз, Югары Тарлау, Югары Авыл Чишмәсе [Гарипова, 1984, б. 55, 160]. Таулы өлкәләрдә бу сүз аеруча актив кулланыла. Мәсәлән, Азәрбайҗанда Юхары Андекент, Югары Зейхур, Югары Караманды, Югары Нейметабад, Югары Сакаклы, Югары Тола, Югары Кышлак һ.б.; Дагстанда Юхари Яраг; Кыргызстанда Җогары-Ак-Булат; Төркмәнстанда Екары Сумбар елгасы һәм Екары-Мугол торак пункты, Югары Топетан күле [Атаниязов, 1980, с. 270].

Без тикшергән регионда югары сүзе белән түбәндәге ойконимнар ясалган:

1. Югары Татар Майнасы (Алексеев районы)
2. Югары Колчура (Әлки районы)
3. Югары Кәчи (Әлки районы)
4. Югары Норлат (Норлат районы)
5. Югары Кәминкә (Чирмешән районы)
6. Югары Чыгтай (Чирмешән районы)
7. Югары Кондрат (Чистай районы)

Тарихтан Нугай юлы өстендәге Олы Әшнәк һәм Кече Әшнәк авылларының Казан ханлыгы чорында булуы мәгълүм.

Олы Әшнәк авылы кешеләренең XV–XVII гасырларда Кама аръягына күчеп утырулары нәтиҗәсендә хәзерге Алексеев районындагы Әшнәк (Ошняк) авылы барлыкка килгән. Тарихи чыганаклар да моны раслый.

Әшнәк елгасы һәм авылларының атамасы русча Ошняк рәвешле әйтелә һәм языла. *Ошняк* варианты атаманың борынгы формасын чагылдыра торган булса, аны составларында *аш/*

*ош* тамыры булган башка исемнәр белән бәйләү, бер семантик кыр эченә алу зарурлыгы туа. Республикабызда Ошторма, Ошма, Ушма, Ашя, Үшнә исемле елгачыклар һәм алар исеме белән аталган берничә татар, удмурт һәм рус авыллары бар. Һ.В. Йосыпов XIV гасырда куелган кабер ташларында Ашлы атамасы урын алуы, аның елъязмалардагы Ошельгә (Ош иле кабиләсе. Ош шәһәре) туры килүе, *ашлы* - *аш, -ош* тамырының байтак кына топонимнар һәм гидронимнарга хас булуы игътибарны үзенә җәлеп итүе турында яза. Ашт һәм Ош топонимнары Кыргызстанда да бар. Боларның кыргыз этнонимы «эш» белән бәйләнешле булулары мөмкин. Димәк, болгар этнонимы *ош иле* (Ашт) гомумтөрки, дигән нәтиҗә ясый [Юсупов, 1971, с. 223].

Ләкин Һ.В. Йосыпов мисал итеп китергән Ошла, Ошел-ош гидронимнары һәм топонимнарының марилар яшәгән территориядә булуы, боларның килеп чыгышын ачыклауга мари теле аша якын килергә кирәк, дигән фикергә этәрә.

Мари телендә *ош* сүзе «ак», *ошелге* – «аксыл» сыйфатын, ә *ошылык* сүзе «аклык»ны белдерә. Шушы лексик-семантик чылбыр яссылыгында караганда, Ошла (Ошлы) елгасы атамасы «Аклы», *оша-ош* гидронимы «ак» дигән мәгънәне бирә.

Татар әдәби телендәге *ошлы* «обработанный крахмалом, накрахмаленный» (мәсәлән, ошлы җеп, ошлы ситса), *ошла* (мәсәлән, киндер ошлау) сүзләренең тамыры ош мари теленнән кергән *ош – ак* сүзе булса кирәк. Сугылган киндерне көзен, кырау төшә башлагач, җиргә җәеп калдыру, киндерне кырау ярдәмендә агарту күренешен «киндер ошлау» диләр. Бу киндер агарту төшенчәсен белдерә [Саттаров, 1973, б. 105]. Биредә *ошлау* сүзенең тамыры мари телендәге «*ош*» (ак) белән бәйләнешле булуы шактый ачык.

Әшнәк авылы атамасы елгачык исеменә әверелү аркасында Әшнәк гидронимы барлыкка килү ихтималы да бар. Ул чагында гидрониим комонимнан ясалган була һәм комоним кайсы чыганакка мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килүен ачыклау зарурлыгы туа.

Әшнәк комонимының асылында Әшнәк дигән борынгы кеше исеме ятуы мөмкин. Бу исем фарсы теленнән кергән *ошна-әшнә* сүзенә *-әк* иркәләү-эндәшү антропонимик кушымчасы ялгану юлы белән *әшнә+әк=әшнәк* исеме яки кушаматы ясала ала.

Фарсы телендә *ашена* сүзе «таныш» мәгънәсен белдерә. Гаяз ага Ишмөхәммәтов фарсыдан алынган бу сүзнең татар телендә «әшнә, белеш, дус, иптәш» мәгънәсендә кулланылуын күрсәтә [Ишмухаметов, 1954, с. 46]. «Татарча-русча» сүзлектә *әшнә* сүзенең сөйләм телендә «приятель, друг, товарищ» мәгънәсендә кулланылуы теркәлгән. Әшнә сүзләре татар теленә фарсы теленнән күчкән дус һәм иптәш сүзе белән бергә аерым бер синонимик оя барлыкка китерә.

Без бу атаманы борынгы төрки телгә нисбәтлибез. Күп галимнәр шушы фикердә тора: «...тамырында *аш-ош* берәмлекләре булган атамаларның барысы да борынгы төрки «аш» этнонимына барып тоташалар. «Аш» этнонимы яши торган урыннарның үзәге Ошель – Ошлы (ош иле) булган борынгы болгар кабиләләре белән бәйләнгән» [Гарипова, 1994, б. 127].

Археолог-галим А.Х. Халиков, борынгы төрки ашина ыругы, башка төрки кабилә-кавемнәр арасында, безнең эра башларында Алтайдан Көнчыгыш Европага үтеп кергән, дип уйлый. Бу фикерне нигез итеп алып, Г.Ф. Саттаров Ашытны борынгы төрки ашина – бүре ыругы атамасының күплек кушымчасы, *-т* алган формасы дип карый. Ашина кабиләләренең бер өлеше хәзерге Татарстан төбәгенә килеп чыккан һәм андагы Ашыт елгасына үз исемен биреп мәңгеләштергән. Археолог-галимнәр А.П. Смирнов һәм С.А. Плетнева мәгълүматларына таянып, Н.Б. Борһанова Ашыт атамасын борынгы төрки-хәзәр ашын кабиләләре белән мөнәсәбәтле дип уйлый һәм, үзәкләре Ашлы шәһәре булган болгар кабиләләре дә шушы ашыннарга барып тоташа булса кирәк, дигән фикерне алга сөрә. Ашытның төрки чыганакларга мөнәсәбәтле атама икәнлеге шик тудырмый [Гарипова, 1994, б. 128].

Әлки районының исеме шушы район территориясендәге Әлки авыллары (Югары Әлки, Түбән Әлки, Урта Әлки) исе-

ме белән аталган. Әлки авылларының атамасы Әлкәй дигән борынгы кеше исеменә нисбәтле [Саттаров, 1984]. Бу исем *әл-кәй* компонентларыннан тора. Ихтимал, бу Галекәй, Галикәй исемнәреннәндер, ә бәлки *әл, эл* сүзеннәндер. Элек *әл* сүзе «кул» дигән төшенчәне белдергән һәм шушы мәгънәдә азәрбайҗан, төрек һәм башка телләрдә хәзер дә кулланыла. -*кәй* кушымчасы борынгы кеше исемнәрен ясауда актив катнашкан. Гәүдә-баш атамасына нигезләнеп ясалган кеше исемнәре борынгы теле-бездә байтак очрый: Акбит, Йөзлекәй, Акчәч һ.б. Әлкәй исеме дә шулар белән бер үк антропонимик рәт – семантик кыр бар-лыкка китерә. Составларында «әл» кул сүзе булган Тугрел яки Турел – тугры -*әл*, ягъни туры кул, Әлемгол һәм башкалар кебек исемнәр кулланылышта йөргән.

Чирмешән районы Иске һәм Яңа Әлмәле авылларының атамасы исә Әлмә исемле агач исеменә -*лы* кушымчасы кушып ясалган. Русча «ильмовый» [РТС, 1966].

Региондагы төрки атамаларга йомгак ясап, түбәндәгеләр-не әйтәсе килә. Көнбатыш Кама аръягындагы татар, чуваш, рус теленә нисбәтле саналып йөргән атамаларның күбесе борынгы төрки телгә барып тоташа.

Татар теленең үз сүзләре саналып йөргәннәренең бөтенесе диярлек, җентекләп тикшереп карасаң, борынгы телгә нисбәт-ле икән. Аларны аерып карау да авыр. Аермалыклары тыш-кы формада гына. Төрки телләрнең тотрыклылыгы турында Дж. Клоусон да язган: «Төрки телләр үзгәрүләргә аеруча тот-рыклылык күрсәтәләр. Мең ел элек кулланылган сүзләрнең үз-бәк телендә 9% ы, төрек телендә 10% ы гына тулысынча искер-гәннәр. Искәрмә булып чуваш һәм тува телләре генә тора [Клоу-сон, 1964, с. 31].

### 2.1.2. Болгар теленә нисбәтле ойконимнар

Болгар этнонимы – аның тар мәгънәсе – Болгар дәүләтен төзегән кабиләне атауга, киң мәгънәсе исә бик зур территория-дә төзелгән Болгар дәүләте эчендәге барлык төркиләрне го-мумиләштереп атауга кайтып кала. Традиция буенча Болгар

үзатамасы зыялылар арасында XX гасырга кадәр кулланылган [Зәкиев, 1998, 22 б.].

Без тикшергән Кама аръягы җирләре Идел Болгары составына кергәнлектән, болгарларның тел үзенчәлекләре җирле торак пункт атамаларында чагылыш тапкан. Бу атамаларның күбесе, әлбәттә, икенчел. Ягъни җимерелгән болгар шәһәрләренең, авылларының исемнәрен халык онытмаган, бу җирләрдә бераз соңрак барлыкка килгән авылларга шул исемнәрне яңадан кушкан. Кайбер атамалар исә елга, күл һ.б. атамалары аша яңадан безгә кайтканнар. Бу турыда Г.Ф. Саттаров болай дип яза: «Алтын Урда кенәзе Булат–Тимер тарафыннын 1361 елда Болгар дәүләте икенче мәртәбә тәмам җимерелгәннән соң, болгарлар үзләренең элек төп яшәү урыны булган Кама сулъягының кара туфраклы уңдырышлы җирләреннән, туган авылларын һәм шәһәрләрен ташлап, массовый төстә Кама уңъягына – Казан арты территориясенә күчеп утырганнар. Болгарларның бер өлеше Иделнең уңъягына – Зөя елгасының түбән агымындагы җирләргә күчеп килгәннәр. Шулай итеп, Болгар дәүләтенең үзәге, ядросы булган Кама сулъягы территориясе 3 – 4 гасырга бушап калган. Анда утрак тормышта яшәүчеләрнең саны бик азайган, бик күп сандагы болгар авыллары һәм шәһәрләре юкка чыкканнар. Бу җирләргә күчмә нугай һәм башкорт кабиләләре генә җәйләүгә килеп чыга торган булганнар. Менә шушы тарихи сәбәпләр республикабызның Кама аръягы территориясендә болгар теле белән мөнәсәбәтле топонимик катламның, бигрәк тә ойконимнарның югалуы исәбенә, шактый ярлылануына, сирәкләнүенә китергән. Без бу төбәктә болгар топонимик катламы бөтенләй юкка чыккан, эссез югалган, дигән караштa тормыйбыз. Байтак кына елга (Кондырма, Кондызча, Чирмешән, Шуран, Баран, Яуширмә, Чаллы), күл (Биләр күле, Би күле, Балым-Хуҗа күле һ.б.), шәһәр (Болгар, Биләр, Суар, Нократ, Тубылгытау, Җүкәтау, Баламир һ.б.) һәм авыл (Пәрәү, Саурыш, Ашыт, Шыланга, Каратай, Шуран, Чаллы, Таңкай, Нократ, Ямбакты, Әҗемәр, Иске Рәҗәп, Салман һ.б.) атамалары безнең көннәргәчә сакланганнар.

«Чирмешән, Майна, Актай елгалары буенда утырган Алпар, Борнай, Чиябашы, Аппак, Пәрәү, Кизләү, Иске Рәҗәп, Йорткүл, Ямбакты, Салман кебек авылларны Болгар дәүләте чорыннан калган авыллар дип исәпләргә кирәк. Без бу турыда археология, тел һәм фольклор материаллары буенча беләбез» – дип яза Р.Г. Фәхретдинов.

Югарыда китерелгән атамалар, әлбәттә, болгар чорында да булганнар. Ләкин аларның бөтенесен дә болгарларның үз телләренә генә нисбәтләү дөрес булмас иде. Болгарлар төрки кабиләләр булганнар. Аларның күп сүзләре, атамалары да борынгы төрки телдән үк килгән. Без аларга бу бүлектә аерым басым ясап тормыйбыз. Басымны болгар теле үрнәкләренә ясыйбыз.

Идел болгарларының атамаларын өйрәнгәндә, сүзне иң элек Болгар һәм Биләр атамаларыннан башлау кирәктер.

Болгар – бүгенге көндә Спас районындагы рус авылы. Атама, әлбәттә, икенчел. Ул Болгар дәүләтенең баш каласы – Болгар шәһәре исеменнән алынган.

Шәһре Болгар зур ике су – Идел һәм Кама кушылган урынга утырган, ясалма рәвештә ныгытылган һәм аннан бөтен тирә-якны иркен күзәтеп булган. Ныгытылган өлешенең мәйданы яңа оешкан вакытында 90 мең $м^2$ дан артык булмаган. Тора-бара үзәктән 300–700 метр ераклыкта кыр ягыннан шәһәр яны авыллары, бистәләр барлыкка килә башлый. X гасырның ахырында инде шәһри Болгар Урта Идел һәм Түбән Кама буйларында культура һәм этник яктан төрле чыганакларга барып тоташа торган кабилә-кавемнәрнең сәяси үзәгенә әверелә.

Болгар сүзенең этимологиясе турында фикерләр бик күп; барысы да диярлек этнонимны болгар теленә нисбәтлиләр. Аеруча кызык берничә фикер генә күрсәтәбез.

Ш. Мәрҗани «Мостафадел-әхбар...» дигән хезмәтенең икенче кисәгендә (Казан, 1910) болгар этнонимының килеп чыгышын *болгау* фигыленә бәйләп аңлата. Профессор Н.И. Золотницкий Болгар һәм Биләр атамаларын бер үк сүзнең калын һәм нечкә әйтелешле вариантлары дип саный [Золотницкий, 1884, с. 12].

Ф. Гордеев болгар этнонимын, *болгар + болга + волга + ар* – «ир, ир кеше» төзелешен тәшкил итә һәм «Волга елгасы буенда яшәүче кешеләр, халык» мәгънәсен белдерә, дип саный. Волга гидронимының килеп чыгышы балтик телләренә нисбәтле дип искәртә [Гордеев, 1967, с. 194].

Г.Ф. Саттаров *булгар – болгар* этнонимын *булуг - ар (булугар)* төзелешен тәшкил итә һәм *«булган ар, булган ир, булган кеше, булган, уңган кешеләр, булган, уңган, булдыклы кабилә, халык»* мәгънәсен аңлата дип әйтү ягында тора [Саттаров, 1973, б. 144].

Болгар шәһәре Биләрнең атамасы бүгенге көндә Алексеев районындагы авыл исеменә әверелгән. Авылда руслар яши. Биләр елгалары да бар. Алар Кече Чирмешәннең сул, Сикия елгасының уң кушылдыклары. Биләр авылы шушы елга буена урнашкан. Авылны тирә-яктагы җирле халык Бүләр дип тә атый. Биләр ~ Бүләр авылы Казан ханлыгы чорында да булган. Урта гасыр галимнәренә һәм сәяхәтчеләренә бу атама мәгълүм. Әбү Хәмид әл-Гарнати Биләрнең XII гасыр башында билгеле булуы хакында яза.

Биләрнең тарихи аренада яшәү чоры X–XIII гасырлар, ягъни 922 елдан алып, 1236 еллар дип күрсәтелә. Тарихи чыганаклар һәм нумизматика мәгълүматларында ул «Бүләр», «Бүләмәр», рус елъязмаларында «Олуг шәһәр» формасында кулланылган һәм Болгар дәүләтенең башкаласы да булып торган, монда акча да сугылган.

Борынгы Болгар шәһәре исеме халык күңеленнән чыкмаган, рухи мәдәниятеннән аерылмаган. Биләр сүзе белән хәзерге Татарстанда һәм аңа чиктәш урыннарда да авыл, елга һ.б. географик берәмлек атамалары еш очрый. Арча районындагы Татар Кадрәге авылын тирә-як халкы «Биләр иле» дип йөртә. Бу авыл зиратында XIV гасырның беренче яртысына карый торган кабер ташлары бар.

Норлат районында Биләр күле янында шул ук атаманы йөрткән авыл бар. Авылларның исемен исәпкә алу кенәгәләренә нигезләнеп, С.М. Шпилевский шушы авыл янында Болгар

дәүләтенә караганлыкны күрсәтә торган Биләр сүзе белән тагын өч авыл булуын яза.

Мөслим районындагы Мари-Бүләр исемле – мари, Татар-Бүләр исемле татар авылларының да атамалары Идел болгарларының Бүләр ~ Биләр исемле шәһәр атамасына мөнәсәбәтле.

«Биләр» кабер ташы язмаларында да ныгып калган. Һ.В. Йосыпов Болгар шәһәре хәрабәләре янында табылган XIV гасыр кабер ташында «Мон Булер» дигән кушамат укый һәм аны ике этноним катнашмасы (ике кабилә исеме) дип уйлый. XV–XVII гасыр эпитафияләрендә дә Биләр этнонимы чагылыш таба. Идел-Чулман буе болгарларында Бүләртай дигән кеше исеме дә булган.

Биләр сүзе хәзер төркиләр яши торган һәм кайчандыр яшәгән урыннарда да очрый. Хәзерге Башкортстан җирендәге Бүләр авылы шулай ук Идел болгарларының борынгы Биләр шәһәре исеменә мөнәсәбәтле.

Вятка губернасы Алабуга өязенең 1891 елгы картасында Можга өязендәге Биләр исемле елга ярында Биләр авылы күрсәтелә. Хәзерге Мари Эл республикасында да Биләр сүзенә мөнәсәбәтле топонимнар бар.

Болгарлар һәм болгарларга кадәр яшәгән җирле төрки кабиләләрнең яңа җирләр белән мөнәсәбәткә керүләре елгалар буйлап башкарылган булса кирәк. Мәсәлән, «Болгар дәүләте төзелгәнче үк, – дип яза М.З. Зәкиев, – Кама буйларында яшәгән биар (бигер, биләр) кабиләләре төрки җирләргә барып чыкканнар, башка кабиләләр белән сату-алу һәм хәрби мөнәсәбәткә кергәннәр... Пермь шәһәре исеме *биар* сүзеннән ясалган Биарм атамасына нисбәтле. Моңа кадәр фантастик ил дип уйланылган Биармия чынлап та яшәгән. Икенче төрле аны Биләр яисә Бигер дип атаганнар. Идел һәм Чулман елгалары буйларында Идел–Чулман болгарлары дәүләте төзелгәннән соң, ул бу ил составына керә [Гарипова, 1994, с. 182]

Г.Ф. Саттаров биләр сүзен *би* + *ләр* элементларына аера. Ягъни Биләр шәһәре анда күп биләр/бәкләр яшәгән шәһәр булып чыга. Бу яктан караганда атама борынгы төрки чорга ук

барып тоташа [Саттаров, 1973, б. 141]. Без дә шушы фикергә кушылабыз.

Николаев Баран, Арбузов-Баран, Кызыл Баран – Алексеев районындагы авыллар. Бу авылларның атамасы Бәрән елгасы исеменә нисбәтле. Бәрән елгасы – Кече Чирмешәннең уң кушылдыгы, Алексеев районы җиреннән ага. Спас районында да Бәрән елгасы бар. Икенче төрле аны Рәҗәп суы дип тә йөртәләр. Ул Майна елгасының уң кушылдыгы. Бәрән елгасы ярында Иске Бәрән яки Иске Рәҗәп һәм Яңа Рәҗәп авыллары урнашкан. Р.Г. Фәхретдинов Иске Бәрән авылының Болгар чорында барлыкка килүе хакында яза.

А.Х. Халиков фикеренә караганда, гидроним һәм ойконим атамалары *бәрәнҗәр* дигән этнонимга мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән. Бу атаманың этнонимик характерда булуын рус топонимисты В.А. Кононов та күрсәтеп узды. X гасырда гарәп хәлифәлегеннән Идел-Чулман болгарлары дәүләтенә килгән Ибне Фадлан язмаларында без түбәндәге язмаларны укыйбыз: «Без аларда инде мөселман динен кабул иткән 5000 кешедән торган бер гаилә кешеләре күрдек. Алар бәрәнҗәр исеме белән билгеле».

А.Х. Халиков «Кече Чирмешән һәм аның уң кушылдыгы Бәрән суы ярында Биләр халкының нигезен тәшкил иткән бәрәнҗәр кабиләләре яшәгән», – дип яза.

Урта гасыр галиме Мәсүди мондый язма калдырган: «Дүрт кардәш төрки кабиләләр – баджна, баджанок, баджгурт һәм нукардалар славяннар җиренә яу чабалар».

Азәрбайҗан галиме А. Гусейнзадә, бәрәнҗәр төньяк Дагстанда сакланып калган хәзәр топонимы Belansar'дан барлыкка килгән, ди. Ул, немец галиме Дерферның фикеренә кушылып, хәзәр топонимы Baranjar'дан үзгәргәнлеген һәм бу терминның шушы ук мәгънәдә яңа фарсы теленә дә кергәнлеген әйтә. Г.Ф. Саттаров Бәрән атамасы белән бер үк ояга Казан суының уң кушылдыгы Бирәзә суын, аның ярына урнашкан Зур Бирәзә, Урта Бирәзә һәм Күкчә Бирәзә авыллары атамаларын кертә һәм бу исемнәрне Идел-Кама болгарлары этнонимы бәрәнҗәр белән

бәйләп карый. Ул түбәндәге фонетик үсеш этапларын күрсәтә: беренджер – бәрәнзәр – бәрәзә – бирәзә.

Шулай итеп, бәрән атамасының серләре тирән катламнарга барып тоташа, халкыбыз үсеше юлларының гаять катлаулы икәнлеген күрсәтә.

Бу атама – безгә тарих тарафыннан калдырылган кадерле ядкәр.

Болымер Спас районындагы рус авылы. Атаманы Идел болгарлары составына кергән Болымәр (Бүләмәр) кабиләсе исеменә нисбәтлибез. Һ.В. Йосыпов болгар кабер ташларын җентекләп өйрәнә һәм, моңарчы билгеле булганнардан тыш, тагын Катай, Табын, Суван, Сувар, Болгар, Төрекмән, Ашлы, Бүләр, Мин, Балымәр, Көек, Орым, Алак кебек башка төрки халыкларда да билгеләнгән шактый күп этнонимнар барлыгын ачыклый [Гарипова, 1994, б. 216].

П.И. Рычков Биләрнең Булумәр, Булумер, С.М. Шпилевский һәм Р.Г. Фәхретдинов Буләмәр формалары булганлыгын язалар.

Украина галимнәре бу атамаларның мәгънәсен төрки-болгарлар белән бәйләп аңлаталар [Гарипова, 1994, б. 181]

В.К. Магницкий хезмәтендә урын алган мәҗүси Саурыш һәм Савыш исемнәре Саба районындагы Сауыш, Олы Саурыш, Түбән Саурыш дигән татар авыллары атамаларының барлыкка килүе болгар-чуваш-татар Сауыш һәм Саурыш исемнәре белән мөнәсәбәтле булуын ачыкларга ярдәм итә. Атаманың болгар теленә нисбәтлелеген Р.Г. Фәхретдинов [Фәхретдинов, 1967, б. 142] белән Г.Ф. Саттаров [Саттаров, 1973, б. 38] күрсәтеп узды.

Аксубай районында Саурыш, Иске Саурыш, Түбән Саурыш дигән чуваш авыллары бар. Борынгы болгар-чуваш исеме Саурыш (Савруш), республикабызның Саба һәм Теләче районнарында – татар, Аксубай районында чуваш авыллары атамасына әверелеп, саклануы игътибарны үзенә җәлеп итә.

Тубылгытау – Яңа Чишмә районындагы татар авылы. Тарихтан билгеле булганча, Тубылгытау авылы урынында Урта гасырларда кечерәк шәһәр булган. Мәйданы ягыннан ул Болгар, Биләр, Суар, Кашан кебек шәһәрләрдән күп кечкенә булган,

чөнки зур сәүдә юлларыннан, Идел һәм Камадан шактый ерак урнашкан. Ләкин кечкенә булуына карамастан, монда да мәктәп-мәдрәсәләр эшләгән, сәүдә һәм һөнәрчелек чәчәк аткан. Шәһәр тирәсендә халык иген иккән, ә шәһәр урыны хуҗалык алып бару өчен бик уңайлы сайланган. Тубылгытау шәһәренең урыны Шушма елгасының сул як ярында, Яңа Чишмә районы Югары Никитка авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. Шәһәргә XII гасырда монгол яуларына кадәрге чорда нигез салынган, аның чәчәк ату вакыты исә XIII–XIV гасырларга туры килә, дип исәплиләр. Элекке шәһәр урынында, хәзер Тубылгытау дип аталган авыл кырыенда «Кала башы тавы» дигән урын булу да шәһәрнең монголларга кадәрге болгар чорларында барлыкка килүен раслый. Чөнки «Кала тау», «Кыз каласы», «Кызлар уйный торган җир», «Кыз тавы» дип атала торган легендар урыннар, кагыйдә буларак, Болгар һәм аннан да элеккерәк төрки чорлар белән бәйләнешле. Без моны халык авыз иҗаты әсәрләреннән дә ачык күрәбез. Җүкәтау, Тубыл елгасы да шушы Тубылгы агачы исеменә нисбәтле.

Тубылгытауны археологик яктан өйрәнүгә А. Артемьев, С. Шпилевский, И. Износков, В. Казаринов, П. Пономарев, А. Смирнов һ.б. галимнәр зур өлеш керткәннәр. Топонимик мәгълүматларга таянып, бу шәһәрнең урынын беренче мәртәбә В. Казаринов һәм П. Пономарев ачыклый [Гарипова, 1990, б. 47] XIV гасырда Тубылгытау шәһәре яшәүдән туктый. Соңыннан бу төбәккә татарлар янына руслар килеп утыра.

Тарн-Вар – Норлат районындагы чуваш авылы. Атаманы болгар-чуваш теленә нисбәтлибез. *Вар – варан – валан* сүзе чуваш телендә бүген дә кулланылышта йөри һәм аның белән күп ойконимнар ясалган: Варпус, Варпус Чемей, Варанчи Ушкань, Таранвар һ.б.

*Вар* компонентының болгар теленә нисбәтле икәнлеген Г.Ф. Саттаров та исбатлады [Саттаров, 1998, б. 9–11].

Һуннар Днепр елгасын Var – «елга» дип йөрткәннәр. Бүгенге көндә Варан – Баран-Майна елгасының сул кушылдыгы, Варангуш – Казан артындагы елга, Уран – Башкортстандагы

елга, Урсай – Азнакай һәм Әлмәт районнарындагы авыллар атамасы һ.б.

Чистай районындагы Олы Талкыш, Кече Талкыш, Урта Талкыш, Татар Талкышы авыллары атамалары турында югарыда язган идек инде. Талкыш компонентының борынгы төрки телгә генә түгел, болгар теленә дә нисбәтлелеген искәртеп китәсебез генә килә. Атама антропоним булып нәкъ менә болгар чорында формалашкан булса кирәк.

Көнбатыш Кама аръягында күп авылларның атамасында *чаллы* компоненты бар. Иске Чаллы, Яңа Чаллы, Бибай Чаллысы – Әлки районындагы татар авыллары. Норлат районындагы рус авыллары да Иске Чаллы, Урта Чаллы, Түбән Чаллы атамаларын йөртәләр. Чистай районында Чаллыбаш авылы бар. Чишмә елгасына коючы Чаллы елгачыгы башына утырганга күрә бу авыл шулай аталган.

XIX гасырда Казан төбәге топонимиясен өйрәнүгә зур өлеш керткән галим И.А. Износков бу авылларның күбесенең Чаллы дигән елгачыклар бассейнына утырганга шулай аталуларын әйтә [Износков, 1885, с. 69]

*Чал – чул* сүзе (биредә *у* һәм *а* сузыкларының тарихи тәңгәллеге чагыла) болгар-татар телендә «таш» төшенчәсен белдергән. Чуваш телендә *чул* сүзе хәзер дә «таш» дигән мәгънә аңлата. Чувашлар Түбән Новгород шәһәрен Чулхула, ягъни «Ташкала» дип йөртәләр. Монгол телендә дә *чулу* сүзе «таш» мәгънәсен белдерә.

*Чаллы* сүзенең болгар теленә нисбәтлелеген Г.Ф. Саттаров та күрсәтеп узды. Ул Татарстанда 20, Урта Идел буенда 50 торак пункт атамасы составында *чаллы* сүзе булуын искәртә [Саттаров, 1974, б. 71–74]. Бу сүз төрле фонетик формаларында башка телләрдә дә очрый: тува *чалым,* бурят *шулуун,* монг. *чулу,* тур. *чал,* азәрб. *чал.*

Чирмешән атамасы турында югарыда язган идек инде. Атама составындагы «чирме» компонентының болгар теленә нисбәтлелеген генә тагын бер тапкыр искәртеп китәсе килә. Бу компонент белән Яуширмә атамасы да ясалган. Яуширмә –

Чистай районындагы авыл. Ул татар халкының бөек әдибе, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый туган авыл буларак билгеле. Авылның атамасы Яуширмә дигән елгачык исеменнән алынган.

Атама *яу + ширмә* рәвешендә ясалган. Идел болгарлары телендә *шыр – ширми – ширмә – чирмә – чирме* сүзе актив кулланылышта йөргән. Чуваш телендә ширма сүзе бүген дә кулланыла.

Норлат районында Юган елгачыгы буенда Юган дигән татар-рус-чуваш авылы бар. Н.А. Баскаков борынгы болгар теленнән сакланып калган сүзләргә мисал итеп йупан кабиләсе исемен дә китерә [Баскаков, 1969, с. 235]. *Йупан* этнонимының Йуwан (йуwан) – йупан елгасы буенда яшәүгә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән булу ихтималы бар. Шушы уңайдан *w* (йу) *jo* тамырлы сүзләрнең фин-угыр телләрендә дә кулланылуын әйтергә кирәк [Лыткин, Гуляев, 1970, с. 334].

Югарыда әйтеп үткән Аппак, Алпар, Йорткүл, Ямбакты, Ашыт, Салман, Каратай, Әшнәк кебек атамалар, Р.Г. Фәхретдинов белән Г.Ф. Саттаров күрсәтүенчә, болгарларда да булган. Без бу атамаларны болгарларга гына кайтарып калдыру ягында түгел. Алар борынгы төрки чорда ук кулланылышта йөргәннәр, башка төрки телләрдә дә очрыйлар. Дөрес, кеше исеме, ягъни антропоним буларак, аларның кайберләре нәкъ менә болгар чорында формалашкан булырга мөмкин.

Шактый зур территория биләп торган Болгар дәүләте өчен топонимик истәлекләр чагыштырмача аз сакланган. Татар халкының үзаңын бетерергә теләгән рус хөкүмәте дә моңа шактый өлеш керткәндер әлбәттә. Халыкны чукындыру, русларны күпләп монда күчерү, Болгар кабер ташларын чиркәүләргә нигез ташы итеп куллану моның күзгә күренгән өске өлеше генә.

### 2.1.3. Татар катламы

Татар теленең үзенә генә хас сүзләрне аерып чыгару – шактый авыр эш. Тикшереп караганнан соң, шул мәгълүм булды: татар теленең үзенеке саналып йөргән сүзләр дә, ныклабрак тикшереп карасак, борынгы төрки телгә нисбәтле икән. Шуңа күрә дә күп кенә атамаларны татар теленә дә, борынгы төрки

телгә дә кертеп карадык. Мондый ойконимнарны без югарыда карап киттек инде: Аппак, Актау, Акташ, Акъяр, Яңа Авыл, Зур Алан, Кече Алан, Чиябашы, Түбән Биктимер, Урта Биктимер, Болак, Батыр, Иске Баллы Күл, Дүрт Өйле, Йолдыз, Карасу, Каракүл, Каргалы, Киекле, Кычытканлы, Каравыл Тавы, Нарат-Елга, Суыксу, Ташбилге, Олы Талкыш, Кызыл Уракчы, Чулпан, Ясак авыллары атамалары.

Шул ук вакытта Кама аръягында борынгы төрки телдә күренмәгән һәм башка төрки телләрдә дә очрамаган атамаларга тап булдык. Андый атамаларны, кайбер галимнәрнең фикерләренә таянып, татар теленең үз атамаларына керттек.

Тигән Бүләк – Алексеев районындагы чуваш-мордва авылы. Бу атаманы татар теленә нисбәтлибез. Ойконимның ике компоненты да татар телендә бүгенге көндә актив кулланылышта йөри. Башка төрки телләр топонимиясендә очратмадык. Г.Ф. Саттаров *бүләк* компонентының берничә мәгънәсе барлыгын күрсәтә [Саттаров, 1973, б. 177; 1998, б. 162]. Бүләк исемле авыл Мөслим районында да бар. Азнакай һәм Бөгелмә районнарында Таллыбүләк авыллары бар.

Әлки районында Татар Борнае һәм Чуваш Борнае дигән авыллар бар. Борнай топокомпоненты Борнай дигән шәхес яки нәсел кушаматына нисбәтле рәвештә барлыкка килгән [Саттаров, 1973, б. 147]. Татар теленең Казан арты сөйләшләре төркеменә карый торган Балтач урынчылыгында *борнай* сүзе хәзер дә кулланылышта йөри.

Борнаш – Чистай, Бөгелмә районнарындагы – рус, Апас районында татар авылы. Борнаш авылларының атамасы Борнаш дигән кеше исеменнән алынган. Татар теле сөйләшләрендә борнау сүзе бүген дә кулланылышта йөри [Татар теленең диалектологик сүзлеге, б. 92]. Борнашның этимологиясе борын сүзенә мөнәсәбәтле [Саттаров, 1973, б. 245].

Мәҗүси чуваш исемнәре арасында Борнаш исеме очрамый. Казан ханлыгы чорында Казан артында ике татар авылының атамасы Борнаш булганлыгы мәгълүм. Бүгенге көндә алар юк.

Яңа Чишмә районындагы Акъяр авылының русча атамасы Азеево. Атаманың нигезендә чуваш-татар Әзи, Азей исеме ята [Магницкий, 1905, с. 25]. Р.И. Куряева исемне татар диалектларында очрый торган *әзи* (старший брат) сүзенә нисбәтле дип күрсәтә [Куряева, 1992, с. 19].

Норлат районында Гайтанкино һәм Новое Гайтанкино исемле рус-чуваш авыллары бар. Ойконимның нигезендә Гайтанкин фамилиясе ята. Фамилия Гайтанко кушаматыннан алынган. Кушамат рус телендәге *гайтан* сүзенә нисбәтле [Вайсблит, 1936, с. 96]. Рус теленә бу сүз XVI гасырда татар теленнән кергән: татар. *гайтан* (шнурок); төрек. *кайтан* (шнурок, бахрома).

Яңа Чишмә һәм Норлат районнарында Ерыклы исемле татар авылларының татарча атамасы Зирекле. Атаманы татар теленә нисбәтлибез. Борынгы төрки сүзлектә бу сүз китерелмәгән. Э.М. Мурзаев та бу сүзне топонимнары арасында күрсәтми. Зирекле елгасы да бар. Ул Кече Чирмешәннең сул кушылдыгы.

Ишәле – Чистай районындагы татар авылы. Иш тамыры белән ясалган авыллар Ульяновск өлкәсендә – Ишеевка, шул ук атама белән Пенза өлкәсендә ике авыл, Апас районында – Ишеево, Мордва республикасында Ишейки авыллары бар. Атама татар телендәге *Ишәй* исеменә нисбәтле булырга мөмкин. Бу исем Казан татарлары арасында XVI–XVII гасырларда киң таралган булган. *Ишейка* формасында мордва теленә дә кергән. Г.Ф. Саттаров, бу исем татар телендәге *ишәй* фигыленнән ясалган, дип күрсәтә [Саттаров, 1981, б. 6]. *Ишәле* атамасы Ишгали исеменең кыскартылган варианты булырга да мөмкин.

Спас районындагы Ирек авылының атамасын татар теленә нисбәтлибез. Татар телендә *ирек* сүзенең «азатлык, бәйсезлек» мәгънәләре бар [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1977, т. I, б. 40]. Татар телендә Ирек – кеше исеме булып та йөри. Г.Ф. Саттаров атаманы татар телендәге неологизм дип күрсәтә [Саттаров, 1998, б. 115].

Кәкре Күл – Аксубай районындагы рус авылы. Атаманың беренче компоненты «кәкре» татар телендә «туры, төз булма-

ган, бөгелгән яки кәкерәйтелгән» дигән мәгънәне аңлата [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1979, т. II, б. 249].

Әлки районында Русская Шибаши һәм Татар Чиябашы исемле авыллар, Норлат районында Вишневая Поляна исемле авыл бар. Татарлар авылны Чияле дип йөртәләр. Атама татар телендәге *чия* сүзеннән һәм *-лы* кушымчасыннан ясалган. Шибаши атамасы да Чиябашы атамасының диалекталь формасы булып тора. Без монда *ч/ш* тәңгәллеген күрәбез: чаг. *чишмә/шишмә*.

Карамалы – Әлки районындагы татар авылы. Карама сүзе татар телендә агачны аңлата. Ул элмәсыманнар семьялыгыннан киң ябалдашлы агач [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1979, т. II, б. 53].

Черемушка – Аксубай районындагы рус-чуваш авылы. Авыл атамасы татар телендәге шомырт сүзеннән калька дип уйлыйбыз. Татарлар авылны Шомыртлы дип йөртәләр. Бу якта Шомыртлы исемле елга да бар.

Гомумән, татар телендәге үсемлекләр белән бәйләнгән атамаларны татар теленең үз сүзләренә кертеп карарга, дөресрәге, кыпчак телләре сүзләренә кертергә мөмкин. Борынгы төрки телдән үсемлекләр арасыннан 12 төрле генә атама килеп җиткән. Башкалары бер җирдә дә күрсәтелми. Без күрсәткән үсемлекләр белән бәйле атамалардан *чия* сүзе генә *шия* формасында казак телендә дә бар.

Чирмешән районында Яшәүче исемле татар авылы бар. Татар телендәге *яшәү* фигыленә *-че* кушымчасы ялганып, Яшәүче исеме ясалган. Гомер итүче, торучы дигәнне аңлата [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1981, т. III, б. 664].

Юксыл – Әлки районындагы татар авылы. Юксыл сүзе бүгенге көндә искергән сүзләр рәтенә керә. Ярлы кеше, изелгән, эксплуатацияләнгән сыйныф вәкилен аңлата. Авыл халкы аеруча ярлы булганга бирелгән булса кирәк [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1981, т. III, б. 605].

XVII–XVIII гасырларда хәрби корабльләр төзү өчен казна урманнарында агач кисү һәм аны мул сулы елга буйларына тарттыру хезмәте белән шөгыльләнгән дәүләт крестьяннарын

«лашманнар» дип атаганнар. Ул заманда «лашман хезмәте», «лашман бәясе», «лашман бәете» кебек төшенчәләр булган. Бүгенге көндә Лашман – Чирмешән районындагы татар авылы. Лашман исемле елга да бар. Ул Арча районында Ашыт елгасының кушылдыгы [Гарипова, 1990, б. 218].

Мамык – Норлат районындагы авыл. «Физик яки рухи яктан бик йомшак булган кешегә Мамык кушаматы тагылган. Мамык кушаматын йөрткән аерым шәхес яки нәсел-токым эшчәнлеге аша бу кушамат Мамык авылы атамасына әверелгән» [Саттаров, 1973, б. 157].

Аксубай районында Татар Сөнчәлесе һәм Сөнчәле авыллары бар. XVI гасырда Сунчалеев дигән авыл булган. Әдәбиятта алпавыт Кибек Мурза Сөнчәлиев исеме китерелгән. Атама татар телендәге Сөенечгали атамасының диалекталь формасы булган Сөнчәләй исеменә мөнәсәбәтле булса кирәк.

Урта Тигәнәле, Зур Тигәнәле, Түбән Тигәнәле исемле татар авыллары Алексеев районында урнашканнар. «Тигәнә» сүзе татар телендә бер бөтен агач кисәгеннән чокып ясалган озынча улак, савыт, тагарак мәгънәләрен аңлата. Авылга атама тигәнә сыман чокырлы җиргә утырган өчен бирелгән булу мөмкинлеге дә бар. Шулай ук татар телендәге *тигәнәк* сүзенә нисбәтле булу мөмкинлеге бар. Сүз ахырындагы *-к* авазы төшеп калып *-лы* ясагыч кушымчасы белән ясалырга мөмкин. Авыл картлары атаманы шулайрак аңлата. Тигәнәк – җимешләре чәнечкеләр белән капланып үсә торган киң яфраклы үсемлек [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1981, т. III, б. 93].

### 2.1.4. Чуваш катламы

Көнбатыш Кама аръягында чувашлар бик күп яши. Региондагы 142 авылның 78 ендә чувашлар үзләре генә яши; 39 – рус-чуваш, 7 – татар-чуваш, 16 – татар-чуваш-рус, 1 – чуваш-мордва һәм 1 – чуваш-мордва-татар авыллары бар.

Чувашлар яшәгән барлык авылларның да атамаларын чуваш теленә генә нисбәтләү дөрес булмас иде. Шул ук вакытта чуваш теленә мөнәсәбәтле ойконимнар да байтак.

Ака – Норлат районындагы чуваш авылы. Ака һәм Аки ата-малары бер үк сүз булырга мөмкин. Аки исемле авыл Биектау районында бар. Атаманы чуваш-болгар теленә нисбәтле булырга мөмкин дип К.Я. Кадралиева күрсәтеп китә [Кадралиева, 1989, с. 105]. Атама чуваш телендәге *ака* (старший брат) сүзенә мөнәсәбәтле дип санайбыз. *Ака* сүзе чувашларда мөстәкыйль кеше исеме булып та йөргән. Бу сүз борынгы төрки сүзлектә дә очрый [ДТС, 1969, с. 47]. Мордва теленә бу сүз «старшая сестра» мәгънәсендә кергән [Марийский-русский словарь, 1956, б. 20]. Исем татар-чуваш исеме Акайдан да чыккан булырга мөмкин.

Алексеев районында Баганалы урманчылыгы бар. Атама чуваш мәҗүси исеме Багай белән мөнәсәбәтле. Багай исемле авыл Кайбыч районында да бар. Багай исеме удмурт теленә дә кергән [Куряева, 1992, с. 51].

Базяково авылы да Алексеев районында. Авылда руслар яши. Ойконим мәҗүси чуваш Базяк исеменә мөнәсәбәтле дип уйлыйбыз [Магницкий, 1905, с. 32]. Базяков фамилиясе булганлыгы да мәгълүм.

Чистай районындагы Бахта авылы турында язган идек инде. Атама чуваш телендәге Бахти исеменә дә нисбәтле булырга мөмкин [Магницкий, 1905, с. 33].

Әлки районының үзәге Базарлы Матак авылы исеменең икенче өлеше – Матак – борынгы чуваш исеме [Саттаров, 1973, б. 126]. Н.И. Ашмарин чувашларда Матакның ирләр исеме һәм нәсел кушаматы булып йөрүен хәбәр итә [Ашмарин, с. 322].

Бу районда тагын Иске Матак, Югары Матак дигән чуваш авыллары бар.

Булдырь – Чистай районынлдагы рус авылы. Ойконим нигезендә рус телендәге «булдырь» дигән сүз ята. Рус телендә «дом, стоящий на отшибе» мәгънәсен бирә. Чуваш телендә *pəlder* (навес на двух стойках) сүзенә мөнәсәбәтле [Фасмер, 1986, с. 238].

Сабакайка – Алексеев районындагы рус авылы. Ойконимның нигезендә Сабакай дигән мәҗүси чуваш исеме ята [Магницкий, 1905, с. 70]. Революциягә кадәр Казан губернасының Лаеш өязендә Сабакайкино дигән чуваш авылы булган.

Норлат районындагы Салдакай авылының атамасы да чуваш теленә мөнәсәбәтле дип уйлыйбыз. Салтак исемле авыллар Мари Эл республикасында да бар. *Салдакай* атамасы мәҗүси чуваш Салтак исеменә нисбәтле булса кирәк [Магницкий, 1905, с. 72]. *Салтак* сүзе мари теленә дә кергән.

Тарн-Вар атамасы турында язган идек инде. «Вар» сүзе болгар-чуваш телләренең уртак ядкәре. Чуваш телендә ул бүген дә кулланылышта йөри. Чувашстанда Варпус, Варпус Чемей, Воронин Ушкань, Таранвар кебек чуваш авыллары бар.

В.К. Магницкий шулай ук чуваш мәҗүси кеше исемнәренә мисал итеп Талкышны да китерә [Магницкий, 1905, с. 84].

Аксубай районында Иске Кәрәмәт, Яңа Кәрәмәт авыллары бар. Кәрәмәт сүзен чуваш теленә нисбәт итәбез. Чувашларда «кирәмәт өрәге» культы бар. В.А. Нестеров *кирәмәт* – чувашларның иң яраткан табыну объекты, дип күрсәтә [Нестеров, 1980, с. 67–68]. Бу автор *кирәмәт* сүзе белән кушылган 60 чокыр, яр исемен китерә. Усла Сизми Кереметь, Шинор Кереметь, Игис Кереметь, Кырлы Кереметь һ.б. В.А. Нестеров атама ислам дине белән гарәп-фарсы телләреннән кергән дип күрсәтә. Шул ук фикерне Н.И. Ашмарин һәм В.Г. Егоров та яклыйлар. Н.К. Антонов *кирәмәт* сүзе белән *кирәк* сүзләре арасындагы бәйләнешкә игътибар итә [Антонов, 1971, с. 131].

Беренче иҗектәге «*и*» авазы «*ә*» авазы белән алышынып Кирәмәт Кәрәмәткә әйләнгән булырга тиеш.

Чуваш этнонимы белән Көнбатыш Кама аръягында түбәндәге ойконимнар ясалган:

1. Яңа Чваш Әдәмсуы (Аксубай районы)
2. Иске Чуваш Әдәмсуы (Аксубай районы)
3. Чувашское Енорускино (Аксубай районы)
4. Чуваш Майнасы (Алексеев районы)
5. Чуваш Шәпкесе (Алексеев районы)
6. Чуваш Кичүе (Алексеев районы)
7. Чуваш Борнае (Алексеев районы)
8. Чувашская Чебоксарка (Яңа Чишмә районы)
9. Чувашская Менча (Норлат районы)

10. Чуваш Тирмәннеге (Норлат районы)
11. Чувашская Афонькино (Норлат районы)
12. Чуваш Ялтаны (Чистай районы).

Этноним буларак *чуваш* сүзе XVI гасырның беренче яртысында рус чыганакларында күренә [Перетяткович, 1892, с. 119]. М.И. Скворцов, чуваш (таврош) этнонимы чувашларның хәрби җитәкчеләренең исеменнән килә, дип күрсәтә [Скворцов, 1977, с. 21].

Чабаксар һәм Шабашкар атамалары турында күп язылган. Атамаларны төрле телләргә нисбәт итәләр. Чуваш филологы Г.Е. Корнилов, бу ике сүз дә мөстәкыйль рәвештә барлыкка килгәннәр һәм борынгы чуваш теленә нисбәтлеләр, дип күрсәтә [Нестеров, 1973, с. 183–185]. Г.Ф. Саттаров, атама төрки телдәге *Чыбык* сүзенә *сар* элеменды кушылып «чыбыклык, чыбык күп үсә торган урын» мәгънәсен белдерә дип аңлата.

В.А. Нестеров, атаманы фин-угыр телләренә карый, ди, венгр теленә якын тора дип күрсәтә [Нестеров, 1973, с. 183–185]. Безнең фикеребезчә, ике атама да бер үк сүзгә нисбәтле. Алар бер сүзнең төрле фонетик яңгырашлары гына. *Ч/ш/с* күчеше диалектларда сирәк очрый торган күренеш түгел. Ойконим гидронимнан ясалган. Чувашстанда Чабаксар дигән елгалар һәм елгачыклар бик күп. Чабаксар шәһәре шул исемдәге елга буена утырган. Ойконимны төрки-чуваш теленә нисәтлибез. Яңа Чишмә районындагы Русская Чабаксарка авылының атамасы икенчел.

Әлки районында Чуваш Шәпкесе дигән авыл бар. Ойконимның нигезендә Шапки дигән мәҗүси чуваш исеме ята [Магницкий, 1905, с. 94].

Яңа Сихтермә Әлки районындагы чуваш авылы. Чуваш телендәге *сихтерме* сүзе татар телендә бишек дигәнне белдерә.

### 2.1.5. Башкорт катламы

Көнбатыш Кама аръягында башкорт теленә караган атамалар күп түгел. Һәрхәлдә без ике ойконимны гына башкорт теленә мөнәсәбәтле итеп карыйбыз. Каргалы авылы Әлки районында, Ибраево, Каргали (Кәркәле) Чирмешән районында

урнашкан. Әлки районындагы Каргалы авылы кешеләре үз авылларының атамасын авыл урынында каргалар күп булганлык белән аңлаталар. Безнең фикеребезчә, атама башкорт этнонимына нисбәтле булырга тиеш. Моның шулай икәнлегенә Каргалы атамалы елгалар да дәлил булып тора. Районда ике Каргалы елгасы бар: 1. Талкыш суының уң кушылдыгы; 2. Чаллы елгасының сул кушылдыгы. Авыл атамасы гидронимнан ясалган. Болгар дәүләте таркалганнан соң, бушап калган бу җирләргә башкорт, нугай кабиләләре җәйләүгә килгәннәр. Шул башкорт кабиләләренең берсенең атамасы елгаларга кушылып калган булса кирәк.

Каргалы ойконимының башкорт теленең нисбәтлелеген Г.Ф. Саттаров та күрсәтеп узды [Саттаров, 1980, б. 32–49].

Райондагы башкорт теленә нисбәтле икенче атама – Ерыклы/Ерыкла. Бу исемдәге авыллар Алексеев, Яңа Чишмә, Норлат районнарында бар. Норлат районында Йырыклы елгасы бар [Гарипова, 1990, б. 199]. Татарлар авылларны Зирекле дип йөртәләр. Ерыклы – Зирекле сүзенең башкортча варианты дип уйлыйбыз. Монда *з/й* тәңгәллеге күренә. Башкортстанда Ерыклы елгасы һәм Ерыклыбаш авылы да бар.

Башкорт теленә нисбәтле булган башка атамаларны без бу регионда очратмадык.

## 2.2. Фин-угыр катламы

Патша хөкүмәте указы белән Кама аръягы ныгытмаларын саклау өчен XVII–XVIII гасырларда бу регионга, татарлар һәм чувашлар белән бергә, мордва һәм мариларны да күп күчергән булганнар. Ләкин алар сан ягыннан татарлар, чувашлар һәм русларга караганда күпкә азрак булган күрәсең. Бүгенге көндә бары тик 12 авылда гына марилар һәм мордвалар яши. 12 авылның дүртесендә әле алар руслар, чувашлар, татарлар белән аралашып яшиләр. Сан ягыннан күбрәк булган халыклар белән ассимиляцияләшкәннәр күрәсең. Фин-угыр халыклары, гомумән, үзләренең гореф-гадәтләрен, телләрен онытып, күбесенчә я руслашканнар, я татарлашканнар. Бүгенге көндә дә алар яшәгән 15 авыл

атамасыннан җидесен генә фин-угыр телләренә нисбәтләргә мөмкин. Аларны да тулы составлары белән бу телләргә кертеп булмый. Мордва Болагы, Нәлет, Күтәмә, Мордва Афонкәсе, Мордва Баганалысы, Войкино, Вожи. Калган сигез атама рус, татар һәм монгол теленә нисбәтле: Андрейка, Родники, Тигән Бүләк, Красная Поляна, Яңа һәм Иске Котыш, Чирмешән, Нагай.

Дөрес, бу регионда элек фин-угыр телләренә нисбәтле булган атамалы авыллар бар. Бүгенге көндә бу авылларда башка милләт вәкилләре яши. Ул авылларда башта мордвалар яки марилар яшәп, вакытлар үтү белән алар төркиләшкәннәр яки руслашканнар. Мәсәлән, фин-угыр телләренә караган Вожи исемле авылда руслар, Каратаево авылында руслар, Иске Мукшы авылында чувашлар, Яңа Мукшы авылында руслар, Шома авылында да руслар, Сарсаз авылында руслар һәм татарлар яши. Бу күренешне Р.И. Куряева фин-угыр халыкларының түбән милли үзаңлылыгы белән аңлата. Мордва республикасындагы 1614 торак пунктның 571 е генә мордваларныкы, калганнарында руслар яши. Эш монда русларның күпләп күчерелүендә генә түгел, ә җирле халыкның христиан диненә күчеп руслашырга омтылышында да булса кирәк [Куряева, 1992, с. 143].

Иске Мукшы һәм Яңа Мукшы – Аксубай районындагы авыллар. Мукшы исемле авыллар Арча һәм Чүпрәле районнарында да бар. Казан ханлыгы чорында Мукшы исеме татар авылы булганлыгы билгеле [Остроумов, 1876, с. 287]. Бу авыл Болгар дәүләте чорында яки аннан да иртәрәк нигезләнгән булырга мөмкин [Саттаров, 1980, с. 32–49]. Лаеш өязендә Мордва Челно һәм Мордва Новое исемле авыллар булган. Соңыннан алар Чистай өязенә күчерелгәннәр [шунда ук].

Мукшы этнонимы белән Татарстанның төрле районнарында микротопонимнар да ясалган. Лаеш районында – Мукшы болыны, Норлат районында – Мукшы тугае һ.б.

Каратаевка – Чистай районындагы авыл. Без бу атаманы югарыда караган идек инде. Бу сүз, әлбәттә, төрки телгә нисбәтле. Ләкин мордвалар аны этноним буларак кулланганга күрә, без аны бу телгә мөнәсәбәтле рәвештә дә карарга булдык.

Каратай атамасы шактый күп топонимнарда очрый. Кама Тамагы районындагы Мордва Каратай һәм Заовражный Каратай авылларында мордвалар яши. Шул ук төбәктә Олы Каратай һәм Кече Каратай исемле елгалар ага. Арча районындагы Каратай һәм Лениногорск районындагы Мөэмин-Каратай авылларында татарлар яши. Зәй-Каратай – Зәйнең сул кушылдыгы.

Каратай исеме һәм аннан ясалган Каратаев фамилиясе татарларда һәм, татарлардан алынма буларак, русларда да очрый. *Каратай – Карачай* берәмлеге белән ясалган гидроним һәм топонимнар Татарстаннан башка төбәкләрдә дә табыла. Башкортстанда Каратай авылы бар. Каратай исемле елга Ульяновск өлкәсендә ага. Каратай исемендәге хутор Дон елгасы бассейнында да билгеләнгән. Ставрополь краенда Яңа Карачай дигән шәһәр тибындагы бистә, Кырымда Карачай топонимы бар [Гарипова, 1994, б. 114]. Моңа тагын мәгълүм карачай-балкар этнонимын да өстәргә кирәк. Г.Ф. Саттаров атаманы мордвалар белән бәйләп карый [Саттаров, 1980, с. 32–49].

Алексеев районындагы Шома дигән татар-рус авылы исемен мукшы телендәге *шома* (бит) сүзенә нисбәтле булган, Шома кушаматыннан ясалган дип әйтә алабыз. Гадәтидән зур яки кечкенә битле кешегә мукшы телендә Шома дигән шәхси кушамат тага торган булганнар [Саттаров, 1973, б. 179].

Вожи – Спас районындагы рус авылы. Атама коми теленә мөнәсәбәтле булырга мөмкин. *Вож* сүзе коми телендә елга кушылдыгы мәгънәсен бирә [Мурзаев, 1984, с. 185]. Бу сүз белән ясалган гидронимнар А.К. Матвеев картасында күрсәтелгән [Матвеев, 1972, с. 25]: Вожгора, Вожмогора, Войвож, Вожаель, Вожский, Непь-Ворга-Вож, Бадья-Вож, Вожбол, Вожма, Воженка, Вожега һ. б.

Күпмедер күләмдә фин-угыр телләренә нисбәтле атама – Сарсаз. Бу ойконимның беренче компоненты *сар* бу телләрдә сазлык мәгънәсен бирә. Бу элемент белән түбәндәге атамалар ясалган: Саранск, Сара, Засарье, Инсар, Сарпа, Саранка, Инсаровка һ.б.

## 2.3. Монгол катламы

Монгол катламына Татарстанның Көнбатыш Кама аръягында мисаллар аз. Тулысынча бу катламга ике атаманы гына кертеп карыйбыз – Чыгтай һәм Нагай атамалары. Төрки-монгол уртак атамасы – Урмандәй.

Югары Чыгтай һәм Түбән Чыгтай – Чирмешән районындагы татар авыллары. Чыгтай антропотопонимы монгол телендәге Чагатай дигән кеше исеменә нисбәтле [Саттаров, 1989, б. 118].

Нагай авылы да Чирмешән районында урнашкан. Нагаевка, Нагаево исемле авыллар Мордва республикасында да бар. В.К Магницкий Нагайны мәҗүси чуваш исемнәренә кертеп карый [Магницкий, 1905, с. 60]. Д.Н. Ушаков нугайлар дип кырым татарларының кыр диалекты вәкилләрен атый [Ушаков, 1966, с. 326]. Без М. Фасмер фикеренә кушылабыз. Ул «нагай» төрки кабиләләр атамасы дип саный. Бу кабиләләргә атама монгол кенәзе Ногай (Чыңгызхан оныгы) исеменнән бирелгән, дип күрсәтә. Исем монгол телендәге *нокай* (эт) сүзенә нисбәтле дип яза. [Радлов, 1882, с. 3–35]. Г.Ф. Саттаров, мондый исем эт елында туган балага бирелгән булса кирәк, дип яза [Саттаров, 1992, б. 190].

*Урмандәй* атамасы турында без югарыда язган идек инде.

Татарстандагы монгол топонимнары, антропо- һәм этнотопонимнары XIII–XV гасырларга, ягъни Алтын Урда чорына бәйле. Г.Ф. Саттаров мәгълүматларына караганда, бүгенге көндә Татарстан җирләрендәге монгол атамалары 20 дән артмый [Саттаров, 1989, б. 119]. Көньяк республикаларда алар күбрәк. Г.К. Конкашпаев Казакстанда 200 дән артык топоним бар дип күрсәтә. А.П. Цагаева мәгълүматларына караганда, Төньяк Осетиядә 150 төрки-монгол атамасы табылган.

Димәк, татар халкының оешуына монголлар көчле тәэсир ясый алмаганнар. Монгол гаскәренең төп көчләрен төрки кабиләләр тәшкил иткән. Безнең якларны яуларга да күбрәк шулар килгәндер күрәсең. Татар халкының оешуына җирле Идел, Урал буе халыклары, болгар халкы, дала якларыннан килгән төркиләр нигез булган. Монголларның тәэсире сизелерлек түгел, дип яза Б.Х. Юлдашев [Юлдашев, 1972, с. 47]. Без аның

фикере белән килешәбез. Татар теле лексикасында очрый торган уртак төрки-монгол сүзләре исә Гомумалтай чорга ук барып тоташа.

## 2.4. Гарәп-фарсы катламы

922 елда Идел Болгарстаны ислам динен кабул иткәннән соң, телгә күпләп гарәп-фарсы сүзләре керә башлый. Бу алынмалар кеше исемнәрендә дә чагыла. Соңрак инде антропонимнар ойконимнарга, гидронимнарга һ.б.га әйләнәләр.

Бүгенге көндә Көнбатыш Кама аръягы ойконимнары арасында, безнең тикшеренүләр күрсәткәнчә, гарәп-фарсы телләренә нисбәтле кырык биш атама бар. Бу атамаларның кайберсе кабатлана, мәсәлән, *чишмә* сүзе белән биш атама ясалган һ.б.

Аксубай районында Яңа Чуваш Әдәмсуы, Иске Чуваш Әдәмсуы, Яңа Татар Әдәмсуы, Иске Татар Әдәмсуы дигән татар-чуваш авыллары бар. Аксубай районында Әдәмсу елгасы бар [Гарипова, 1990, б. 289]. Атамалар составындагы Әдәм сүзе гарәп теленә нисбәтле.

Гарәп телендәге Әхмәт дигән кеше исеме белән безнең регионда өч ойконим ясалган. Аксубай районындагы Ахматка – чуваш авылы, Әлки районында – Татар Әхмәте, Норлат районында Ахметовка исемле чуваш авылы бар. Ахметовка очрагында Әхмәт исеменнән фамилия ясалган. Фамилия ойконимга әйләнгән. Әхмәт исеменең гарәп теленнән кергәнен Г.Ф. Саттаров та күрсәтә [Саттаров, 1981, б. 239].

Аксубай районында Азат исемле татар авылы бар. Азат сүзе безгә фарсы теленнән кергән. *Азад – азат, ирек, хөр* [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, б. 16]. *Азат* сүзе, кеше исеме буларак, бүген дә актив кулланылышта йөри.

Әлки районындагы Арбузов-Баран авылында руслар яши. Ойконимның Арбузов элементы Арбузов рус фамилиясенә карый. Бу исем мәҗүси чуваш Арбуз исеменнән ясалган булса кирәк [Магницкий, 1905, с. 29]. Рус теленә бу сүз XVI гасырда кыпчак теленнән кергән. Сүз фарсы телендәге *харбуза* (ишәк кыяры) сүзенә мөнәсәбәтле.

Абдул Салманы – Әлки районындагы татар авылы. Абдул гарәп телендәге Габдулла исеменең диалекталь формасы. Габдулла исә Алланың эпитеты. Мөхәммәт пәйгамбәрнең әтисенең исеме.

Базарлы Матак авылы – Әлки районының үзәге. Атаманың *базарлы* компоненты фарсы теленә нисбәтле [Срезневский, 1893, с. 39]. Рус теленә XIV гасырда татар теленнән кергән [Шанский, 1965, с. 10].

М.Р. Маллова атаманы санскритка нисбәтли. Аннан тибет телендәге *баджор*, монгол телендәге *бадзар* һ.б. килеп чыккан [Маллова, 1974]. Топонимнар ясаудан тыш, бу сүз белән кеше исемнәре һәм фамилияләре дә ясалган: Базаров, Бозоров, Пазарски, Базарбай һ.б. [Лезина, Суперанская, 1994].

Топонимнар ясауда да *базар* сүзе бик актив. Мордва республикасында Базарная Дубровка авылы, Пенза өлкәсендә Базарная Кеньша авылы, Ульяновск өлкәсендә Базарный Сызган, Базарный Урень авыллары, Кыргызстанда Базарный-Курган торак пункты һәм Базар-Турук елгасы, Азәрбайҗанда Базармай елгасы һәм Эрмибазар торак пункты, Саратов өлкәсендә Базарный Карабулак [Мурзаев, 1996, с. 151–152].

Татар Гадельшасы Чистай районында урнашкан. Атама *Гадел* һәм *шаһ* компонентларыннан тора. Шунысы кызык, атаманың компонентлары икесе ике телдән кергән. *Гадел* сүзе гарәп телендә турылыклы, гадел мәгънәсен бирә. *Шаһ* сүзе исә фарсы теленнән кергән һәм шаһ, патша мәгънәсен аңлата [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, т. III, б. 64; т. II, б. 700]. Ике сүзне бергә кушкач, Гадельшаһ (справедливый правитель) исеме ясалган.

Яңа Ибрай – Аксубай районындагы авыл. Ибрай – Ибраһим исеменең кыскартылган варианты. Ибраһим исеме безгә ислам дине белән гарәп теленнән кергән. Гарәп теленә бу исем, үз чиратында, яһүд теленнән кергән. Яһүд телендә аның яңгырашы – Авраам. Телдән телгә күчеп бу исем Аксубай районындагы авыл атамасына әверелгән.

Ислай һәм Иглай атамалары да гарәп сүзләренең кыскартылган вариантлары. Ислай гарәп телендәге ислам сүзеннән ясалган. Иглай антропонимы *игълям* сүзенә нисбәтле. *-ай*

суффиксы белән татар телендә күп исемнәр ясалган. Мәсәлән, Камай (Камалетдин), Гимай (Гыймалетдин) һ. б. [Куряева, 1992, с. 215]. Бүгенге көндә Яңа һәм Иске Иглай – Норлат районындагы, Ислай – Чистай районындагы авыллар.

Әлки районында Мулланур Вахитов исемендәге татар авылы бар. Атама татар халкының мәшһүр җәмәгать эшлеклесе хөрмәтенә бирелгән. Исемнең ике элементы да гарәп теленә нисбәтле. Вахитов фамилиясе Вахит исеменнән алынган. Исемнең Вәхидә исемле хатын-кыз варианты да бар [Саттаров, 1981, б. 55]. Атаманың икенче компоненты исә *мулла+нур* элементларыннан тора. *Мулла* сүзе белән тагын Алексеев районында Иске Муллино дигән рус авылы һәм Әлки районында Татар Мулла иле авылы атамалары ясалган. Бу сүз ойконимнар ясауда шактый продуктив булып чыккан. Татарстан һәм башка төбәкләрдә шактый күп атамалар ясалган. Мәсәлән, Яшел Үзән районында Мулла иле авылы һ.б.

Татарстандагы 17 географик объектның исемнәрендә *мулла/молла* сүзе очрый: Моллагыры, Моллакер, Моллатуы, Моллаберди, Моллаораз, Моллажепес һ.б. [Атаниязов, 1980, с. 210–211].

*Мулла* сүзенең ислам динендә рухани мәгънәсен аңлатканын һәркем беләдер, дип уйлыйбыз.

Әлки районындагы Мәүләшә авылы атамасының килеп чыгышы Мәүлишаһ [Саттаров, 1987, б. 138] исеменә нисбәтле. Мәүләшә исеме Мәүлишаһның диалекталь формасы. Атама гарәп телендәге *Мәүлә* һәм фарсы телендәге *шаһ* сүзләрен кушып ясалган [Саттаров, 1965, б. 270].

*Мәүлә* сүзенә антропонимик кушылмалар ялгану яки башка сүзләр кушылу юлы белән татар телендә байтак кына кеше исемнәре ясалганнар. Мәүләбай, Мәүләшаһ, Мәүләкол һәм башкалар. *Мәүлә* сүзенә нигезләнеп ясалган кеше исемнәренең кайберләре, диалекталь әйтелеш җирлегендә билгеле бер фонетик үзгәрешләр кичереп, авыл атамаларына әверелгәннәр. Мәүләшә авылының да атамасы шулай барлыкка килгән.

Атаманың икенче компоненты *шаһ* безгә фарсы теленнән кергән. Яңа Чишмә районында бу сүз белән ясалган Шахмай

исемле татар авылы бар. Исемгә компонент рәвешендә *шаһ* сүзе белән күп антропонимнар ясалган: Шаһбай, Шаһгали, Шаһморза, Шаһзадә һ.б. Шахмай исемендәге [*h*] авазы урынына [*x*] авазын куллануны диалекталь үзенчәлек итеп аңлатабыз.

Югары Әлморза, Түбән Әлморза – Әлки районындагы татар авыллары. Атамаларның Әлморза компоненты фарсы телендәге мирза титулына бәйле [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, б. 262]. Татар телендә *Морза* кеше исеме булып йөри [Саттаров, 1981, б. 131]. Атама төрки телләрнең күбесенә үтеп кергән. Карачай-балкар телендә *Мырза* формасы бар. Сүз, компонент буларак, күп кенә исемнәрнең составына кергән: Мурзабай, Мурзагул, Мурзамай, Мырзабек, Мырзатул, Әлморза, Мурзабек, Мурзабий, Мирзанур, Мирзахит, Морзабирде, Морзагали, Мурза рәвешендә бу сүз рус һәм фин-угыр телләренә дә кергән. Мәсәлән, Мурза, Мурзай, Мурзали, Мурзабай, Мурзабулат һ.б. Алар аркылы күп ойконимнар да ясалган. Мурзима һәм Мурзаят Мари Эл республикасындагы авыллар, Спасские Мурзы – Мордва республикасында. Безнең Татарстанда тагын Морза Бәрлебашы (Апас районы), Иске Мурзиха, Яңа Мурзиха (Алабуга районы) авыллары бар.

*Мирза* үзе дә кушма сүз. Ул гарәп телендәге *әмир* һәм фарсы телендәге *задә* сүзләрен кушып ясалган. Бу кушу фарсы телендә булган [Фасмер, 1964, с. 3–12; Шипова, 1976, с. 238; Баскаков, 1979, с. 246]). Сүздәге ике компонент та бүгенге көндә мөстәкыйль кулланылышта йөрләр. Татар телендә аеруча *әмир* сүзе еш очрый. Татарларда *Әмир* сүзе белән кеше исемнәре (мәсәлән, татар халкының яраткан язучысы Мирсәй Әмир), фамилияләр (Әмиров, Амиров һ.б.) һәм ойконимнар ясалган. Әмир бүгенге көндә Чирмешән районындагы татар авылы. Атаманың гарәп телендәге бирелеше – [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, б. 738].

Мөслим – Чистай районындагы авыл. Татарстанда бу атаманы, авыл исеменнән, тулы бер район йөртә. Бу сүз дә безгә гарәп теленнән кергән [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, б. 384]. Татарларда бу сүз кеше исеме булып кулланылышта йөргән, соңрак ойконимнарга күчкән.

Чистай районындагы Мөслим авылы А. Артемьев җыентыгында да телгә алына. Мөслим суы буена утырган бу авылдагы 221 хуҗалыкта 790 ир-ат һәм 739 хатын-кыз яшәгән [Список..., 1866, № 3327, с. 165]. К.П. Берстель җыентыгында күрсәтелгәнчә, авылда 1959 татар кешесе исәпләнгән [Список..., 1908, № 163, с. 221]. Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, Мөслим авылын Мөслим баба нигезләгән. Үзе монда Чирүле Шонталасыннан килеп утырган, дип әйтәләр. Авыл яныннан Бахта елгасының кушылдыгы булган Мөслим елгасы ага [Гарипова, 1990, б. 222].

Чирмешән районында Иске Кади һәм Яңа Кади авыллары бар. Һәр ике авыл да Олы Сөнчәле суына уң яктан килеп кушыла торган Сөлчә елгасы ярына утырган. Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, Иске Кади авылы оешуга 600 елдан да ким түгел. Авылга беренче булып Кади исемле бабай нигез салган. Аны Спас районындагы Әҗмәр белән янәшәдә утырган элекке Гөлбагар авылыннан килгән, дип әйтәләр.

Яңа Кади авылы Иске Кадидан аерылып чыккан. Аның оешканына 350 еллар була икән. Бу авылда (элекке исеме Утыз Имән) 1754 елда шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни туа.

Чистай районында Кади елгасы да бар. Ул Яуширмә елгасының кушылдыгы [Гарипова, 1990, б. 200].

Норлат районында Нариман исемендәге авыл бар. Г.Ф. Саттаров бу исемне борынгы иран теленә нисбәтли [Саттаров, 1981, б. 195]. Диалектларда Нарым, Нарим, Нарый, Нарыш кебек формалары очрый.

Алексеев районындагы Ромадан авылында бүгенге көндә руслар яши. Атама гарәп телендәге *рамазан* сүзенә нисбәтле [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, II т., б. 477]. Татарларда *Рамазан* сүзе кеше исеме булып йөри. *Ромадан* формасында ул рус теленә дә кергән [Куряева, 1992, с. 212].

Элекке Болгар җирләренең нәкъ үзәгендә хәзерге Спас районында Иске Рәҗәп һәм Яңа Рәҗәп авыллары урнашкан. Рәҗәп – гарәп сүзе [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, II т., б. 490]. Мөселман календаре буенча җиденче ай.

Садиково – Әлки районындагы рус авылы. Ойконимның нигезендә Садыков фамилиясе ята. Фамилия үз чиратында Садик исеменнән ясалган. В.К. Магницкий атаманы мәҗүси чуваш исемнәренә кертеп карый [Магницкий, 1905, с. 72]. Безнең фикеребезчә, атама гарәп теленә мөнәсәбәтле. «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә *садыйк* сүзе гарәп теленә нисбәтләнә [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, II т., б. 495].

Аксубай районында Такталы, Спас районында Татар Такталысы, Чуваш Такталысы, Әлки районында Иске Такталы, Яңа Такталы авыллары бар.

*Такта* сүзе безгә фарсы теленнән кергән. Фарсыча *tahte* – такта, калкан, күкрәк читлеге, тигез, яссы мәгънәләрен бирә [Мурзаев, 1996, с. 38]. Бу сүз топонимнар ясауда шактый продуктив: Азәрбайҗанда Тахтачай елгасы, Тахталар торак пункты, Төрекмәнстанда Тахтабазар шәһәре, Ставрополь краенда Тахта поселогы, Таҗикстанда Тахтакорум бистәсе һ.б. бар.

Бүгенге көндә татар телендә актив кулланылышта йөргән *чишмә* сүзе фарсы теленә нисбәтле [Гарипова, 1994, б. 47]. Дөрес, бу фикер белән килешмәүче галимнәр бар. Мәсәлән, Э.М. Мурзаев, бу сүз фарсы теленә төрки телләрдән кергән, дип күрсәтә [Мурзаев, 1984, с. 614].

*Чишмә* сүзе белән аталган атамаларның таралыш ареалы бик киң. Татарстандагы 57 авыл атамасында *чишмә* сүзе урын ала. Башкортстанда 17 авыл атамасы составында *чишмә* сүзе бар [Киекбаев, 1973].

Көнбатыш Кама аръягында түбәндәге атамалар *чишмә* сүзе белән ясалган: Яңа Чишмә районы һәм авылы, Норлат районында Чишмә авылы, Чирмешән районында Кара Чишмә, Кызыл Чишмә һәм Шишминская Крепость исемле авыллар бар. Оренбург өлкәсендә Чишмәбаш, Таҗикстанда Сары-Чашма һ. б. бик күп атамалар составына да бу сүз керә.

Татар теле сөйләшләрендә *чишмә* сүзенең төрдәшләре еш очрый. *Сишмә-тишмә-шишмә* вариантлары бар. Шишминская Крепость атамасы да шуңа мисал булып тора.

Ширбәт – Спас районындагы рус авылы. Атама гарәп телендәге *ширбәт* сүзенә мөнәсәбәтле. Татарларда бу сүз исем яки шәхси кушамат булып йөргән булырга мөмкин.

Якушкино – Норлат районындагы рус-чуваш авылы. Атама Якуш дигән кеше исеменнән ясалган. В.К. Магницкий атаманы чуваш мәҗүси исемнәренә кертеп карый [Магницкий, 1905, с. 97]. Татар телендәге диалекталь исемнәр арасында да Якуп, Якуш исемнәре бар. Исем гарәп-яһүди Якуб (Якуп) исеменең үзгәртелгән формасы. Иске татар телендә Йагкуп, Җакуп, Җәкуп, русларда – Яков, инглизләрдә – Джейк, Джеймс, немецларда – Якоб, французларда – Жан, Жакоб һ. б. [Саттаров, 1981, б. 228].

Ярдәм – Спас районындагы татар авылы. Бу сүз безгә фарсы теленнән килеп кергән. Татар телендә *ярдәм* сүзе кемнең дә булса хәленә кереп, хәлен җиңеләйтү өчен эшләнә торган эш, булышуны аңлата [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1979, т. III, б. 646].

Норлат районында Яңа Әлмәт, Иске Татар Әлмәте кебек татар авыллары бар. Г.Ф. Саттаров, Әлмәт топонимы Әлмөхәммәт дигән кеше исемен кыскарту, аның икенче һәм өченче иҗеген ташлап, беренче һәм дүртенче иҗекне янәшә әйтү нәтиҗәсендә барлыкка килгән, дип күрсәтә [Саттаров, 1984, б. 95]. Без аның фикеренә кушылабыз.

Академик М.З. Зәкиев карашынча, Әлмәт топонимы *элмә* (агач) сүзеннән һәм *-лы* кушымчасының диалекталь варианты булган *-ты* морфемасыннан тора, соңга таба *-ты* кыскарып *-т* калган. Бик борынгы сөйләмдә һәм хәзерге диалектларда *-лы* кушымчасының *-ты, -ды, -да* вариантлары очрый.

Күргәнебезчә, гарәп-фарсы атамалары Татарстанның Көнбатыш Кама аръягында шактый зур катлам тәшкил итәләр. Бу алынмалар татар теленә шулкадәр яраклашканнар ки, фән белән шөгыльләнмәгән татар кешесе аларны гарәп-фарсы сүзе итеп карамый да инде. Алар безнең телебезнең сүзлек хәзинәсен тәшкил итәләр.

## 2.5. Рус катламы

Бу катлам турында без җентекләп язуны максат итеп куймыйбыз, гомуми колоритны бирү өчен генә күрсәтеп китәбез. Бу үзе бер зур фәнни эш темасы була ала.

Аксубай районында Алексеевка, Беловка, Сергеевский, Федоровка, Емелькино, Сосновка (2), Кривоозерки, Новая Александровка, Образцовый, Носовка, Пионер, Покровка, Пономаревка, Федоровский, Индустриальный, Васильевка, Калиновка, Медянка, Новое и Старое Тимошкино, Владимировка, им. III Интернационала, Культура, Октябрь, Трудолюбово, Заря;

Алексеев районында Алексеевское, Александровка, Большие Полянки, Городок, Ивановский, Пановка, Приозерная, Березовая Грива, Лебедино, Новоспасск, Лебяжье, Горка, Андреевка, Березовка, Родники, Масловка, Сахаровка, Речное, Гурьевка, Языково;

Әлки районында Покровский, Борискино, Катюшино, Кошки, Анины Салманы, Демидовка, Хлебодаровка, Русский Студенец, Сушка, Черная Речка;

Яңа Чишмә районында Слобода Архангельская, Слобода Волчья, Ивановка, Новое Иванаево, Слобода Екатерининская, Лебедка, «Красный Октябрь», Горшкова, Ленино, Аверьяновка, Андреевка, Лебедка, Слобода Петропавловская, Благодаровка, Новая Деревня, Слобода Черемуховая;

Норлат районында Осиновка, Андреевка, им. III съезда, Чистовка, Егоркино, Единение, Михайловка (2), Октябрина, Петровский, Заречный, Клиновка, Некрасовка, Красный Октябрь, Калиновка, Березовка, Красномайский, Рождественский, Сосновка, Стекольный, Николаевка, Фомкино;

Спас районында Антоновка, Гусиха, Мартышачий, Кожаевка, Коминтерн, сов. «КИМ», Красная Слобода, Красный Вал, Приволжский, Порфировка, Ржавец, Кузнечиха, Покровка, Екатериновка, Никольское, Отрада, Полянки, Танкеевка, Иж-Борискино, Фадеевка, Три Озера;

Чирмешән районында Верхняя Каменка, Ибраево Каргали, Ивашкино, Красная Поляна, Лагерка, Мордовское Афонькино, Нижняя Каменка, Серебряный Ключ, Светлогорский, Старое

Сережкино, Девичья Поляна, Нагорный, Сосновка, Свобода, Андреевка, Павловка;

Чистай районында Суворовка, Змеево, Галактионово, Данауровка, Михайловка, Крутая Гора, Березовка, Старое Иванаево, Агрокультура, Николаевка, Сосновый Ключ, Малая Полянка, Подколок, Чистопольские Выселки, Керәшен Ялтаны ойконимнары теркәлгән.

Гомумән алганда, бу регионда 153 авыл атамасы рус теленә һәм рус теле аша бүтән телләргә нисбәтләнә. Бу авылларның барысында да руслар яшәми, күбесендә чувашлар, марилар һәм татарлар яши. Руслар бу регионда 235 торак пунктта яшиләр.

Бүлекне йомгаклап шуны әйтәсе килә: Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы – күп милләтле, халык составы ягыннан чуар регион. Бу хәл авыл атамаларында да чагылыш тапкан. Атамалар да чуар. Иң күп атамалар борынгы төрки телгә һәм рус теленә нисбәтле. Бүгенге көндә татарныкы яки чувашныкы саналып йөргән атамаларның да күбесе борынгы төрки телгә үк барып тоташа. Фин-угыр һәм рус атамалары белән дә шундый ук хәл. Аларның да күбесе борынгы төрки телгә карый.

Рус атамаларының, рус авылларының күплеге безгә патша хөкүмәте алып барган шовинистик сәясәтне ачып бирә. Борынгы болгар җирләренә русларны күпләп күчерү – татар халкын чукындырып бетерү максатыннан чыгып эшләнгән эш. Аз санлы халыклар белән ул бу максатына ирешкән дә. Күп кенә мари-мордва, чуваш авыллары рус исемнәрен йөртә. Бу халыкларның күбесе бүгенге көндә, үз милләтеннән читләшеп, үзен рус дип яздыра.

Өченче зур катламны чувашлар тәшкил итә. Бу чынлап та зур санлы халык булган, аларны да монда күпләп күчергәннәр. Чувашны борынгы Болгар җирләренә күчерү, аларны болгар итеп, татарны болгар тарихыннан аеру аны монголга кайтарып калдыру өчен эшләнгән эш булса кирәк. Чувашка «без болгар» дигән фикерне нәкъ менә Россия хөкүмәте керткән булырга тиеш.

Ләкин, нәрсә генә булмасын, татар халкы үз тарихын, телен онытмый. Безнең халыкка татарлык белән хурлану түгел, горурлану хас. Татарлыгыбыз шуңа күрә сакланып калган да.

# 3. ТАТАРСТАННЫҢ КӨНБАТЫШ КАМА АРЪЯГЫ ОЙКОНИМНАРЫНЫҢ СТРУКТУР-ЯСАЛЫШ КАЛЫПЛАРЫ

## 3.1 Лексик-семантик үзенчәлекләр

Тарихи-лингвистик тикшерүдә атамаларның лексик-семантик үзенчәлекләрен күрсәтү үзенә бер урын алып тора. Атаманың нәрсә аңлатканын белмичә, аның кайсы телгә караганлыгын да, төзелеш калыпларын аңлату да шактый авырлыклар тудыра. Бу үзенчәлекләрне күрсәтүгә генә багышланган фәнни хезмәтләр дә шактый дөнья күрде. Без дә атамаларның лексик-семантик үзенчәлекләрен читләтеп үтә алмыйбыз.

Ойконимнар җәмгыять ихтыяҗлары, бу атамаларны тудырган татар халкының тормыш шартлары, тарихи үсеше белән тыгыз бәйләнештә торалар. Атамалар кинәт, сәбәпсез генә тумый. Аерым тарихи чорларда ойконимнарга хас булган күп үзенчәлекләрнең иң күзгә күренеп торганы атама куюга нигез була, һәм ул бер исемдә чагылыш таба. Кешенең табигать белән булган көчле бәйләнеше күп очракта атамалар барлыкка килүгә хезмәт итә. Авылга исем, күбесенчә, нигез салган кеше исеменнән бирелә. Шулай ук елга, күл исемнәреннән дә күп атамалар ясалган. Табигать күренешләре атамалар ясалуга зур өлеш керткәннәр.

Авыл атамаларын мәгънә ягыннан чыгып тикшерү

1) атамаларның килеп чыгышларын дөрес аңлату өчен җирлек әзерли; ойконимнарның барлыкка килү закончалыкларын ачыклау өчен нигез тудыра;

2) сирәк очрый торган яки кулланылыштан төшеп калган, бары тик ойконимик берәмлекләрдә сакланган борынгы яки иске сүзләрне күзәтү-барлауга, аларның мәгънәләрен торгызуга ярдәм итә;

3) татар халкының шушы атамалар барлыкка килгән чорлардагы тормышын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен һәм башка өлкәләрдәге үсеш-үзгәреш дәрәҗәсен, үзенчәлекләрен күзалларга мөмкинлек бирә.

### 3.1.1. Апеллятив ойконимнар

Ономастикада килеп чыгышлары башка класска караган ялгызлык исемнәреннән барлыкка килгән ялгызлык исемнәрен эпонимик ясалышка, ә турыдан-туры күмәклек исемнәреннән ясалган ялгызлык исемнәрен апеллятив ясалышка кертәләр [Подольская, Суперанская, 1969, с. 142].

Көнбатыш Кама аръягындагы апеллятив ойконимнарга без «авыл», «өй», «йорт», «тирмән» терминнары белән ясалган ойконимнарны, эшне, вакыйганы, хәрәкәтне белдерүче сүзгә нисбәтле авыл атамаларын һәм идеологик төшенчәләрне (башлыча Октябрь революциясе һәм аннан соңгы вакыйгаларны, тормыш-көнкүрешне) белдерүче лексемалардан ясалган ойконимнарны (ойконимик советизмнар) кертеп карадык.

**«Авыл» термины кулланып ясалган атамалар**

Торак пунктлар һәм аларны барлыкка китерүче каралты-кураларның төре, функцияләре, милли үзенчәлекләре һ.б. яклары теге яки бу халыкның хуҗалык һәм мәдәни тарихы, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре белән бик тыгыз бәйләнгән. Төрки халыкларның байтагының, шул исәптән болгар бабаларыбызның, моннан мең еллар элек үк күчмә тормыштан утрак тормышка күчүләре төрле тип торак пунктлар (шәһәрләр, авыллар, кышлаклар) төзүдә бай тәҗрибә туплауга һәм осталыкка китергән.

«Татарстан АССР тарихы»нда Идел буе Болгар дәүләте шәһәрләре һәм аларның төзелеш-корылыш үзенчәлекләре хакында түбәндәге мәгълүматлар хәбәр ителә: «Болгар дәүләтендә һөнәрләр һәм сәүдә үсү нәтиҗәсендә X гасырда шәһәрләр һәм шәһәр тибындагы поселоклар килеп чыга. Ләкин илнең төп халкы барыннан да бигрәк Идел һәм Кама кушылдыклары буена урнашкан бик күп санлы авылларда яши. Илнең үзәген-

дәге бу авыллар зурлыклары белән аерылып торалар, ә чик җирләрдә, бигрәк тә урманлы районнарда, кечкенә авыллар күбрәк була» [Татарстан АССР тарихы, б. 45–47].

«Авыл» ойконимик термины – гомумтатар телендә киң таралган, әдәби телебезгә дә, барлык татар сөйләшләренә дә хас булган һәм актив куллана торган лексик берәмлек. Борынгы төрки телдә «агыл» сүзе «загон для скота» мәгънәсен белдергән [ДТС, 1969, с. 18]. Гомумтөрки *агыл, айыл*, *ауыл, оwыл, авыл* ойконимик терминының борынгы «агыл, терлекләрне яисә аулап тотылган хайваннарны беркадәр вакыт ябып асрау өчен ясалган киртә, ихата, кура» сүзеннән ясалган булуы мәгълүм. Авыл сүзе үзе исә *аг – аң – ау* тамырына нигезләнеп барлыкка килгән, дигән караш бар [Севортян, 1974, с. 84].

Н.Б. Борһанова карашынча, татар халкы телендә *авыл* (аwыл) сүзе чагыштырмача соңрак активлашкан булырга тиеш [Борһанова, 1982, б. 51]. Казан ханлыгы чорындагы авыл атамалары составында бу ойконимик термин бөтенләй диярлек очрамый [Саттаров, 1998, б. 154]. Бүгенге көндә дә ойконимнар составында бу сүз артык еш күренми. Без өйрәнгән регионда ул дүрт авыл атамасы составында бар. Яңа Чишмә районындагы Новая Деревня дигән рус авылының татарча атамасы Яңа Авыл, Иске Авыл – Норлат районындагы – татар, Әлки районындагы рус авылы. Әлки районында тагын Татар Мулла иле дигән татар авылы бар.

**«Өй», «йорт» терминнары белән ясалган ойконимнар**

Казан татарларындагы *җорт,* әдәби телебездәге һәм мишәрләрдәге *йорт* ойконимик терминнары хәзер «авыл, торак пункт» мәгънәсендә кулланылмый, бәлки «өй», «торак» төшенчәсен белдерү өчен генә хезмәт итә. Иске татар телендә бу термин, «өй», «торак» мәгънәсенә ия булу белән беррәттән, шушы мәгънәсенә нигезләнеп барлыкка килгән «авыл», «торак пункт» төшенчәсен белдерү вазифасын да башкарган [Саттаров, 1998, б. 160]. Төрки халыкларда *йорт* (юрта) сүзе борынгы заманнарда «күчеп йөри торган территория, тору урыны» төшенчәсен белдерү белән бергә, «ил, дәүләт» мәгънәсенә ия булган. Себер йорты, Идел-йорт, Болгар йорты һ.б. [Радлов, 1905, с. 459].

Йорт сүзе белән Йортамон, Йортбагыш, Йортлыбай, Йортый, Йортыш кебек кеше исемнәре, соңрак алардан Юртыев, Юртеев, Юртаев һ.б. кебек фамилияләр калган.

Без тикшергән Спас районында «йорт» сүзе белән Урманасты Йорткүл, Урта Йорткүл, Кырый Йорткүл кебек татар авыллары ясалган. Спас районында бу сүз белән микротопонимнар да ясалган. Мәсәлән, Иске йорт – басу исеме (Карамалы авылы), Иске йорт чокыры – чокыр исеме (Яңа Рәҗәп авылы) һ.б.

Татар телендәге «өй» сүзе «йорт, тору урыны» мәгънәләрен аңлата. Саннар белән кушылып килгәндә ул «авыл» мәгънәсен дә бирә. Өч Өйле, Дүрт Өйле кебек авыл атамалары, авылның кечкенә икәнлеген хәбәр итә. Дүрт Өйле – бүгенге көндә Чистай районындагы татар авылы.

**«Бүләк» термины белән ясалган ойконим**

Татар һәм башкорт телләрендә зур авылдан бүленеп чыккан «яңа авыл», зур «авылның бүлентесе, бүлеге» мәгънәсендә чикләнгән рәвештә булса да *бүләк* ойконимик термины да кулланыла [Саттаров, 1998, б. 162].

Бүләк термины зур авылдан бүленеп, күчеп утырган «яңа авыл» төшенчәсенә ия. Бүләк дигән авыллар – заманында зуррак авыллардан күчеп, бүленеп чыккан бүлекләр, ягъни «яңа авыллар». Татарстанның Актаныш һәм Мөслим районнарында – Бүләк, Минзәлә районында Таллы Бүләк, Ленин Бүләк дигән татар авыллары бар. Башкортстанда мондый исем йөртүче авылларның саны дистәдән артык.

Без тикшергән Алексеев районында Тигән Бүләк дигән чуваш-мордва авылы бар. «Өлешеңә тигән көмешең» ди татар халык мәкале. Бу очракта, ягъни аерылып чыккан кешегә (бүленгән) эләккән (тигән) өлеш (бүләк) мәгънәсе килеп чыга.

«Бүләк» топонимик термины һәм «бүләк» антрополексемасының асылында «бүләк» күмәклек сүзе ята. Бу сүзнең этимологиясе *исә* «бүл» тамырына барып тоташа. *Бүл* тамырына *-әк* ясагыч кушымчасы ялганып *бүләк* сүзе барлыкка килгән. Татар телендә шушы тамырдан *бүлү, бүлүче, бүленү, бүлгеч* һ.б. сүзләр ясалган.

Г.Ф. Саттаров татар теленнең урал һәм байкыбаш сөйләшләрендә *бүләк* сүзенең «вак урман, әрәмәлек» мәгънәсендә кулланылышта йөрүен дә күрсәтә [Саттаров, 1973, б. 177].

**Бүрәнәләр (свайлар) өстендә утырган өйне аңлатучы «булдырь» термины белән ясалган атама**

Булдырь ойконимы рус телендә «дом, стоящий на отшибе» мәгънәсен бирә. Чуваш телендәге *pelder* (навес на двух столбах) сүзенә мөнәсәбәтле [Фасмер, 1986, с. 238].

**Торак пунктларның состав өлешләрен белдерүче ойконимик терминнар һәм алардан ясалган ойконимнар**

Мәсәлән, бистә, мәйдан, проспект, базар, урам, тыкрык, оч, аймак, җыен, курмыш, һ.б. терминнар керә.

Гомумтатар телендәге *базар* сүзе «сәүдә итү урыны һәм корылмалары» мәгънәсен бирә. Фарсыча «сәүдә итү көне, базар; бәйрәм көн» төшенчәсен белдерә. Э.М. Мурзаев «базар» сүзенең этноним һәм антропоним буларак кулланылуын, диңгез буендагы яссы кыя мәгънәсе булуын һәм диңгез кошларының күпләп җыелган урыннарының да базар дип аталуын күрсәтә [Мурзаев, 1984, с. 63].

Төрки халыкларда, шул исәптән болгар-татарларда, базар көнен шатлыклы-куанычлы көн, бәйрәм көн дип исәпләгәннәр һәм шул көнне туган ир балага Базар, Базарбай, Базарбәк, Базархан кебек исемнәр кушу йоласы булган. Базар исеменнән татарлардагы һәм руслардагы Базаров фамилиясе ясалган [Саттаров, 1998, б. 167].

Татарстанның Әлки районының үзәге – Базарлы Матак авылы. Элек Базарлы Матак авылында һәр шимбәдә зур базар булган. Базарлы Матак сүзтезмәсенең икенче өлеше *Матак* – борынгы чуваш исеме, ә беренче өлеше – *базарлы* эпитеты – бу авылны башка Матак авылларыннан аеру, конкретлаштыру хезмәтен үти. Әлки районында тагын Иске Матак, Югары Матак дигән чуваш авыллары бар.

Асылында *кор, кору* – «төз, төзү» тамыры яткан *кормыш* < *кормыйш*, *кормаш* < *курмыш* сүзе иске татар телендә «выселок», «зур авылдан күчеп утырган яңа авыл», «яңа кормыш,

корылыш» мәгънәсен белдерү өчен ойконимик термин булып хезмәт иткән. Татарстан топонимиясендә шушы терминга нисбәтле рәвештә кайбер татар авылларының исемнәре барлыкка килгән. Безнең регионда Кормыш – Норлат районындагы татар авылы. Кормаш исемле авыллар Апас, Сарман, Актаныш районнарында да бар.

Чуваш, мари һәм мордва телләрендә курмыш ойконимик термины аерым утырган торак йортны яки тәртипсез рәвештә таркалып утырган йортлар төркемен белдерә [Никонов, 1966, с. 222]. Н.Б. Борһанова, мордва телләренә курмыш («авыл») һәм рус тел сөйләшләренә курмыш («отдаленная пашня», «поселок») сүзе – татар теленнән кергән борынгы алынма, дип саный [Борһанова, 1982, б. 58].

**«Тирмән» термины белән ясалган ойконимнар**

Норлат районында Рус Тирмәннеге, Чуваш Тирмәннеге исемле авыллар бар. Атамалар татар теленең көнбатыш диалектындагы тирмән сүзенә нисбәтле. «Тирмән» сүзе мишәр диалектының Чистай сөйләшендә тегермәнне аңлата. Без монда диэреза күренеше белән очрашабыз [Әхәтов, 1984, б. 101]: тегермән сүзенең *г* авазы төшеп калган.

Татар телендә *тегермән* термины гомум кулланылышка ия. Татар халкының җанлы сөйләм телендә фонетик тартылыш кичергән *тирмән* варианты активрак кулланыла [Саттаров, 1998, б. 201].

Тегермән сүзе белән Татарстанның башка районнарында да ойконимнар ясалган. Югары Тәкермән – Минзәлә районында, Тегермәнлек – Мөслим районы һ. б.

**«Мунча» ойконимик термины белән ясалган ойконим**

Норлат районында **Русская Менча** дигән рус-чуваш авылы бар. «Менча» татар телендәге «Мунча» сүзенең рус теленә кабул ителгән фонетик варианты дип саныйбыз.

Татар телендә гомум кулланылышка ия булган «мунча» ойконимик терминының генезисын рус телендәге *мовиница* сүзенә кайтаручылар бар. Борынгы рус телендә «мовница, мовня, мовь – баня «мунча» [Кочин, 1937, с. 192]. «Парланып, чабы-

ньп юына торган махсус бина» мәгънәсенә ия. Татар топонимикасында Өчмунча, Бишмунча, Дүртмунча, Иске Мунча кебек татар авыллары бар.

**«Кирпеч» сүзе белән ясалган ойконим**

Кирпичное – Норлат районындагы авыл. Авыл атамасы татар телендә төзелеш материалын аңлаткан *кирпеч* сүзеннән ясалган. *Кирпеч* сүзе безгә борынгы төрки телдән килгән [ДТС, 1969, с. 301]. Бу атама гадәттә авылда кирпеч чыгаручы завод булганда кушылган.

**«Каек» сүзе белән ясалган ойконим**

Каек авылының атамасы борынгы төрки телдәге *Qajq* «көймә, лодка, челн» сүзенә мөнәсәбәтле [ДТС, 1969, с. 607].

**Эшне, вакыйганы белдерүче сүзгә нисбәтле авыл атамалары**

XVI–XVII гасырларда хәрби корабльләр төзү өчен казна урманнарында агач кисү һәм аны мул сулы елга буйларына тарттыру белән шөгыльләнгән дәүләт крестьяннарын «лашман» дип атаганнар. Шушы вакыйгадан Лашман авыл исеме булып үсеп чыккан.

Көнбатыш Кама аръягына патша хөкүмәте бик күпләп йомышлы татарларны күчереп утырткан, шулай да араларында ясаклы татарлар да булган. Бу атамалар авыл исемнәренә дә күчкәннәр. Ясак авылының крестьяннары ясаклы татарлар булганнар. Шул сәбәпле, авылга *ясак* атамасы кулланылган булса кирәк. *Ясак* сүзе, дәүләт казнасына туры салым мәгънәсендә, рус телендә дә кулланылышта йөргән. Руслар килгәнче үк дәүләткә ясакны кыйммәтле мехлар белән түләү булган. XVII гасырдан ясакны акча белән түләргә рөхсәт ителгән. Ясак түләү XX гасырга кадәр дәвам ителгән [Энциклопедический словарь, 1963, т. III, с. 729]. Рус теленә бу сүз XV гасырда татар теленнән кергән. Татар телендә бу сүз «дань, подать, налог» мәгънәсендә кулланылган [Фасмер, 1964, т. 4, с. 564].

Чирүле (йомышлы) Шонтала авылы атамасы белән дә шундый ук хәл. Бу авылның кешеләре йомышлы татарлар булганнар, ясаклы татарларга караганда өстенрәк катлам саналганнар.

*Чирү* сүзе борынгы төрки телдә «гаскәр» мәгънәсен аңлаткан. XVII гасырларда *чирүле* сүзе «служилое» («йомышлы) мәгънәсендә йөргән.

**Хәрәкәтне белдерүче сүзгә нисбәтле авыл атамалары**

Әлки районында Иске һәм Яңа Үргәагар авыллары бар. Үргәагар «үргә» һәм «агар» сүзләренннән тора. *Үргә* сүзе югарыга, өскә таба мәгънәсен бирсә (*үр+гә* – юнәлеш килеш кушымчасы), *агар* сүзе *ага+р* (III зат киләчәк заман хикәя фигыль конструкциясе) булып ясалып, «суның югарыга таба агачагы» мәгънәсен бирә. Мондый конструкцияле атамалар Татарстанда тагын бар – Малтабар һәм елга исеме – Уяр елга.

*Яшәүче* атамасы сүзтезмәнең икенче өлеше (географик термин) төшеп калу юлы белән ясалган фигыльле топоним [Саттаров, 1998, б. 312]. Мондый топонимнарның фигыль белән белдерелгән атрибутив өлеше тулысынча мөстәкыйльләшә. Күчте, Китмәс, Тыңламас, Эт басмас һ.б.

**Мифологик терминнарга нисбәтле географик атамалар**

Болгар-татар топонимиясендә борынгы географик атамаларның барлыкка килүендә мәҗүси ышанулар, йолалар һәм мифлар шактый урын тоткан, тотемистик һәм анимистик ышануларга, мифларга бәйләнешле борынгы географик атамалар пәйда булган.

Безнең регионда мондый атамалар күп очрамый. Бу бүлеккә без бары тик Аксубай районындагы Иске һәм Яңа Кәрәмәт авыллары атамаларын гына кертеп карыйбыз.

Н.И. Ашмарин, *кирәмәт* сүзе гарәп теленнән кергән һәм ул «изге урын» дигән мәгънәне аңлата, дип саный [Ашмарин, вып. VI., 1934, с. 230–240]. В.Г. Егоров гарәп телендә кирәмәт сүзе «могҗиза», «изге кешегә хас гайре табигый көч мәгънәсен аңлата, ди [Егоров, 1964, с. 113].

Чуваш мифологиясендә усал рух, көч Кирәмәт исемен йөртә [Саттаров, 1973, б. 206]. Мариларда, чувашларда, чукындырылган татарларда, мәҗүсилек чорында болгарларда, мәҗүсилекнең бер төре буларак, кирәмәт агачын (карама төреннән булган агач, хәзер сирәк очрый) аллалаштыру, шуңа табыну йо-

ласы булган. Татарстанда 30 га якын Кирәмәт елгасы, 10 нан артык Кирәмәт чишмәсе бар [Гарипова, 1984, б. 64, 164]. Аксубай районында Иске Татар Кәрәмәте авылы яныннан да Кирәмәт елгасы ага. Ул Кече Сөлчә суының уң кушылдыгы [Гарипова, 1990, б. 211].

**Татар телендә географик объектларның физик характеристикаларын белдерүче апеллятивлардан ясалган ойконимнар**

А) географик объектның урнашу урыны яки урнашу тәртибен белдерүче сүзләрдән ясалган ойконимнар. Көнбатыш Кама аръягы ойконимиясендә *югары, урта, түбән* урын рәвешләре катнашып күп кенә авыл атамалары ясалган.

*Югары* сүзе белән түбәндәге ойконимнар ясалган: Югары Татар Майнасы, Югары Колчурино, Югары Кәчи, Югары Норлат, Югары Кәминкә, Югары Чыгтай, Югары Кондрат.

*Урта* сүзе белән ясалган атамалар: Урта Тигәнәле, Урта Әлки, Урта Биктимер, Урта Камышлы, Урта Чаллы, Урта Йорткүл, Урта Талкыш.

*Түбән* сүзе белән ясалган ойконимнар: Түбән Саурыш, Түбән Татар Майнасы, Түбән Тигәнәле, Түбән Биктимер, Түбән Колчура, Түбән Әлки, Түбән Салман, Түбән Норлат, Түбән Чаллы, Түбән Каменка, Түбән Кармалка, Түбән Чыгтай, Түбән Кондрат.

Татар топонимиясендә *баш – башы* сүзләре катнашып ясалган географик терминнар бу объектның икенче бер географик объектның (елганың, күлнең һ.б.) башына, башланып киткән җиренә яки азагына, тамагына, беткән җиренә урнашуын тәгъбир итәләр [Саттаров, 1998, б. 302]. Безнең регионда бу сүз белән ясалган атамалар: Рус Чиябашы, Сүлчәбаш, Татар Чиябашы.

«Кырый» сүзе белән Кырый Йорткүл (Спас районы), «асты» сүзе белән Алексеев районында Урман асты Шанталасы, Чирмешән районында Урман асты Өтәмеш, Спас районында Урман асты Йорткүл атамалары ясалган.

Ә) географик объектның искелеген-яңалыгын, температурасын белдерүче сыйфат сүзләрдән ясалган ойконимнар. Татар

телендә географик объектның искелеге яки яңалыгы иске-яңа антонимик сыйфатлары белән белдерелә. Башлыча торак пункт атамалары составында иске-яңа эпитетлары еш урын ала [Саттаров, 1998, б. 298]. *Иске* сүзе белән бу регионда 31 торак пункт атамасы, *яңа* сүзе белән 22 атама ясалган. Без аларны югарыда күрсәтеп киттек инде, кабатлап тормыйбыз.

Татар телендә географик объектларның башлыча су чыганакларының, температурасы *салкын, суык – җылы, кайнар* антонимик сыйфатлары белән белдерелә. Болардан, эпитет буларак, *салкын, суык* синонимик сыйфатлары шактый еш кулланыла. Безнең регионда аларның *суык* сүзе белән генә атама ясалган: Татар Суыксуы һәм Рус Суыксуы Әлки районындагы авыллар.

Б) географик объектның төгәл санын белдерүче топонимик сүзтезмәләрдән гыйбарәт атамалар. Мондый атамаларга Спас районындагы Өч Күл һәм Чистай районындагы Дүрт Өйле авыл исемнәре керә.

В) географик объектның төсен белдерүче сыйфат сүзләрдән ясалган ойконимнар.

Төрки телләрдә ялгызлык исемнәрен ясауда төс белдерүче сыйфатлардан иң активлары *ак* һәм *кара* сүзләре, алардан кала *кызыл, соры, коңгырт, яшел, зәңгәр, күк* сыйфат сүзләре урын ала.

Җирле географик атамалардан *ак* һәм *кара* сүзләренең семантикасы *ак* һәм *кара* сүзләренә генә бәйле булмаска мөмкин дигән караш та бар. Акад. А.Н. Кононов *кара ком, кара су* кебек терминнарда *кара* сүзенең «коры җир» мәгънәсен, ә *ак ком*, *ак су* терминнарында *ак* сүзенең «агу, агыш, агылыш» фигыле мәгънәсен белдерүе турында яза [Кононов, 1954, с. 84–85].

Акад. В.В. Радлов төрки телләрдә омонимик «кара» сүзенең берничә мәгънәгә ия булуын күрсәтә [Радлов, 1905, т. II, с. 132–142]. Беренче мәгънәсе борынгы төрки телдә «коры җир» төшенчәсен белдергән *кара* сүзенең (исемнең) соңрак кара төсне белдерә торган өстәмә мәгънәсе (сыйфат) барлыкка килгән булуы мөмкин [Саттаров, 1998, б. 276]. В.В. Радлов *ак* сүзенең: 1) белый 2) белый, чистый, несмешанный 3) добродушный, чистосердечный, невинный мәгънәләрендә кулланылуын терки

[Радлов, 1905, т. I, с. 88–89]. В.В. Бартольд, табигый елгалар – Аксу, ясалган каналлар Карасу исемен йөртәләр, дип күрсәтә [Бартольд, 1965, т. 3, с. 316]. Г.К. Конкашпаев фикеренчә, Аксу дип аталган елгалар биектән агып төшәләр, шуңа күрә алар кызу агалар һәм күбекләнеп ак төскә керәләр. Алар гадәттә таулы регионнарда очрыйлар [Конкашпаев, 1969, с. 75]. Э.М. Мурзаев *ак* сүзенең җирле географик атамаларда 1) елга тамагы; 2) ак, агу, агым; 3) мәңгелек кар белән капланган тау түбәсе мисалларын китерә [Мурзаев, 1984].

*Ак* һәм *кара* сүзләренең топонимикада «көнбатыш» (*кара*) һәм «көнчыгыш» (*ак*) мәгънәләрен алулары да билгеле. Моның мисалларын азәрбайҗан топонимикасына таянып, Э.К. Мехрамлиев китерә: Карагюней, Караязы, Аггюней, Агязы.

Э.М. Мурзаев *кара* сүзенең топонимикада 1) елганың тирән урыны; 2) чокыр; 3) «черный»; 4) начар, әшәке; 5) таулардагы кар ятмаган урын мәгънәләре барлыгын күрсәтә [Мурзаев, 1984, с. 254]. Казак топонимисты Е. Койчубаев, *ак* сүзе кайбер топонимнарда -*ык* аффиксының төшеп калуы нәтиҗәсендә ясалган, дип күрсәтә. Мәсәлән, *акыксу* (агым су) – *аксу*, *акыккел* (ага торган күл) – *аккел* һ.б. «Кара» сүзе турында ул Кононов фикеренә кушыла [Койчубаев, 1965, с. 185–187].

Көнбатыш Кама аръягында *ак* сүзе белән түбәндәге атамалар ясалган: Аксубай районында Кече Аксубай, Яңа Аксубай, Кече Акташ авыллары, Әлки районында – Аппак, Яңа Чишмә районында – Акъяр, Чирмешән районында – Аккирей, Чистай районында Актау, Акбулат авыллары.

Э.М. Мурзаев Актау сүзен «урмансыз, ачык җирдәге, кырдагы тау» дип аңлата [Мурзаев, 1984, с. 49].

*Кара* сүзе белән ясалган атамалар: Аксубай районында Карасу авылы, Әлки районында – Каракүл, Иске Карата (рус телендә Черная Речка), Норлат районында – Каракүл, Чирмешән районында – Кара Чишмә, Чистай районында Каратаевка, Карасье Озеро авыллары.

Татар топонимиясендә составларында *кызыл* сыйфат сүзе урын алган географик атамалар шактый күп. Аларның күбесендә

*кызыл* сүзе: 1) турыдан-туры төсне белдереп килә; 2) байтагында символик рәвештә Октябрь революциясе, социалистик тормыш, үзгәреш-яңарыш төшенчәсен аңлата [Саттаров, 1998, б. 279]. Рус телендә *красный* сүзе «красивый, хороший, великолепный, прекрасный» мәгънәләрен аңлата.

Е. Койчубаев, елга һәм күлләр составында *кызыл* сүзе «мелкий, неглубокий» мәгънәләрен бирә, дип күрсәтә [Койчубаев, 1974, с. 161–162]. Рус телендәге мәгънәләре төрки телләрдә юк.

Безнең регионда *кызыл* сүзенең ике мәгънәсе кулланыла.

1) Кызыл Яр, Кызыл Тау – Аксубай районында; Кызыл Чишмә, Зур Кызыл Яр, Кече Кызыл Яр – Алексеев районында; Кызылъяр, Красная Поляна, Кызыл Чишмә – Чирмешән районында; Красный Яр, Кызыл Ялан –Чистай районында.

2) Кызыл Уракчы – Алексеев, Кызыл Юл – Норлат, Кызыл Болгар – Чистай районнарындагы авыллар. Шул ук мәгънәдә рус телендә түбәндәге атамалар ясалган. Красный Октябрь, Красномайский, Красная Слобода, Красный Вал.

Г) географик объектның формасын, күләмен, өлешен, халәтен, караңгылык-яктылыгын белдерүче сүзләрдән ясалган ойконимнар. Татар телендә географик объектның формасын, күләмен, зурлыгын-кечкенәлеген, халәтен һ.б.ны белдерү функциясен башкара торган сыйфат һәм рәвеш сүзләр шактый күп: *түгәрәк, текә, тигез, кәкре, биек, тәбәнәк, озын, кыска, тирән, сай, зур, кечкенә, бәләкәй, олы, эре, калын, нечкә, ачык, ябык, караңгы, якты, коры, юеш* һ. б. [Саттаров, 1998, б. 282].

*Зур ~ олы* синонимдаш сыйфаты аергыч функциясендә килгән (сыйфат + исем модельле) сүзтезмәдән гыйбарәт атамалар: Зур Тигәнәле, Зур Кызыл Яр – Алексеев районы. Зур Алан – Әлки районы, Олы Талкыш – Чистай районы.

*Кечкенә, кече* сыйфат сүзләре аергыч функциясендә килгән (аерылмыш өлеше географик терминнан торган) сүзтезмәләрдән гыйбарәт географик атамалар: Аксубай районында – Кече Аксубай, Кече Акташ, Кечкенә Сөнчәле; Норлат районында – Кече Күлбай-Мораса, Кечкенә Камышлы; Чирмешән районында – Кече Чыгтай; Чистай районында – Кече Талкыш.

Кәкре Күл – Аксубай, Кәкре Атау Норлат районнарындагы авыллар.

Алексеев районында Юеш Көрнәле, Коры Көрнәле исемле авыллар бар.

Шушы ук рәткә керә торган *якты* сүзе белән Норлат районында Якты Күл авылы атамасы ясалган.

**Туганлык терминнарына нисбәтле ойконимнар**

Мондый атамаларга күпмедер күләмдә Азеево (Акъяр) һәм Ака авыллары исемнәрен кертергә мөмкин. *Азеево* атамасы татар диалектларындагы *әзи* «старший брат» сүзеннән барлыкка килгән [Куряева, 1992, с. 40]. Борынгы төрки *эзи* – «старший брат» [ДТС, 1969, с. 58]. *Ака* сүзе күп төрки телләрдә кулланыла. Аның берничә мәгънәсе бар: 1) брат деда по отцу 2) отец 3) дядя 4) старший брат 5) пожилой мужчина 6) старшая сестра, тетя [Мокшанско-русский словарь, 1949, с. 26]. Бу сүз «старшая сестра» мәгънәсендә мордва теленә дә кергән [Марийско-русский словарь, 1956, с. 20].

*Ака* сүзе борынгы төрки сүзлектә «старший брат» мәгънәсендә китерелгән [ДТС, 1969, с. 7]. Р.И. Куряева атама *акай* «лупоглазый» сүзенә дә мөнәсәбәтле булырга мөмкин дип күрсәтә [Куряева, 1992, с. 40].

**Ойконимик советизмнар**

Барлык төр ялгызлык исемнәре, тел факты буларак, җәмгать төзелеше һәм аның тарихы белән бик тыгыз бәйләнгән. Совет хакимиятенең җитмеш биш елы дәвамында татар теленең барлык тармаклары да киң колачлы, тирән һәм катлаулы үсеш, баю, тулылану процессын кичерде. Социалистик тормыш, шәһәр, поселок, авыл һ.б. топонимиясенә һәм антропонимиягә сизелерлек тәэсир ясады [Саттаров, 1998, б. 158–165].

Көнбатыш Кама аръягындагы советизмнарның үзләрен берничә бүлеккә бүлеп карыйбыз.

А) революцион эшчәнлек күрсәткән кешеләрнең фамилияләре ойконимнарга күчте: Әлки районында – М. Вахитов исемендәге авыл, Яңа Чишмә районында – Ленино авылы, Нариман исемендәге авыл – Норлат районы, Чирмешән районында –

Ульяновка, Чистай районында – Галактионов, Домоуровка авыллары, Аксубай районында – Носовка авылы.

Ә) яңа, социалистик тормыш идеяләрен чагылдырган сүзтезмәләрне топонимлаштыру. Мондый сүзтезмәләрнең беренче компоненты булып күбесенчә *кызыл, якты, яшь, яңа, азат, ирек, йолдыз* кебек сүзләр кулланыла. Алар үзләре генә дә шундый ук мәгънәдә киләләр. Мондый атамаларга Аксубай районында – Азат, Кызыл Тау, Батыр, Алга; Алексеев районында – Кызыл Чишмә, Кызыл Уракчы, Ялкын; Әлки районында – Йолдыз; Норлат районында – Кызыл Юл, Үрнәк, Якты Күл; Спас районында – Ярдәм, Йолдыз, Ирек, Үрнәк; Чирмешән районында Кызыл Чишмә, Якты Тау; Чистай районында – Яңа Урал, Кызыл Болгар, Кызыл Ялан авыллары исемнәре керә.

Б) Октябрь революциясеннән соң топонимиябездә рус теленнән һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән шактый гына сүзләр урын алдылар, ойконимнарга әверелделәр. Аксубай районында – Образцовый (*үрнәк*нең русча варианты, татар телендәге Үрнәк русчаның калькасы), «МЮД», Пионер, Индустриальный поселогы, им. III Интернационала, Культура, Октябрь, Заря; Әлки районында – Катюшин; Яңа Чишмә районында – Красный Октябрь поселогы; Норлат районында – им. III съезда, Октябрина, Октябрь, Кирпичное, Красномайский, Стекольный, п. Первой бригады, п. Третьей бригады; Спас районында – Коминтерн, п. «КИМ», Красная Слобода, Красный Вал; Чирмешән районында – Красная Поляна, Лагерка, Светлогорский, Свобода; Чистай районында – Агрокультура.

Апеллятив лексикадан ясалган топонимик берәмлекләр барыннан да элек, терминологик нигезле булып, ягъни теге яки бу терминга яки лексикага нигезләнеп ясалып, регионга күп төрле һәм күп яклы тарихи-географик характеристика бирәләр. Тарих дәвамында татар теленең топонимик системасын барлыкка китерүдә апеллятив лексикага караган җирле географик объектларның физик үзенчәлекләрен билгеле бер урында булган берәр мөһим вакыйганы, эш яки хәрәкәтне белдерүче лексемалар һ.б.

зур роль уйнаганнар. Без өйрәнә торган Көнбатыш Кама аръягы территориясе ойконимнары да бу кагыйдәгә буйсына.

## 3.1. Онимик ойконимнар

### 3.1.1. Антропонимнарга нисбәтле ойконимнар

Аерым бер регионның ифрат катлаулы һәм бер-берсе белән бик тыгыз бәйләнгән топонимик системасында антропотопонимнар һәм этнотопонимнар кешеләрнең һәм аларның физик һәм акыл эшчәнлегенең географик атамаларда үзенчәлекле чагылышын хасил итәләр. Менә шуңа антропотопонимнар, кеше белән җәмгыять, кеше белән табигать арасындагы үзара тыгыз бәйләнешләрнең, күп төрле физик һәм рухи мөнәсәбәтләрнең тел берәмлеге саналган исем-атамаларда үзенчәлекле чагылышыннан гыйбарәт катлаулы лингвистик продукт булган хәлдә, ономастика фәненең иң зур һәм мөһим тармаклары антропонимика һәм топонимика аралыгында барлыкка килгән иң яшь һәм яңа бер тармагы – антропотопонимиканың төп тикшеренү предметын тәшкил итәләр [Саттаров, 1998, б. 7].

Төрки халыклар топонимиясе антропотопонимнарның зур урын алуы белән характерлана. Азәрбайҗан тарихчысы һәм топонимисты А.А. Гусейнзадә хәзерге Азәрбайҗан географик атамалары исемлегендә антропонимнарга һәм топонимнарга нигезләнгән атамаларның күпчелекне тәшкил итүләре турында яза [Гусейнзаде, 1971, с. 123]. Кандидатлык диссертациясендә башкорт топонимисты Р.З. Шәкүров, Башкортстан топонимиясендә һәм микротопонимиясендә антропонимнар зур урын алалар, ә гидронимиядә алар чагыштырмача азрак, дигән нәтиҗәгә килә [Шакуров, 1973, с. 130]. Күренекле географ һәм топонимист профессор Э.М. Мурзаев, антропонимика белән топонимика арасында тыгыз тарихи бәйләнеш, үзара керешү булуын билгеләп, бик хаклы рәвештә: «Торак пунктларның атамаларында күбесенчә кеше исемнәре, фамилияләр, кушаматлар урын ала», – дип яза [Мурзаев, 1968, с. 85]. Докторлык диссертациясен Төньяк Осетия топонимиясенең апеллятив сүзләрдән

ясалган топонимнарын шактый җентекле итеп тикшергән А.Дз. Цогаева «Число географических названий, восходящих к собственным именам, довольно значительно, и они могут стать предметом самостоятельного исследования», – дип язуы белән, һичшиксез, хаклы [Цогаева, 1971, с. 340].

«Татарстан Республикасының административ-территориаль бүленеше» (Казан, 1992) белешмә мәгълүматларына таянып исәпләгәндә, республикабызда барлыгы 3942 торак пункт бар. Шуларның 1968 енең атамасы антропонимнарга нигезләнеп ясалган, ягъни Татарстандагы торак пункт атамаларының 50% ын антропоойконим тәшкил итә. Антропоойконимнарның Әстерхан өлкәсендә барлык торак пункт исемнәренең 20% чамасын гына алып торуын исәпкә алганда [Тюменцева, 1970, с. 309], Татарстанда антропонимнарга нигезләнгән ойконимнарның саны һәм проценты шактый югары булуы ачыклана [Саттаров, 1998, б. 8].

А.И. Попов та торак пункт атамаларында антропонимнарның күпчелекне тәшкил итүе турында яза. Бу урынга беренче булып килгән кешеләрнең исемнәренең авыл исемнәрендә аерым, әһәмиятле урын тотуларын күрсәтә [Попов, 1981, с. 116]. Шул ук вакытта торак пункт яки географик атамаларның, киресенчә, кеше исеменә әйләнү процессы да актив булган [Никонов, 1979, с. 92], ягъни бу бәйләнеш (антропонимнар һәм топонимнар арасындагы) ике яклы. Мәсәлән, башкортлар арасында бүгенге көндә дә Дим, Итил исемнәрен йөртүче кешеләр бар. Урта гасыр галимнәре, шагыйрьләре, Болгари, Хәрәзми, Сараи, Бируни кебек, үзләренә туган җирләрен аңлаткан атамаларны исем итеп алганнар.

Г.Ф. Саттаров тикшерүләре күрсәткәнчә, антропотопонимнар арасында зур күпчелекне ир-ат исемнәре ала, хатын-кыз исемнәре бары 1% кына тәшкил итә. Моның сәбәбе – феодаль җәмгыятьтә ир-атны өстен дип күрсәтү [Мурзаев, 1996, с. 193].

В.А. Нестеров күрсәтүенчә, Чувашстан топонимнары арасында антропотопонимнар бик аз. Алар шулай ук гидронимиядә дә очрамый. Бик аз санда гына ойконимнарда очрыйлар

[Нестеров, 1980, с. 102–111]. Көнбатыш Кама аръягында исә чуваш теленә нисбәтле ойконимнарның күбесен кеше исеменә нисбәтле атамалар алып тора.

Э.М. Мурзаев төрки антропонимиядә өч катлам күрә: 1) төрки; 2) гарәп-фарсы (мөселман); 3) катнаш (төрки, гарәп-фарсы һәм рус) [Мурзаев, 1996, с. 195].

Көнбатыш Кама аръягындагы антропоойконимнарны без дүрткә бүлеп карыйбыз:

1) кеше исемнәреннән, фамилияләрдән, кушаматлардан ясалган атамалар;

2) сословие титулларына нисбәтле ойконимнар;

3) дини титулларга нисбәтле ойконимнар;

4) профессия аңлаткан сүзләргә нисбәтле атамалар.

**Кеше исемнәреннән, фамилияләреннән, кушаматлардан ясалган ойконимнар**

Бу төр антропотонимнарның үзләрен өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

а) мәҗүси (төрки-болгар-чуваш-татар) исемнәр;

ә) ислам дине белән кергән (гарәп-фарсы) исемнәр;

б) рус һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән исемнәр (күпмедер күләмдә христиан дине белән бәйле).

***а) мәҗүси исемнәр.***

Татар антропонимиясендә *ак* сүзе кушылып ясалган кушма төзелешле борынгы кеше исемнәре бик күп. Мәсәлән, Акбатыр, Акъегет, Акбуга һ.б.

Аксубай, Аппак, Акбулат исемнәре Көнбатыш Кама аръягында ойконимнарга әйләнгәннәр.

Аксубай исеме *ак + субай* сүзләреннән тора. Борынгы төрки телгә фарсы теленнән килеп кергән *сыбай* сүзе атлы сугышчы төшенчәсен белдергән. Татар теле сөйләшләрендә шул мәгънәсендә әле дә сакланган. Мәсәлән, гәйнә, эчкен һәм красноуфим татарлары телендә *сыбай* җайдак мәгънәсендә йөри («Бригадир сыбай йөри»). Аксубай исемендә, икенче компонент булып шушы сүз чагылыш таба.

Әлки районында Татар Аппагы авылы янынннан Аппак суы да ага. Ул Иске Чирмешәннең уң кушылдыгы [Гарипова, 1990, б. 196]. Елгага атама авыл исеменнән кушылган булса кирәк.

Иске Алпар, Яңа Алпар авыллары атамалары Алпар дигән борынгы төрки кеше исеменә нигезләнеп ясалганнар. «Борынгы төрки сүзлек»тә *alp* сүзенең 1) меткий стрелок; 2) герой, богатырь, витязь; 3) отважный, храбрый, смелый; 4) отвага, храбрость, мужество мәгънәләрен белдерүе күрсәтелгән [ДТС, 1969, с. 36]. Шушы сүзгә нигезләнеп байтак кына борынгы кеше исемнәре барлыкка килгән.

С.Е. Малов *alp* (герой) сүзенә Күл-Тәгин ядкарендәге Alp ar исемен мисал итеп китерә [Малов, 1951, с. 357]. Борынгы төрки телдә *ar* (er – ир) сүзенең «муж», «мужчина» мәгънәсен белдерүен исәпкә алсак, Алпар исеме «батыр ир» мәгънәсен бирә булып чыга. Бу исемнең башка төрле юл белән дә ясалган булуы ихтимал. Ләкин югарыда китерелгән юл безгә чынбарлыкка туры килә кебек тоела.

Азеево авылының атамасы татар диалектларындагы һәм чуваш телендәге Әзи, Әзей исеменә нисбәтле [Магницкий, 1905, с. 25]. Татар-чуваш телләрендә Ака, Акай исемнәре дә кулланылышта йөргән [Магницкий, 1905, с. 25].

Чуваш телендәге Алка [Магницкий, 1905, с. 27] исеменнән рус һәм татар телләрендә Алкин фамилиясе ясалган. Яңа Чишмә районындагы Татар Алкины авылы атамасы шушы фамилиягә нисбәтле. Һ.В. Йосыпов Алканы болгар исеме дип күрсәтә [1992, б. 44]. Алка исеме Алкай исеменең фонетик варианты булырга да мөмкин. Г.Ф. Саттаров Алкай исеме беренче булып туган балага кушылган дип күрсәтә. *Ал* сүзенә *-кай* иркәләү кушымчасы кушып «беренче бала» мәгънәле исем ясалган ди [Саттаров, 1981, б. 32]. Без дә шушы фикергә кушылабыз. Р.И. Куряева Алкай исеме Гали исеменең диалекталь варианты дип күрсәтә.

Алексеев районында Багалинский урманчылыгы бар. Багалинский атамасы мәҗүси чуваш Багай исеменә нисбәтле булырга мөмкин.

Базякова авылы атамасы да чуваш телендәге Базяк исеменә нисбәтле [Магницкий, 1905, с. 38].

Балахчино авылы атамасының нигезендә Балахчин фамилиясе ята. Бу фамилия борынгы төрки телдәге балукчы/балыгчы – «рыбак» [ДТС, 1969, с. 80] сүзенә нисбәтле.

Түбән, Урта Биктимер авылларының атамасы составындагы *Биктимер* сүзе *бик* һәм *тимер* сүзләреннән тора. *Бик* («нык, таза») сүзе *тимер* белән кушылып, *Биктимер* («нык, таза, тимер» яки «тимердәй нык, таза» мәгънәсен бирә) антропонимы ясалган. Элекке заманнарда кешеләр, балаларының таза, нык, сәламәт булуларын теләп, шундый исемнәр кушканнардыр, мөгаен.

Байтирәк авылы атамасы турында без югарыда язган идек инде. Төркиләрдә *тирәк* – яхшы, изге, ныклы агач, *бай* компоненты изге саналган агачларга кушылган: *Байкайын,* мәсәлән, Г.Ф. Саттаров, өйдә калырга тиеш булган төпчек балага шушы исем кушылган, дип саный [Саттаров, 1981, б. 421].

В.К. Магницкийның «Чувашские языческие имена» (Казан, 1905) китабында Айтерекъ, Кулдерекъ кебек составларында *терекъ* (тирәк) сүзе булган кеше исемнәре бирелгән.

Чуваш Борнае һәм Татар Борнае авылларының *Борнай* топокомпоненты *Борнай* дигән кеше яки нәсел кушаматына нибәтле рәвештә барлыкка килгән. Татар теленең Казан арты сөйләшләре группасына карый торган Балтач урынчылыгында *борнай* сүзе «сөйләшмәүчән, караңгы чырайлы, төксе, төмсә» (мрачный, нахмуренный) [Татар теленең диалектологик сүзлеге, 1969, б. 92] мәгънәсендә хәзер дә кулланылышта йөри. Сөйләшмәүчән, караңгы чырайлы кешегә Борнай кушаматы тагылган һәм ул хәзерге Әлки районы җирлегендә бик күптәннән татар һәм чуваш авыллары атамасы функциясен үтәүгә күчкән.

Чистай районындагы Борнаш авылы атамасы да төрки кеше исеменә нисбәтле. М. Фасмер Борнаш исемле Казан кенәзе турында хәбәр итә. Күп кенә галимнәр *борнаш* сүзен борынгы төрки «борын, бурун» белән бәйләп карыйлар [Куряева, 1992, с. 67–68]. *Борын* сүзенә *-аш* кушымчасы өстәгәч, *борнаш*

«носатый» мәгънәсе чыга. Ләкин *борын* сүзенең «алдан, прежде, сначала» дигән мәгънәсе дә бар. Ул чагында *борнаш* сүзе алдан туган, беренче балага кушылган булырга мөмкин. Борнай атамасының да шушы мәгънәсе булырга мөмкин.

Бахта авылының атамасы мәҗүси чуваш Бахти яки татар телендәге Бәхти (Бәхтияр) исеменә нисбәтле [Магницкий, 1905, с. 35]. Борынгы төрки телдә *бахт* – «счастье» [ДТС, 1969, с. 89] мәгънәсен бирә: татар телендә «бәхет».

Гайтанкино һәм Новое Гайтанкино (Гайтан) авылларының атамасы Гайтанкин фамилиясенә нисбәтле. Фамилия Гайтанка кушаматыннан, ә кушамат рус телендәге *гайтан* – «шнурок для ношения креста на груди, веревка для связывания тяжестей» сүзеннән ясалган [Полный иллюстрированный словарь иностранных слов, 1936, с. 96]. Татар телендә *гайтан* рус телендәге «шнурок» дигәнне аңлата.

Танылган рус фамилиясе Гогольдән Көнбатыш Кама аръягында Гоголиха исемле авыл атамасы ясалган. Бу атама төрки телдәге *гогул* – «селезень» сүзенә нисбәтле булырга мөмкин: кыргызча – *когол* «селезень»; якутча – *когулок* «хохлатая утка, нырок, малая гагара; шор. – *когулас* «соловей»; бараба – *кугулуий* «кулик»; тобол татарларында – *куголчин* «дикий голубь». Барлык күрсәтелгән мәгънәләрдә төрки телдәге *кок, гөк* «синий, синеватый; зеленый, зеленоватый; серый, сероватый; голубой, голубоватый» [Баскаков, 1979, с. 76] тамырына барып тоташа.

Рус телендәге Енарус кеше исеме чуваш телендәге Енарас исеменә якын тора, бу исем үз чиратында татар диалекталь Януразисеменә мөнәсәбәтле. Әдәби формасы – Йонураз. Исем *яңа* «новый» һәм *ураз* «бәхет» сүзләреннән тора.

Барское Енарускино, Удельное Енарускино – Аксубай районындагы авыллар.

«Чувашча-русча сүзлек»тә тарихи исем буларак Богдыхан исеме китерелгән [1961, с. 55]. Богдашкино авылының атамасы шушы исемгә нисбәтле булырга мөмкин.

Колчура *кол* һәм *чура* компонентларыннан тора. *Кол* сүзе «раб, человек» мәгънәсен аңлата. Борынгы татар телендә актив

кулланышта йөргән *чура:* 1) кол; 2) игенче, сабанчы, крестьян; 3) чури, сугышчы, хәрби – сүзенә антропонимик кечерәйтү кушымчалары ялганган. Мәсәлән,

Чура
- -ай – Чурай
- -аш – Чураш
- -ак – Урак
- -кай – Чуракай [Саттаров, 1970, б. 213].

*Чура* антрополексемасының башка сүзләр белән кушылуы нәтиҗәсендә байтак кына кеше исемнәре (мәсәлән, Акчура, Колчура (*кол* + *чура*), Чурабай һ. б.) барлыкка килгән.

Күлбай-Мораса авылы атамасы составындагы *Күлбай* компоненты Кулибай ~ Колбай дигән кеше исеменә нисбәтле. Атама *кол* – «раб божий, человек» һәм *бай* – «богатый» сүзеннән тора. *Күлибәк* исә *Күлбай*ның рус теле аша кире әйләнеп кайткан варианты булырга мөмкин.

Кураново атамасы рус һәм татар телләрендә очрый торган Куранов фамилиясеннән ясалган. Татар телендә Куран дигән кеше исеме дә булган. Алтай телләрендә *куран* сүзе «кыргый кәҗә» мәгънәсендә йөри: Кучкар, Курый. Чагатай телендә *куран* – «корал, оружие». Р.И. Куряева, атама борынгы төрки телдәге *кур* – «приводить в боевую готовность» фигыленә нисбәтле, дип күрсәтә [Куряева, 1992, с. 98]. Рус телендәге *курок* сүзе дә шушы тамырга нисбәтле булырга тиеш.

Кармыш авылы атамасы Карамыш дигән кеше исеменә нисбәтле. Карамаш исеменең әүвәлге төзелеше *Карамыш бала* яки *Карамыш оглан* сүзтезмәсеннән гыйбарәт булган. Мондый сүзтезмәдә *-мыш* формасы фигыль үзе кергән исемнән алда килә, аергыч функциясен башкарып, предметның билгесен белдерә. Шушы грамматик билгеләре аның үткән заман сыйфат фигыль икәнлеген ачык күрсәтә.

Кошаново ойконимы Кошанов фамилиясеннән ясалган. Төрки телләрдә *кош, куш* сүзенең «присоединяться; пара, двойной» кебек мәгънәләре бар. Без инде югарыда «Иш янына куш»

дигән мәкальне китергән идек. Бу исем дә игезәк сыңарына бирелгән булырга мөмкин.

Базарлы Матак авылының исемендәге *Матак* сүзе – борынгы чуваш антропонимы [Саттаров, 1973, б. 126]. Н.И. Ашмарин чувашларда Матакның ирләр исеме һәм нәсел кушаматы булып йөрүен хәбәр итә [Ашмарин, вып. VIII, с. 322]. Чуваш телендә *матак* «кечкенә, бәләкәй»не аңлата. Ә «Базарлы» эпитеты бу авылны башка Матак авылларыннан аеру, конкретлаштыру хезмәтен үти.

Физик яки рухи яктан бик йомшак булган кешегә Мамык кушаматы тагылган [Саттаров, 1973, б. 157]. Мамык кушаматын йөрткән аерым шәхес яки нәсел-токым эшчәнлеге аша бу кушамат Мамык авылы атамасына әверелгән.

Норлат атамасы Нурдәүләт исемле кеше исеменә нисбәтле. XVI гасырда авыл Нурдәүләт атамасын йөрткән [Саттаров, 1974, б. 41–49]. Исем *нур* һәм *дәүләт* сүзләреннән тора. *Нур* борынгы төрки телдә «свет, сияние» [ДТС, 1969, с. 361] мәгънәсендә йөргән: татар телендә *нур* – «сияние, луч, блеск» [Татарча-русча сүзлек, 1966, б. 402]. *Дәүләт* сүзе борынгы төрки телдә «счастье, удача, благополучие» мәгънәсенә ия. Татар телендә *дәүләт* – «богатство, государство». *Дәүләт* сүзе үзе генә дә кеше исеме булып йөргән. Бүгенге көндә татарларда Дәүләтов, Дәүләтбаев кебек фамилияләр еш очрый.

Сөнчәле авылларының атамасы диалекталь Сөнчәли исеменә нисбәтле. Сөнчәләй исеме Сөенечгали исеменең кыскартылма варианты. Исем татар телендәге *сөенеч* – «радость, радостно, известия» сүзенә нисбәтле, бу сүз, үз чиратында, борынгы төрки телдәге *севин* – «радоваться» [ДТС, 1969, с. 497] сүзенә мөнәсәбәтле. Татар диалектларында Сөнчәләй варианты да бар.

В.К. Магницкий хезмәтендә [Магницкий, 1905, с. 71] урын алган мәҗүси Сауыш һәм Саурыш (икесе дә «савыгырга булыш, ярдәм ит» мәгънәсен белдерәләр. Күрәсең, ябык, бик зәгыйфь булып туган ир баланы савыктырырга, терелтергә теләп илаһи көчкә табыну, мөрәҗәгать итү аркасында әлеге бала исемнәре

барлыкка килгән) исемнәре Саба һәм Теләче районнарындагы Сауыш, Олы Саурыш, Түбән Саурыш дигән татар авыллары атамаларының барлыкка килүе риваятьләрдә «сау арыш» сүзләреннән дип аңлатыла, борынгы төрки Сауыш һәм Саурыш исемнәре белән мөнәсәбәтле булуын ачыкларга ярдәм итә [Саттаров, 1973, 38 б.].

Мәҗүси чуваш Сабакай [Магницкий, 1905, с. 70] исеменнән Алексеев районында Сабакайка авылы атамасы ясалган. Революциягә кадәр Лаеш өязендә Сабакайкино дигән чуваш авылы булганлыгы мәгълүм.

Салдакай атамасы мәҗүси чуваш Салтак [Магницкий, 1905, с. 72] исеменә нисбәтле. Чуваш телендә *салтак* сүзе «солдат» мәгънәсендә йөри. Чагатай телендә *салак* «гаскәр»не аңлата. «Солдат» мәгънәсендә *салтак* сүзе мари теленә дә кергән.

Төгәлбай авылларының атамасы борынгы төрки Төгәлбай исеменнән алынган. «Борынга төрки сүзлектә» [ДТС, 1969, с. 595] *tuko* / I сүзенең «тулы, камил» мәгънәсен белдерүе, ә *tuka* / II нең кеше исеме булып йөрүе күрсәтелгән һәм *Tukolqara* (кеше исеме) мисалы китерелгән. Төгәлбай исеме *төгәл* (тулы, камил, бар әгъзасы да исән-имин), *бай* (сословие титулы) сүзләре кушылу юлы белән ясалган. Төгәлбайның синонимы булган Тулыбай исеме безнең республикада Тулбай (Минзәлә һәм Мамадыш районнарында) авыллар атамасына әверелгән. Борынгы төрки телләрдә Төгәлбота (*төгәл* + *бота*, дөя баласы) һ.б. шундый исемнәр булган.

Әлки районында Рус Салманы, Анин Салман дигән рус, Иске Салман, Яңа Салман, Түбән Салман, Абдул Салманы исемле татар авыллары бар. Структур яктан ике сүздән торган сүзтезмә тәшкил итүче бу атамалар составындагы *салман* компонентының килеп чыгышын өч төрле карый алабыз. Без аларны югарыда күрсәткән идек инде.

Әлки районындагы Ташбилге дигән чуваш-татар авылы атамасының килеп чыгышы Ташбилге елгачыгы исеменә нисбәтле. Бу елгачыкның үз атамасының килеп чыгышы исә, Ташбилге дигән борынгы төрки кеше исеменә мөнәсәбәтле

булырга тиеш. Ташбилге исеме *таш* + *билге* компонентларыннан торган кушма төзелеш тәшкил итә.

Кеше исемнәре составында *таш* сүзе бала таш кебек нык, таза, каты булсын, усал көчләргә һәм авыруларга бирешмәсен дигән теләк-йола белән бәйләнешле рәвештә урын алган. Мондый исемнәргә Таш, Ташбай, Ташбулат һәм башкаларны мисал итеп китерергә мөмкин. Электә төрки халыкларда үзе туганчы яки тугач та озак тормастан әтисе үлгән ир балага, әтисенең төсе, аннан калган билге дип санап, *билге* сүзе кергән исем кушу гадәте булган. Мәсәлән, Билге каган.

*Билге* антропокомпонентына фонетик составы һәм яңгырашы ягыннан борынгы төрки телдә кулланылышта йөргән *bilga* – 1) мудрый, 2) мудрец [ДТС, 1969, с. 99] сүзе бик якын тора.

Ташбилге исеменең икенче өлешен тәшкил иткән *билге* антропокомпонентының «тамга, төс» мәгънәсен белдерә торган сүз булмыйча, *билгә* (bilga) – 1) «биекле», 2) «хәким» [шунда ук, б. 99] мәгънәләрен белдергән, сүзнең беркадәр фонетик үзгәреш кичергән варианты (*билгә* > *билге*) булуы да мөмкин. Ул вакытта Ташбилге атамасы «Ташбиекле» яки «Ташхәким» мәгънәсен аңлата булып чыга.

Татар халкының бөек шагыйре Г. Тукай исемен мәңгеләштерү максатыннан Татарстандагы күп авылларга Тукай исеме бирелгән. Г.Ф. Саттаров бу исемнең берничә мәгънәсен күрсәтә [Саттаров, 1981, б. 181–182]:

1. *Тук* сүзенә *-ай* атау-эндәшү-боеру кушымчасы ялганып ясалган. «Ризыклы-нигъмәтле бул» мәгънәсен бирә.

2. Й. Гәрәй Тукай исеменең мәгънәсен *ту, туу* тамырына нисбәтле итеп, туганкай дип аңлата.

3. Тукай исеме борынгы төрки телдәге *тогай, тугай* – «елганың борылмасы, түгәрәк үзәне, тугайлы урыны» сүзеннән ясалган булырга да мөмкин. А. Гафуров, төрки телдәге Тукай исеме «урман куаклыгы, әрәмәлек» мәгънәсен, ә аның фонетик вариантыннан гыйбарәт Токай, Тукай исеме «урманлы җир» мәгънәсен белдерә, дип саный.

4. Монголча Тукай – «җәя», «салават күпере».

5. Себер татарлары Туктаким, Туктаргали исемнәрен кыскартып, җанлы сөйләм телендә Тукай рәвешен кулланалар. Риваятьләргә караганда Г. Тукайның ерак бабаларыннан берсе Туктаргали исемле булып, аны кыскартып, Тукай дип йөрткәннәр [Нуруллин, 1977].

Көнбатыш Кама аръягында Тукай исемле авыллар Аксубай, Норлат, Спас районнарында бар.

Уткино, Утяково авылларының атамалары татар телендәге Өтәк, чуваш телендәге Отяк [Магницкий, 1905, с. 63] исемнәренә нисбәтле. Г.Ф. Саттаров исемне борынгы төрки телдәге *өтәк* – «долг» [ДТС, 1969, с. 392] сүзенә мөнәсәбәтли. Мондый исем тәңредән озак итеп сораганнан соң туган малайга бирелгән [Саттаров, 1981, б. 246]. *Өтәк* сүзе *үтә* фигыленнән («исполнять, выполнять») ясалган, төрек телендә бу сүзнең «вознаграждать» мәгънәсе бар [Севортян, 1974, с. 169].

Утяшкино авылы атамасы татар-чуваш Өтәш [Магницкий, 1905, с. 89] исеменә нисбәтле. Өтәш исеме дә, Өтәк исеме кебек, *үтә* фигыленә барып тоташа.

Үтәмеш атамасы *үтәгән* сүзен аңлата. Бу исем дә шулай ук *үтә* фигыленә нисбәтле.

Шома дигән татар-рус авылы исемен мукшы телендәге *шома* – «бит» сүзенә нисбәтле булган Шома кушаматыннан алынган дип тә әйтә алабыз [Саттаров, 1973, б. 179]. Гадәтидән зур яки кечкенә битле кешегә мукшы телендә Шома – «бит» дигән шәхси кушамат тагыла алган.

Шапкино авылы атамасы Шапки дигән мәҗүси чуваш исеменә нисбәтле [Магницкий, 1905, с. 94].

Мишәр диалектындагы Янбакты исеме *ян* (әдәби телдә *җан*) – «душа» һәм борынгы төрки *бак* – «внимательно смотреть, обозревать, разгадывать» [ДТС, 1964, с. 8] сүзләреннән ясалган: мишәрчә *бак* – «смотреть, показываться» [Радлов, 1882, 4, с. 1435]. *Ян* сүзе, үткән заман фигыле *бакты* белән кушылып, «җан күренде, туды» мәгънәсен барлыкка китерә: Айбакты, Байбакты һ.б.

Чыгтай антропотопонимы монгол телендәге Чагатай исеменә нисбәтле [Саттаров, 1989, б. 114–116].

Ямкино антропотонимы *җан* сүзенең көнбатыш диалекттагы *ян* диалектик вариатыннан ясалган булырга мөмкин.

Талкыш – шәхес яки нәсел-ыру кушаматына нисбәтле рәвештә барлыкка килгән атама. Талкыш кушаматы аерым бер шәхескә бик вакчыл булганлыгы өчен кушылган. Кешенең вакчыллыгын метофорик рәвештә талкыш белән тиңләштерү, талкышка аналогия ясау нәтиҗәсендә Талкыш кушаматы барлыкка килгән. Шушы кушаматны йөрткән кеше яисә гаилә башлап килеп утырганга, әлеге авылларның берсенә Талкыш атамасы бирелгән, ягъни Талкыш кушаматына нигезләнгән антропотопоним ясалган.

*Талкыш* сүзе мәҗүси исем булып та йөргән. Болгар эпитафиясендә Талкыш, ә мәҗүси чуваш исемнәре арасында Талкаш бар [Магницкий, 1905, с. 84]. Талкыш исеменә нисбәтле рәвештә дә Талкыш антропотопонимнары барлыкка килә ала. Талкыш атамасын «талга кош кунганга, тал+кош» сүзләреннән барлыкка килгән, дип риваять итү чынбарлыкка туры килми [Саттаров, 1973, б. 155–156].

Әлки авылларының атамасы Әлкәй дигән борынгы кеше исеменә нисбәтле [Саттаров, 1984]. Бу исем *әл + кәй* компонентларыннан тора. Ихтимал, бу Галикәй, Галекәй исеменнәндер. Ә бәлки *әл, эл* сүзеннәндер: элек *әл* сүзе «кул» төшенчәсен белдергән һәм шушы мәгънәдә азәрбайҗан, төрек һәм башка телләрдә хәзер дә кулланыла. *-кәй* кушымчасы борынгы кеше исемнәрен ясауда актив катнашкан. Гәүдә-баш әгъзасы атамасына нигезләнеп ясалган кеше исемнәре борынгы телебездә байтак очрый: Акбит, Йөзлекәй, Акчәч һ.б. Әлкәй исеме дә шулар белән бер үк антропонимик рәт – семантик кыр барлыкка китерә. Составларында *әл* («кул») сүзе булган Тугрел, Турел (*тугры + әл,* ягъни «туры кул»), Әлемгол һ.б. исемнәр кулланылышта йөргән.

Мәҗүси кеше исемнәренә нигезләнгән атамаларга без тагын Котловка, Котыш, Кондрат, Савгач, Селенгуш, Әзи, Хузангай, Чурабатыр, Чертуш ойконимнарын кертеп карыйбыз.

***ә) ислам дине белән кергән атамалар.***

Гарәп теленнән кергән Әдәм исеме белән Көнбатыш Кама аръягында Әдәмсуы исемле берничә авыл атамасы ясалган. Әдәмсу исемле елга да бар [Гарипова, 1990, б. 263]. Гарәп телендә *әдәм* – «человек, люди» мәгънәсен бирә һәм кеше исеме булып та йөри [ДТС, 1969, с. 8].

Әхмәт исеме белән Ахматка, Ахметова, Татар Әхмәте кебек атамалар ясалган. Гарәп телендә Әхмәт «иң данлыклы, иң мактаулы» дигәнне аңлата [Саттаров, 1981, б. 239].

Абдул Салманы атамасындагы Абдул элементы гарәп теленнән кергән Габдулла исеменең диалекталь варианты. Бу исемнең татар телендә тагын Абдуллай, Аблай, Гаптул, Абаш, Абуш, Апуш, Абиш, Габдул һ.б. шундый вариантлары бар. Габдулла «Алла колы» дигәнне аңлата [Саттаров, 1981, б. 61].

Гадельша исеме «гадел» һәм «шаһ» сүзләреннән ясалган. Мөхәммәт пәйгамбәрнең әтисенең исеме. Гарәп телендә *гадел* сүзе «1. Турылык, гаделлек. 2. Турылык, дөреслек» мәгънәләрен аңлата [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, т. I, б. 64]. *Шаһ* сүзе фарсы теленнән кергән. Ул «1) шаһ, патша (Иран патшасы), 2) сүзләргә алдан кушылып, «иң шәп, иң беренче, иң зур» [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, т. II, б. 700) дигән мәгънәләр бирә. *Гадельшаһ* исеме «справедливый правитель» дигәнне аңлата булып чыга. Бу исем безнең регионда ойконимга да әйләнгән. *Шаһ* сүзе белән тагын Мәүләшә (шаһ), Шахмай кебек атамалар ясалган.

Күп кенә гарәп-фарсы исемнәре үзләренең беренчел фонетик кыяфәтләрен югалтып, диалекталь вариация алганнар. Ибрай, Ислай, Иглай атамалары шундыйлардан.

Ибрай – Ибраһим исеменең кыскартылма варианты. Ибраһим исеме гарәп теленең үзенә дә яһүд теленнән кергән. Яһүд телендә аның яңгырашы – Авраам. Абрам, Абраил кебек башка вариантлары да бар. Билгеле булганча, яһүд пәйгамбәре Авраам исемен йөрткән. Исем «халыклар атасы» дигәнне аңлата [Саттаров, 1981, б. 87].

Ислай – Исламның диалекталь варианты. Ислам – динебезнең атамасы. Кеше исеме функцияләрен дә үти.

Иглай – Игълямның варианты. Гарәп телендә ул «1) белдерү, аңлату, 2) кеше исеме – динне аңлатучы» мәгънәләрендә кулланыла [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, т. I, б. 147].

Кади – гарәп сүзе, «казый, судья» мәгънәсен бирә [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, т. I, б. 199]. Мөселманнар балаларына, укымышлы, гадел, акны карадан аера белә торган булсыннар дип, шушы исемне кушканнар.

Кайбер атамаларны без кеше исемнәренә дә, сословие титулларына да кертеп карыйбыз. Алар башта, әлбәттә, сословие титулы булып йөргәннәр. Соңрак кеше исеменә дә әйләнгәннәр. Әлморза, Әмир, Шаһмай әнә шундыйлар.

Әлморза исеме «бөек, данлыклы, билгеле морза» дигәнне аңлата; Әлмөхәммәт – «билгеле Мөхәммәт».

Әлки районында М. Вахитов исемендәге авыл барлыгын хәбәр иткән идек инде. Вахитов фамилиясе Вахит исеменнән ясалган. Гарәп телендә *Вахит/Вахидә* (хатын-кыз варианты) – «бердәнбер, беренче бала» дигәнне аңлата [Саттаров, 1981, б. 55].

Мөслим авылы атамасы Мөслим дигән кеше исеменнән алынган. Гарәп телендә *мөслим* «ислам динендә булган кеше, мөселман» мәгънәсен аңлата [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, т. I, б. 384].

Әлки районындагы Мәүләшә авылы атамасының килеп чыгышы Мәүләшаһ дигән кеше исеменә нисбәтле.

Гарәп теленнән кергән *мәүлә* сүзе берничә мәгънә белдерә: 1) ия, хуҗа, яхшылык итүче; 2) дус; 3) колын азат итүче; 4) Алланың эпитеты.

*Мәүлә* сүзенә антропонимик кушылмалар ялгану яки башка сүзләр кушылу юлы белән татар телендә байтак кына кеше исемнәре ясаганнар: Мәүләбай, Мәүләшаһ, Мәүләви һ.б.

Ислам динендә Алланы мактау сүзләре туксан тугыз. Шуларның байтагы ислам динен кабул иткән төрки халыкларда, шул исәптән татарларда да, кеше исеме булып йөриләр: Бакый, Каюм, Рахман һ.б. Мәүләшә исеме дә шундыйлардан.

Нариман исеме борынгы иран теленә нисбәтле. Ул «көчле рухлы, кыю, батыр (сугышчы)» дигәнне аңлата. Аның Нарым,

Нарик, Нарый, Нарыш, Нардин кебек диалекталь формалары бар [Саттаров, 1981, б. 145]. Исем ойконимга да әверелгән.

Ромодан дигән рус авылының атамасы Рамазан дигән кеше исеменә нисбәтле. Рамазан – мөселман календаре буенча тугызынчы ай исеме [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, т. II, б. 477]. Мөселманнарда ай исемнәрен балага кушу гадәте булган. Шундый атамалардан тагын берсе – Рәҗәп. Рәҗәп – мөселман ай календаре буенча җиденче ай. Ислам динен тотучы халыклар, шул исәптән татарлар да, Рәҗәп аенда туган балага Рәҗәп исеме куша торган булганнар. Соңрак, ул кеше исеме булып киткәч, башка айларда туган балаларга да Рәҗәп исеме кую гадәткә кереп киткән.

Садиково авылы атамасы Садыйк исеменә нисбәтле. Гарәп телендә *садыйк* «туры, дөрес, чын, эчкерсез» дигәнне аңлата. Кара: «Вә һәр әбхаре садыйк, гайре кедиб» (Г. Тукай) [Гарәпчә-татарча-русча..., 1993, т. II, б. 459].

Мулланур Вахитовның исеме гарәп телендәге *мулла* сүзенә нисбәтле.

*Мулла* сүзе рухани төшенчәсен генә белдермәгән, «укымышлы, белемле кеше, гыйлем иясе; укый-яза белүче, укытучы, остаз» мәгънәсендә дә кулланылган һәм борынгы кеше исемнәре составында шактый еш урын алган. Мәсәлән, Муллабай, Муллагали, Мулланур, Муллахәсән, Муллахан, Бикмулла, Ишмулла, Шаһимулла һ.б. [Саттаров, 1984, б. 159].

Якушкино авылы атамасы гарәп, борынгы яһүд телләреннән кергән. *Якуп* «ияреп баручы» дигәнне аңлата. Пәйгамбәр исеме [Саттаров, 1981, б. 228]. Хәтерләсәгез, Йосыфның атасы Якуп пәйгамбәр.

Әлмәт атамасы турында без югарыда язган идек инде. Атама Әлмөхәммәт исеменә нисбәтле. Мөхәммәт – пәйгамбәребезнең исеме. Әлмөхәммәт танылган, билгеле Мөхәммәт дигәнне аңлата.

***б) рус теле һәм рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән кергән исемнәрдән ясалган атамалар.*** Бу исемнәрнең нәрсә аңлатканнарын язып тормыйбыз, ләкин факт буларак

аларны күрсәтеп китәбез: Алексеевка (Алексеевское), Александровка, Андреевка, Аверьяновка, Антоновка, Афонькино, Беловка, Борискино, Берлек-Михайловка, Васильевка, Владимировка, Гурьевка, Горшково, Демидовка, Домауровка, Емелькино, Ерепкино, Екатерининская Слобода (Екатериновка), Егоркино, Ивановка (Иванаево), Иж-Борискино, Катюшин, Калиновка, Ленино, Масловка, Михайловка, Носовка, Некрасовка, Николаевка (2), Никольское, Осиповка, Покровка, Паномаревка, Пановка, Петропавловское, Петровский, Порфировка Сергеевский, Сахаровка, Стар. Сережкино, Тимошкино, Ульяновка, Федоровка (Федоровский), Фомкино, Фадеевка, Языково.

**Сыйнфый катлам титулларына нисбәтле ойконимнар**

Татар ономастикасында җәмгыятьнең сыйнфый катламы титулларына нисбәтле рәвештә байтак кына ономастик атау берәмлекләре барлыкка килгәннәр, шул исәптән ойконимнар да.

*Бай* (хуҗа, мал-мөлкәтле кеше) сословие титулы белән: Бибай, Байтирәк, Күлбай-Мораса авыллары исемнәре ясалган.

Н.А. Баскаков хәбәр итүенә караганда, географик атамалар составында *бай* сүзе «запретный, священный» мәгънәсендә кулланылырга мөмкин: алтай – *бай соз* «запретное слова»; *бай куш* «святая птица» [Мурзаев, 1996, с. 77].

*Бояр* сословие титулы белән Барское Енорускино ойконимы ясалган. *Бояр* сүзе рус теленә төрки телләрдән кергән. *Баяр = байар, бай* «богатый» + төрки *ар* «мужчина» мәгънәләрен аңлата.

*Би, бәк, бик, биге* титуллары белән дә ойконимнар ясалган.

*Бик* («таза, нык, үтә») дәрәҗә рәвешен аңа омонимдаш булган *бик* (*бәк, бек, би* – кенәз; борынгы төрки телдә *Beg* – хаким, җитәкче, князь, әфәнде) [ДТС, 1969, с. 92] титулы белән бутамаска кирәк [Саттаров, 1973, б. 141].

*Бикүле* сүзе «би» һәм «күле» элементларыннан тора. Бикүле сүзенең мәгънәсе «бинең күле, кенәз күле» булып килеп чыга. Бу авыл кайчандыр ниндидер бәкнең шәхси милке булып саналган күл янына утырганга шулай аталгандыр мөгаен.

Биләр – Идел-Кама болгарларының башкаласы атамасы. *Би + ләр* конструкциясе: Байлар Сабасы.

Шушы ук районда урнашкан Биккол авылы атамасының мәгънәсе «бинең, бәкнең колы» булуы ихтимал.

Әмир – Чирмешән районындагы татар авылы. *Әмир* сүзе гарәпчә «хәрби начальник, идарә итүче» мәгънәләрен аңлатучы титул исеме.

Тарханка – Аксубай районындагы чуваш авылы. Бу авылның исеме борынгы төрки *тархан* (титул исеме) сүзенә нисбәтле. Тархан – ханга буйсынучы, ләкин аңа ясак түләми торган вассал [Саттаров, 1998, б. 316]. Монгол телендә *дархан* – «кузнец, мастер, вольный человек» [Мурзаев, 1996, с. 167]. А.Т. Кайдаров бу терминның «бог грозы» дигән мәгънәсе барлыгын билгеләп үтә [Кайдаров, 1986]. Р.И. Куряева атама *тар* – «труд по найму» һәм *хан* (титул исеме) сүзләреннән тора, дип уйлый [Куряева, 1992, с. 123].

Безнең фикеребезчә дә, атама *тар* һәм *хан* сүзләреннән торырга мөмкин. *Тар* сүзе бу очракта «узкий» мәгънәсен бирә, ягъни «тар хан – биләмәсе чикләнгән хан, үз җирендә генә хан, бер кешесе дә аннан башка берәүгә дә буйсынмый, берәүгә дә ясак түләми».

*Кол* һәм *чура* («хезмәтче, игенче, сугышчы») титуллары белән Колчура, Биккол, Чурабатыр атамалары ясалган.

*Морза, мирза* (*әмир задә* – «әмир баласы; аксөяк, затлы токым») титулы белән Әлморза авыллары атамасы ясалган.

Шаһ титулы белән Мәүләшә, Гадельша, Шахмай авыл атамалары ясалган.

**Дини титулларга нисбәтле ойконимнар**

Мулла рухани титулы белән Татарстанда географик атамалар күп ясалган, чөнки электә һәр татар авылында диярлек бер яки берничә мулла булган.

Иске Муллино – Алексеев, Татар Мулла иле – Әлки районындагы авыллар.

Төрки халыкларда мәҗүсилек вакытында *кам* (шаман, колдун) титулы зур әһәмияткә ия булган.

*Qan, qam* – «шаман» [ДТС, 1969, с. 413] сүзенең «врачеватель, исцелитель, прорицатель, предсказатель, заклинатель, чудесник, чародей, маг, волшебник, колдун» мәгънәләре дә булган [Мурзаев, 1996, с. 160]. Кам титулы белән Камкино атамасы ясалган. Атама мишәр диалектындагы *камка* (божья коровка) сүзенә нисбәтле булырга да мөмкин.

**Профессияне аңлаткан сүзгә нисбәтле атама**

Билгеле булганча, иң борынгы кәсепләр – аучылык, күчмә терлекчелек, балыкчылык һәм игенчелек. Болгар-татар телендә кәсеп-һөнәр атамалары *-чы, -че* кушымчасы кушылып ясалганнар. Балахчино атамасы да шундыйлардан. Борынгы төрки телдәге *балукчы* – «рыбак» сүзеннән [ДТС, 1969, с. 112] Балукчы исеме һәм Балахчин фамилиясе ясалган.

### 3.1.2. Этнонимнарга нисбәтле ойконимнар

Азия күчмә халыкларының, шул исәптән татарларның да, ыру-кабилә структурасы бик катлаулы булган. Мәсәлән, Б.Я. Владимирцев үзенең «Общественный строй монголов» дигән хезмәтендә монголларның гына да 93 кабилә-ыругы булганлыкны күрсәтә [Владимирцев, 1934, с. 209–210]. Ул кабиләләрнең кайберләренең исемнәре төркиләр арасында да кабатлана: калпак, керей, кият, конгират, найман, уренхат.

И.Н. Лезина һәм А.В. Суперанскаяларның бөтен төрки халыкларның исемнәрен күрсәткән хезмәтләре бар [Лезина, Суперанская, 1994]. Анда төрки халыкларның этногенезында катнашкан 12 мең исем китерелгән.

Дөрес, кайбер халыкларда ыру-кабилә бүленеше булмаган. Мәсәлән, үзбәкләрдә. Аларда этнонимнар белән ясалган топонимнар бик аз [Губаева, 1972].

Аерым көтүлекләр, сулыклар, урман-аланнар, торак пунктлар һ.б. ниндидер бер кабиләгә бәйле булганнар һәм күп очракта бу кабиләләрнең исемнәре топонимикага күчкән.

Гомумтөрки чагыштырулар кызык. Мәсәлән, Сәмәрканд өлкәсендәге 3700 ойконимның 800 е этноойконим. Бохара өлкәсендәге 2800 торак пункт атамасының өчтән бере этноним белән бәйле һ.б. [Мурзаев, 1996, с. 185].

Татар халкының формалашуында да бер генә ыру яисә кабилә роль уйнамаган, киресенчә, бүгенге көндәге татар халкы ул кабиләләр, халыклар синтезы. Безнең тикшеренүләр дә шуны күрсәтә. Чагыштырмача кечкенә булган Көнбатыш Кама аръягында гына да ундүрт этноним табылды: Болгар, Биләр, Боламер, Баран, Каратай, Каргалы, Кәчи, Мукшы, Мордва, Нагай, Рус, Татар, Чуваш, Юган.

Болгар, Биләр этнонимнары турында инде күп язылган, күп тикшерелгән. Монда ниндидер яңалык кертү шактый авыр. Шуңа күрә без кыскача берничә фикерне генә китерәбез.

Профессор Н.И. Золотницкий Болгар һәм Биләр атамалары бер үк сүзнең каты һәм нечкә әйтелешле вариантлары дип саный [Золотницкий, 1884, с. 12]. Ф. Гордеев болгар этнонимын, *болгар < болга < волга + ар* «ир, ир кеше» төзелешен тәшкил итә һәм «Волга елгасы буенда яшәүче кешеләр, халык» мәгънәсен белдерә, дип саный. Волга гидронимының килеп чыгышы балтик телләренә нисбәтле дип искәртә [Гордеев, 1967, с. 194].

Ш. Мәрҗани болгар этнонимының килеп чыгышын *болгау* фигыленә бәйләп аңлата [Мәрҗани, 1910]. Г.Ф. Саттаров булгар – болгар этнонимын *булуг + ар* (булугар) төзелешен тәшкил итә һәм «булган ар», «булган ир», «булган кеше», «булган, уңган кешеләр», «булган, уңган, булдыклы кабилә, халык» мәгънәсен аңлата дип әйтү ягында тора [Саттаров, 1973, б. 144]. Биләр атамасын ул, борынгы төрки титул исеме *би* сүзенә *-ләр* күплек кушымчасы кушылып ясалган, ди [Саттаров, 1973, б. 146]. «Болгар дәүләте төзелгәнче үк, – дип яза М.З. Зәкиев, – Кама буйларында яшәгән биар (бигер, биләр) кабиләләре төрки җирләргә барып чыкканнар, башка кабиләләр белән сату-алу һәм хәрби мөнәсәбәткә кергәннәр... Пермь шәһәре исеме „биар“ сүзеннән ясалган. Биарм атамасына мөнәсәбәтле. Моңа кадәр фантастик ил дип уйланылган. Биармия чынлап та яшәгән. Икенче

төрле аны Биләр яисә Бигер дип атаганнар. Идел һәм Чулман елгалары буйларында Идел-Чулман болгарлары дәүләте төзелгәннән соң ул бу ил составына керә» [Гарипова, 1994, б. 182].

Һ.В. Йосыпов Болгар шәһәре хәрабәләре янында табылган XIV гасыр кабер ташында *Мон Булер* дигән кушамат укый һәм ул аны ике этноним катнашмасы дип уйлый. XV–XVII гасыр эпитафияләрендә дә Биләр этнонимы чагылыш таба. Идел-Чулман болгарларында Бүләртай дигән кеше исеме дә булган [Гарипова, 1994, б. 180].

Болымер этнонимы да Биләр этнонимының бер формасы булырга мөмкин. П.И. Рычков – Биләрнең «Булумәр» (Булумер), С.М. Шпилевский һәм Р.Г. Фәхретдинов «Бүләмәр» формалары булганлыгын язалар [Гарипова, 1994, б. 181]. *Бүләмәр* «билямарий» (марича *пыламарий*) этнонимының фонетик варианты булырга мөмкин. Мари галиме С.Я. Черных билямарийның *биләр* һәм *мари* сүзләре кушылып ясалуын, биләрнең төрки кабилә болгарларга мөнәсәбәтле, ләкин сөйләм телендә «р» авазы төшеп калу нәтиҗәсендә билямарий формасы барлыкка килүе хакында яза.

Һ.В. Йосыпов болгар кабер ташларын җентекләп өйрәнә һәм, моңарчы билгеле булганнардан тыш, тагын Катай, Табын, Мин, Биләр, Балымәр, Көек, Орым, Кәче һ.б. төрки халыкларда да билгеләнгән шактый күп этнонимнар барлыгын ачыклый [Юсупов, 1971].

Көнбатыш Кама аръягында Болгар, Биләр, Балымәр (Бүләмәр) этнонимнары белән түбәндәге торак пункт атамалары ясалган: Биләр (Алексеев районы), Болгары, Болгар, Болымеры (Спас районы), Кызыл Болгар (Чистай районы).

Бәрән елгасы ярларында Николаев Баран, Арбузов Баран, Кызыл Баран авыллары урнашкан.

А.Х. Халиков фикеренә караганда, гидроним һәм ойконим атамалары *бәрәнҗәр* дигән этнонимга мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән. Бу атаманың этнонимик характерда булуын В.А. Никонов та күрсәтеп узды. А. Гусейнзадә, бәрәнҗәр Төньяк Дагстанда сакланып калган хәзәр топонимы Belan-

sar’дан барлыкка килгән, ди. Ул, немец галиме Дерферның фикеренә кушылып, хәзәр топонимы Belansar’ның «армиянең уң канаты» мәгънәсен аңлата торган монгол хәрби термины Balanjar’дан үзгәргәнлеген һәм бу терминның шушы ук мәгънәдә яңа фарсы теленә дә кергәнлеген әйтә. Г.Ф. Саттаров Бәрән атамасы белән бер үк ояга Бирәзә атамасын да кертә һәм бу исемнәрне ул бәрәнҗәр этнонимы белән бәйләп карый. Ул түбәндәге фонетик үсеш этапларын күрсәтә: беренджер < бәрәнзәр < Бәрәзә < Бирәзә.

Каратай этнонимы Татарстанда да, аннан читтә дә торак пункт атамаларында, гидронимнарда шактый киң таралган.

Каратай ойконимының килеп чыгышын (карачай этнонимы кебек үк) Каратай, Карачай «кара елга» гидронимы белән бәйләп карарга кирәктер [Саттаров, 1980, б. 32–49]. Каратай елгасы буенда яшәгән мордва кабиләләре үзләренә исемне гидронимнан алган булсалар кирәк.

Каргалы авылы атамасы «карга» дигән башкорт этнонимына нисбәтле [шунда ук]. Болгар җирләре бушап калганнан соң, бу территориядә башкорт кабиләләре җәйләүгә килгәннәр. Карга гидронимы да бу якларда бар.

Кәче ойконимы көнбатыш Себер төркиләре – кәчиләр – белән бәйле булырга мөмкин. Хәзерге кәчиләр (хакаслар) төркиләшкән сомадилар булырга тиеш [шунда ук]. Самади телендә *ба* сүзе суны аңлата. *Ба~бо~ма* компоненты белән Казан артында Күлмә, Тойма, Шушма, Ушма, Норма кебек гидронимнар ясалган. Димәк, безнең җирләрдә эра башында борынгы кәчи кабиләләре килеп чыккан булырга мөмкин.

Мукшы – мордваның бер этник тармагы. Бу этноним белән Татарстанда берничә ойконим ясалган, шул исәптән Аксубай районында да. Мордва – бүгенге көндә яшәүче халыкның атамасы. Татар, рус, чуваш, мордва кебек этнонимнар авыл атамалары составында, сүзтезмәдә беренче компонент булып киләләр.

Мордва этнонимы Мордва Булагы (Алексеев), Мордовское Афонькино (Чирмешән), Мордва Баганалысы (Чистай) авыллары атамасы составында сакланган.

Рус этнонимы белән Рус Кәрәмәте, Рус Марасасы Рус Тегельбәс, Рус Чиябашы, Русская Чебоксарка, Иске Рус Әмҗәсе, Русское Богдашкино, Русская Менча, Рус Тирмәннеге, Рус Сарсазы, Рус Ялтаны ойконимнары ясалган.

Татар этнонимы турында без югарыда язган идек инде.

Чуваш этнонимы белән Яңа Чуваш Әдәмсуы, Иске Чуваш Әдәмсуы, Чувашское Енорускино, Чуваш Майнасы, Чуваш Шәпкесе, Чуваш Кичүе, Чуваш Борнае, Чуваш Чабаксары, Чувашская Менча, Чуваш Тирмәннеге, Чувашское Афонькино, Чуваш Ялтаны ойконимнары ясалган.

*Нагай* сүзен без антропонимга да, этнонимга да кертеп карыйбыз. Монгол телендәге *нагай* – «эт баласы, көчек» антропонимы этнонимга да әйләнгән. Нагай исеме, фонетик үзгәреш кичереп, нугай формасын алган.

Норлат районында Юган (йуган – «ермак», «агым», «елгачык», «инеш») дигән елгачык буенда Юган дигән татар-рус-уваш авылы бар. Н.А. Баскаков, борынгы болгар теленнән сакланып калган сүзләргә мисал, итеп йупан кабиләсе исемен дә китерә [Баскаков, 1969, с. 235]. Йупан этнонимы халкының Йуwан (Йуwан > Йупан) елгасы буенда яшәүгә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килү ихтималы бар. Шушы уңайдан *ю (йу), jo* тамырлы сүзләрнең фин-угыр телләрендә дә «елга» мәгънәсендә кулланылуын әйтергә кирәк [Лыткин, Гуляев, 1970, с. 334].

Болардан чыгып, татар теленең нократ-кистем сөйләшендә сакланган *йоwан* «елга аръягы» һәм чирмеш телендә башта Идел болгарларын, аннан соң Казан татарларын атау өчен кулланыла торган *йуwас, суwас, суас* – «елга аръяклары» сүзенең асылында борынгы болгар телендә «агым», «елга», «су» мәгънәсендә кулланылышта йөргән *йуwан* сүзе ята, дип әйтә алабыз [Саттаров, 1973, б. 245–246].

### 3.1.3. Топонимнарга нисбәтле ойконимнар

Җирле географик объектларның күбесенә бик борынгы заманнарда ук исемнәр бирелгән. Бу исемнәр, буыннан-буынга күчә барып, бүгенге көнгәчә артык зур үзгәрешләр кичермичә,

безгә килеп җиткәннәр. Менә шуңа алар әйләнә-тирә табигать, халыкның теле, тарихы, тормыш-көнкүреше, хуҗалык итү ысулы, гореф-гадәтләре турында байтак кына бик борынгы һәм кыйммәтле мәгълүматларны хәбәр итүче чал тарих хәбәрчеләре булып саналалар.

**Гидроойконимнар**

Татар гидронимнарының үзенчәлеге – аларның эчке дөньясының җәмгыять ихтыяҗлары, бу атамаларны тудырган татар халкының тормыш шартлары, тарихи үсеше белән бәйле булуы [Гарипова, 1994, б. 61].

Башка халыклардагы атамалар кебек үк, татар гидронимнарының төрдәшләре мәгънә төрлелекләре күп кенә су чыганакларының физик-географик үзенчәлекләре, шул төбәктә яшәгән халыкның рухи халәте, тормыштагы урыны, хуҗалык эшчәнлеге һ.б. хакында мәгълүматлар белдерәләр.

Көнбатыш Кама аръягында гидронимнарга нисбәтле атамаларга түбәндәгеләрне кертәбез: Баланда, Бахта, Березовка, Зирекле, Иске Күл, Йауширмә, Ерыклы, Калиновка, Карамалы, Кармалы, Әшнәк, Сөлчәбаш, Киса, Көрнәле, Майна, Мораса, Сушка, Селенгуш, Тарн-Вар, Чаллы, Шәрбән, Үргәагар, Чиябаш, Әдәмсу, Илюткино, Чирмешән, Нохрат, Нарат-Елга, Шонтала.

Верхняя Баланда, Нижняя Баланда авылларының атамасы Баланлы елгасы исеменә мөнәсәбәтле. Баланлы – Олы Инеш елгасы кушылдыгы [Гарипова, 1990, б. 179]. Елга буйларында балан агачлары үскәнгә күрә, елгага шундый исем бирелгән булса кирәк.

Бахта авылының (Чистай районы) атамасы Бахта гидронимыннан алынган. Бахта елгасы Шонтала елгасының сул кушылдыгы [Гарипова, 1990, б. 180]. Борынгы төрки телдә *бахт* «счастье» мәгънәсен бирә [ДТС, 1969, с. 89], татарча – бәхет.

Березовка авылы Алексеев районында Березовка суы буенда урнашкан. Березовка суы Шонтала суының сул кушылдыгы.

Баланда, Березовка, Зирекле, Ерыклы, Калиновка, Карамалы, Кармалы, Чиябаш гидронимнары да ярларында үскән агачлар исеменнән ясалганнар. Зирекле/Ерыклы атамалары икесе дә

бер үк агачны аңлата. Без монда *з ~ е* күчеше күрәбез. Ерыклы атамасы башкорт теле варианты. Регионда Зирекле елгасы да, Йырыклы елгасы да бар. Зирекле елгалары хәтта икәү: 1. Кече Чирмешәннең сул кушылдыгы (Чистай районы); 2. Кичү елгасының сул кушылдыгы (Яңа Чишмә). Йырыклы елгасы Олы Чирмешән кушылдыгы (Норлат районы) [Гарипова, 1990, б. 199].

Ерыклы/Зирекле гидронимнары белән түбәндәге ойконимнар ясалган: Седулово – Ерыклы (Аксубай); Алексеев районындагы Ерыкла дигән рус авылын татарлар Зирекле дип йөртәләр; Яңа Чишмә районында да Зирекле/Ерыклы авылы бар; Норлат районында Ерыкла/Зирекле; Ерыклы (Чистай районы).

Калиновка – Аксубай районындагы авыл һәм елга буларак Олы Инеш кушылдыгы. *Калина* – балан сүзен аңлата.

Карамалы елгачыклары да икәү: 1. Олы Чирмешәннең уң кушылдыгы (Чирмешән); 2. Кече Чирмешән кушылдыгы (Әлки). Карамалы – Әлки районындагы татар авылы.

Кармалы суы Олы Чирмешәннең уң кушылдыгы (Чирмешән). Бу исемдәге елгалар Мамадыш һәм Әлмәт районнарында да бар. Верхняя Кармалка, Түбән Кармалка Чирмешән районындагы авыллар.

Рус Чиябашы, Татар Чиябашы авыллары Чия елгасының башланган урынына урнашканга шулай аталганнар.

Яуширмә авылы атамасы *яу* + *ширмә* рәвешендә ясалган. Идел болгарлары телендә *шыр~ширми~ширмә* сүзе, чувашларның ширма термины кебек, «елга, елгачык, чокыр» мәгънәсендә йөргән. Авыл атамасы Яуширмә дигән елгачык исеменнән алынган.

Әшнәк авылларының атамасы Әшнәк елгасы исеменнән алынган. Әшнәк – Кама елгасының уң кушылдыгы. Күп кенә галимнәр Әшнәк гидронимын Ашлы атамасы белән бәйләп карыйлар. Без дә шушы фикергә кушылабыз.

*Аш~ош* тамыры булган гидронимнар һәм топонимнар хәзерге Татарстанда һәм аннан читтәге җирләрдә дә шактый күп очрый. Бу атамалар борынгы төрки «аш» этнонимына барып тоташалар.

Гарәп телендә *ашыт* – «сазлык», «сазлыклы урын» төшенчәләрен белдерә. Һ.В. Йосыпов Ашлы һәм Ашытның бер этнонимның төрдәшләре булуын дәлилли. А.Х. Халиков, борынгы төрки ашина ыругы башка төрки кабилә-кавемнәр арасында безнең эра башларында Алтайдан Көнчыгыш Европага үтеп кергән, дип уйлый. Бу фикерне нигез итеп алып, Г.Ф. Саттаров Ашытны – борынгы төрки ашина (бүре) ыругы атамасының күплек кушылмасы -т алган формасы, дип карый. Ашина кабиләләренең бер өлеше хәзерге Татарстан төбәгенә килеп чыккан һәм андагы Ашыт елгасына үз исемен биреп мәңгеләштергән. Археолог-галимнәр А.П. Смирнов һәм С.А. Плетнева мәгълүматларына таянып, Н.Б. Борһанова Ашыт атамасын борынгы төрки-хәзәр ашын кабиләләре белән мөнәсәбәтле дип уйлый һәм үзәкләре Ашлы шәһәре булган болгар кабиләләре дә шушы ашыннарга барып тоташа булса кирәк, дигән фикерне алга сөрә [Гарипова, 1994, б. 128].

Сөлчәбаш авылы – Сөлчә елгасының башланган урынына урнашканга шулай аталган. Регионда Кече Сөлчә һәм Олы Сөлчә елгалары бар. Кече Сөлчә Олы Сөлчә елгасының уң кушылдыгы. Киси ойконимы Киса гидронимына нисбәтле. Киса елгасы Кече Сөлчә елгасының сул кушылдыгы.

Көрнәле авылларының атамасы Көрнәле суы белән бәйле. Көрнәле елгасы Кама елгасының сул кушылдыгы.

Майна елгасы атамасыннан да ойконимнар ясалган. Майна Иделнең сул кушылдыгы. Э.М. Мурзаев «майна» сүзен «прорупь, полынья; открытый участок воды между льдинами» дип аңлата [Мурзаев, 1984, с. 359].

Мараса (Алексеев), Күлбай-Мораса, Кече Күлбай-Мораса (Норлат) ойконимнары Мораса гидронимына бәйле. Мораса – Кече Чирмешәннең сул кушылдыгы. Гидроним «мара» сүзенә нисбәтле булырга мөмкин. Мара – «песчаный берег, отмель, коса» [Мурзаев, 1984, с. 362]. Г.Ф. Саттаров Мораса гидронимы монгол *мурән, мора* «елга» + һун *са, су* «елга» тезелмәсеннән гыйбарәт кушма сүз булса, монгол һәм һун телләрендә «елга» мәгънәсен белдергән сүзләрнең бергә кушылуы, ягъни

борынгы заманнарда монгол һәм һун кабиләләренең үзара көрешүеннән гыйбарәт тарихи-этник процесслар нәтиҗәсендә барлыкка килгән булып чыга [Саттаров, 1998, б. 23]. Без дә шушы фикергә кушылабыз.

Сушка авылы атамасы Сушка елгасы исеменнән алынган. Атаманың тамыры *сушь* сүзе. Э.М. Мурзаев «Сушь, сушка, усушка – «мели, которые используются как участки рыбной ловли», – дип аңлата [Мурзаев, 1984, с. 533].

Селенгуш (Сәләнгеш) – Олы Сөлчә елгасының уң кушылдыгы. Норлат районында Селенгуш авылы яныннан ага. Күпмедер дәрәҗәдә Селенгуш гидронимын Селенга гидронимы белән чагыштырырга мөмкин. Э.М. Мурзаев аны «восточный ветер на Байкале, дующий со стороны долины и дальты р. Селенги» дип аңлата [Мурзаев, 1984, с. 507]. Сүзнең этимологиясе бәхәсле.

Тарн-Вар ойконимы Тарн-Вар гидронимы белән бәйле. Тарн-Вар авылы һәм елгасы Норлат районына керәләр. Елга Киекленең уң кушылдыгы [Гарипова, 1990, б. 244]. Гидроним *тарн* һәм *вар* сүзләреннән тора. *Тарн, тарна* чуваш телендә «торна» дигәнне аңлата [Чувашско-русский словарь, 1961, с. 406]. *Вар* сүзе борынгы хуннар телендә үк *Var* – «река» мәгънәсендә йөргән. Хуннар Днепрны *Var* дип атаганнар. Чуваш телендә *вар, варон, волон* бүгенге көндә дә «овраг: долина, лог, ложбина, сухой овраг, русло реки, ручеек» мәгънәләрендә йөри [Саттаров, 1989, б. 9–11]. Димәк, Тарн-Вар атамасы «торна елгасы» дигәнне аңлата булып чыга. Бу елгада торналар күп булганга шулай аталгандыр күрәсең. Г.Ф. Саттаров *тарн* сүзен чуваш телендәге *таран* сүзе белән тәңгәл дип күрсәтә. *Таран* – «глубокий»: татарча – тирән. «Тирән чокыр» мәгънәсе килеп чыга [шунда ук].

Әлки районындагы Бибай Чаллысы, Яңа Чаллы, Иске Чаллы авыллары Чаллы елгачыгы буена утырганга шулай аталганнар. Әлки районында Чаллы – Актай елгасының, Алексеев районында – Бәрән суының кушылдыгы [Гарипова, 1990, б. 252–253].

Норлат районындагы рус авыллары да Иске Чаллы, Урта Чаллы, Түбән Чаллы атамаларын йөртәләр. Чистай районында Чаллыбаш авылы бар. Шишмә елгасына коючы Чаллы елгачыгы башына утырганга күрә бу авыл шулай аталган.

XIX гасырда Казан губернасы топонимиясен өйрәнүгә зур өлеш керткән галим И.А. Износков бу авылларның күбесенең Чаллы дигән елгачыклар бассейнына утырганга шулай аталуларын әйтә [Износков, 1885, с. 69].

*Чаллы* топокомпоненты Чаллы гидронимына мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән. Бу елгага исә, ярларының һәм төбенең ташлы булуларыннан чыгып, Чаллы («Ташлы») исеме бирелгән. *Чал~чул* сүзе (биредә *у* һәм *а* сузыкларының тарихи тәңгәллеге чалына) борынгы болгар-татар телендә «таш» төшенчәсен белдергән. Чуваш телендә *чул* сүзе хәзер дә «таш» дигән мәгънә аңлата. Чувашлар Түбән Новгородны Чулхула, ягъни «Ташкала», дип йөртәләр. Монгол телендә дә *чулу* сүзе «таш» мәгънәсен белдерә.

Г.Ф. Саттаров, Ф.Г. Гарипова, Э.М. Мурзаев, *чаллы* сүзен болгар телендә «ташлы» мәгънәсендә йөргән, дип күрсәтәләр [Саттаров, 1974, б. 3; Гарипова, 1975; Мурзаев, 1984, с. 606]. Г.Ф. Саттаров Татарстанда *чаллы* сүзе белән 20 атама, Урта Идел буенда 50 атама күрсәтә.

Шәрбән – Кирәмәт елгасының кушылдыгы. Шәрбән авылы шушы елга буена урнашканга шулай аталган. Гидроним үз чиратында Шәһрибану дигән хатын-кыз исеменнән ясалган, дип уйлыйбыз.

Әлки районындагы Яңа Үргәагар, Иске Үргәагар авыллары атаманы Үргәагар елгасы исеменнән алганнар.

Аксубай районындагы Иске Чуваш Әдәмсуы, Яңа Чуваш Әдәмсуы, Яңа Татар Әдәмсуы, Иске Татар Әдәмсуы ойконимнары Әдәмсу елгасына нисбәтле. *Әдәм* гарәп телендә «кеше, кешеләр» мәгънәсендә йөри һәм кеше исеме булып та тора.

Илюткино авылы атамасы Илләт гидронимына нисбәтле.

Ф.И. Гордеев бу гидронимны балт теленә нисбәтли [Гордеев, 1973, с. 229–230].

Ф.Г. Гарипова Илләт гидронимын Ашыт, Кыят кебек атамалар белән бер үк ояда карый, атаманы төрки телгә нисбәтли [Гарипова, 1994, б. 104], без аның фикеренә кушылабыз.

Чирмешән ойконимы гидроним белән бәйле. Олы Чирмешән елгасы буенда утырганга авыл шулай аталган. Олы Чирмешән – Идел елгасының сул кушылдыгы. Ул Самара, Ульяновск өлкәләреннән һәм Татарстан җирләреннән ага, гомуми озынлыгы – 465 чакрым.

Кече Чирмешән – Олы Чирмешән елгасының кушылдыгы. Ул Татарстан һәм Самара өлкәсе аша агып уза, гомуми озынлыгы – 214 чакрым.

Чирмешән сүзенең этимологиясе белән күп галимнәр кызыксыналар. М.З. Зәкиев бу атаманың мәгънәсен Чирмешән – «майлы, сагызлы урман елгасы» дип аңлата. Р.Г. Әхмәтҗанов Чирмешән сүзен «гаскәр җыела торган урын» дип уйлый. Н. Исәнбәтчә, Чирмешән атамасы борынгы эпослар каһарманы Чирү Мәмшәнгә мөнәсәбәтле. Чирү Мәмшән – «гаскәр башы»н аңлата. Ф.И. Гордеев Чирмешән атамасын «Сармат суы» дип аңлата [Гарипова, 1994, б. 119]. Г.Ф. Саттаров атаманы ике төрле аңлатып карый. Беренче мәгънәсе – «Чирмешләр елгасы», ягъни ярларында марилар яшәгән елга. Икенче мәгънәсе – «...Идел-Кама болгарлары телендә «чирме, чирмә» сүзе «елга, елгачык, инеш» мәгънәсендә кулланылган. Чуваш телендә «сырма» сүзе хәзер дә «елгачык, инеш, чокыр» мәгънәсендә кулланышта йөри.

Чирмешән гидронимының икенче компонентын тәшкил иткән *шән, шөн, сән, сөн* сүзе борынгы төрки кабиләләр телендә «елга» мәгънәсендә йөргән [Саттаров, 1984]. Без икенче фикергә кушылабыз.

Нохрат – Әлки районындагы рус авылы, Чулман аръягында Актайга коючы Салман суының уң кушылдыгы Нократ гидронимына нисбәтле. «Нохрат» формасында С.М. Шпилевский, Д.А. Корсаков, А.И. Артемьев тарафыннан бастырып чыгарылган чыганакларда искә алына.

Чулман суы тирә-юнендә яшәгән болгарлар, тарихи чыганаклар күрсәтүенә караганда, Идел тирәсендә яшәгәннәреннән

аермалы буларак, Көмеш яисә Нократ болгарлары дигән исем белән билгеле булганнар. Нократ тәгъбиренең асылы гарәп телендәге *накәр* – «көмеш» сүзеннән гыйбарәт [Гарипова, 1994, б. 212].

X гасырда яшәгән гарәп тарихчысы Мәсүди «Төркиләрнең бертуган дүрт кабиләсе баҗла, бәҗәнәк, бажгурд һәм нухардалар славяннар җиренә яу чабалар», – дип яза.

Нарат-Елга авылы Чистай районында урнашкан. Авыл Олы Бахта елгасының уң кушылдыгы Кала-Елга суының сул ягына утырган. Бу елга тирәсендә нарат агачлары күп үскән. Аларның тамырлары 1911 елда тау казыганда бик күп чыгалар. Кала-Елга атамасының беренче компоненты *Кала* сүзе, *Нарат* сүзе белән алыштырылган һәм Нарат-Елга атамасы туган.

Көнбатыш Кама аръягында өч авылның атамасында *Шонтала* компоненты бар. Бу авылларның атамасы Шонтала елгасына нисбәтле.

Бүлекне йомгаклап шуны әйтәсе килә. Көнбатыш Кама аръягы – елгаларга, күлләргә бай регион. Болгар бабаларыбыз яшәү өчен урынны сайлый белгәннәр. Атамаларның күбесе болгар заманнарыннан ук килеп җиткәннәр. Гидронимнар, безнең фикеребезчә, ойконимнарга караганда да борынгырак булырга тиеш. Чөнки елгалар үзләре дә торак пунктларга караганда борынгырак.

Җирле халык тормышында бу елгалар борынгы заманнарда да, хәзер дә зур роль уйныйлар.

## Гидрографик номенклатура терминнарыннан ясалган атамалар

Р.И. Донидзе «Төрки телләрдә гидронимик терминнар» дигән мәкаләсендә төрки телләрдәге гидронимик терминнарны лексик-аналитик яктан 5 төркемгә бүлеп карый [Донидзе, 1969, с. 16–17]. Г.Ф. Саттаров бу классификациягә тагын ике пункт өсти [Саттаров, 1996, б. 20]. Без шушы классификациягә таянып эшлибез. Көнбатыш Кама аръягында бу классификациянең бөтен пунктларына да атамалар табылмады.

А) төрле озынлыктагы һәм төрле характердагы елгаларны белдерүче терминнар

Бу төркемгә караган гидрографик терминнар арасында иң күп таралган һәм актив кулланыла торганы – *су* термины. Борынгы төрки телдә *су* сүзе *sub, suv* һәм *suu* рәвешле йөргән: 1) су, «вода»; 2) елга, «река» һ.б. мәгънәләрне белдергән [ДТС, 512, с. 515].

О.Т. Молчанова мәгълүматларына караганда, *су* термины үзе генә аерым су чыганагы атамасы булып бик сирәк, ләкин шул ук вакытта ике, өч сүздән торган гидронимнар составында еш кулланыла [Молчанова, 1979, с. 91].

*Су* гидрографик термины, гомумән, «су-сыеклык» төшенчәсен белдерүдән бигрәк, «елга» мәгънәсен белдергән хәлдә, Татарстан гидронимнары һәм алар аша «гидроним-ойконим» нисбәтендәге топонимик метанимиягә нигезләнеп (бу очракта теге яки бу су, «елга» буена утырган торак пунктның шул су, «елга» атамасы белән аталуы, ягъни гидронимнан ойконимга әверелүе аркасында), ойконимнары составында да урын ала [Саттаров, 1998, б. 21].

Көнбатыш Кама аръягында су термины белән ясалган авыллар: Яңа Чуваш Әдәмсуы, Иске Чуваш Әдәмсуы, Яңа Татар Әдәмсуы, Иске Татар Әдәмсуы, Карасу (Аксубай районы), Рус Морасасы (Алексеев районы), Татар Суыксуы, Суыксу (Әлки районы), Кече Күлбай-Мораса (Норлат районы), Чебоксарка (Яңа Чишмә).

Карасу – элекке СССР территориясендәге бик күп елга, елгачык һәм инешләрнең атамасы. Бу атама, «җир-су, җир астыннан чыгучы су, елга» төшенчәсен белдергән хәлдә, борынгы төрки телдән үк килә, дип санала [Кононов, 1954, с. 84–85; Мурзаев, 1959, с. 102.).

Көнбатыш Кама аръягы гидронимиясе һәм ойконимиясендә *су* гидрографик термины *са* фонетик вариантында очрый. Мәсәлән, Чебоксарка – чебакса: *чабак* + сар *са* ~ *су* – «елга»; Мораса: *мора* – «елга» + һун *са, су* – «елга», «елга + елга».

*Ширмә ~ чирмә ~ чирме* – «сулы чокыр, тирән чокыр; елга» орогидрографик термины белән Яуширмә, Чирмешән гидронимнары ясалган.

Елга. Элек *елга* сүзе бары уртача зурлыктагы агым суларны атау өчен файдаланылган. Хәзерге татар телендә исә ул зур һәм кечкенә елгаларга карата да кулланыла [Гарипова, 1994, б. 38]. Әлеге термин үзенең генезисы белән гомумалтай географик номенклатурасына барып тоташа: монгол – *жолга,* бурят – *жалга, елга,* эвенк – *дэлгэ,* тува – *джалга* «чокыр, озын сыза, уйсулык, иңкүлек», казак – *жилга* «инеш, чокыр эчендәге елга», башкорт – *йылга,* татар – *елга* «елга, агымсу һ.б. Бу *елга* термины белән безнең регионда Нарат-Елга гидронимы, аннан ойконим ясалган.

«Елга» мәгънәсендә йөрүче искергән *вар* һәм *шән, шөн, сөн* сүзләре белән Тарн-Вар һәм Чирмешән гидроойконимнары ясалган.

Болак. Күпчелек төрки телләрдә бу термин «чишмә, чыганак» мәгънәләрен белдерә. Татар телендә бу сүзнең мондый мәгънәсе очрамый [Саттаров, 1998, б. 51; Гарипова, 1994, б. 41]. В.В. Радлов: «„Болак“ сүзе Казан татарларында елгачык, Казандагы бер канал исеме буларак кулланыла», – дип күрсәтә [Радлов, 1911, с. 1837]. «Борынгы төрки сүзлек»тә *булак* сүзенең: 1) чыганак 2) канал мәгънәләре күрсәтелгән [ДТС, 1969, с. 211]. Төркиләр *bulak* дип болганчык сулы чишмәгә әйтәләр [Будагов, 1869, 288 б.]. Э.В.Севортян сүзнең барлык төрки телләрдә дә диярлек, башлыча «чишмә» мәгънәсендә кулланылуын күрсәтә [Севортян, 1978, с. 257]. Көнбатыш Кама аръягында без бу сүзне «елга» мәгънәсендә карыйбыз, чөнки ул елгачыкны аңлата. Мордва Болагы (Алексеев районы) ойконимы шушы терминнан ясалган.

Ә) елга объектларының төрле өлешләрен белдерүче җирле гидрографик терминнар һәм алардан ясалган ойконимнар.

Гомумтатар телендә *кәкре* термины «елганың бөгелгән, борылыш ясаган урынын» белдерү өчен хезмәт итә [Саттаров, 1998, б. 44]. *Кәкре* сүзе катнашып, Кәкре Күл (Аксубай районы)

атамасы ясалган. Бу сүз белән Кәкре Атау атамасы да ясалган. Ләкин бу очракта *кәкре* сүзе гидрографик термин ролен үтәми.

*Баш* термины елганың (чишмә, күл) башланып киткән өлешен, баш өлешен, башын белдерә. Татарстан ойконимиясендә теге яки бу елганың, суның, күлнең, чишмәнең яки башка берәр географик объектның башланып киткән җиренә утыруыннан чыгып, «елга атамасы + *баш, башы*» төзелмәсе ясалган. Көнбатыш Кама аръягында «баш» сүзе белән Чиябашы, Сүлчәбаш, Чаллыбаш гидроойконимнары ясалган.

Б) фонтан формасындагы су чыганакларын белдерүче гидрографик терминнар һәм алардан ясалган ойконимнар

Чишмә. Фарсы телендә *чәшм* сүзе «күз»не белдерә. *Чишмә* сүзе «источник, родник, ключ» мәгънәләрен белдерү өчен хезмәт итә. Типтәрләр чишмәне сишмә рәвешле атап йөртәләр, байбагыш сөйләшендә тишмә формасында кулланыла. *Чишмә* сүзе белән Кызыл Чишмә, Чишмә (Алексеев районы), Яңа Чишмә (Яңа Чишмә районы), Чишмә (Норлат районы), Кара Чишмә, Кызыл Чишмә (Чирмешән районы) ойконимнары ясалган.

Көнбатыш диалект вәкилләре татар-мишәрләр чишмәне *кизләү* яки *күзләү* диләр. Норлат районында Кизләү авылы бар. Бу авыл Кизләү-Чишмә елгасы буенда урнашкан.

В) акмый торган су объектларын белдерүче җирле гидрографик терминнар һәм алардан ясалган ойконимнар

Күл – «бөтен яктан да ярлар белән уратып алынган табигый сулык» һәм «су түгелеп, җыелып барлыкка килгән кечкенә сулык» [Гарипова, 1994, б. 58]. Борынгы төрки телдә kol дип, «күл, су җыелып тора торган урын» аталган [ДТС, с. 313]. *Күл, kol* сүзенең «Күл» мәгънәсендә йөрүен В.В. Радлов та күрсәткән [Радлов, т. II, ч. II, 1965].

*Күл* сүзе белән безнең регионда түбәндәге ойконимнар ясалган: Кәкре Күл (Аксубай районы), Кыркүл (Алексеев районы), Каракүл, Иске Баллы Күл, Яңа Баллы Күл (Әлки районы), Якты Күл, Бий күле, Каракүл (Норлат районы), Урманасты Йорткүл, Урта Йорткүл, Кырый Йорткүл (Спас районы).

Саз – «өстенә су чыгар-чыкмас яки чыгып торган баткак җир, яисә артык сулану-юешләнү нәтиҗәсендә җебеп баткакка әйләнгән җир». Бу термин белән Чистай районында Татар Сарсазы атамасы ясалган.

Г) елга ярларына мөнәсәбәтле рәвештә якларны, ориентирны, урынны белдерә торган җирле гидрографик термин һәм аннан ясалган ойконим

*Кичү* термины зур елгаларда мал-туар су эчәргә төшә торган сай урынны белдерә [Саттаров, 1998, б. 72]. Бу термин белән Әлки районында Чуваш Кичүе авылы атамасы ясалган.

Д) су объектларының ярын аңлатучан термин һәм аннан ясалган ойконимнар

Гомумтатар *яр* гидрографик термины, төс белдерүче һәм башка сыйфат сүзләр белән аныкланып килеп, татар топонимиясендә бик күп атамалар ясалган: Кызыл Яр (Аксубай районы), Зур Кызыл Яр, Кече Кызыл Яр (Алексеев районы), Акъяр (Яңа Чишмә), Кызылъяр (Чирмешән), Красный Яр (Чистай).

Күреп үткәнебезчә, Көнбатыш Кама аръягында гидрографик терминнарга нисбәтле атамалар шактый. Бу факт безгә халык тормышының табигать белән тыгыз үрелеп, тыгыз бәйләнештә булуын күрсәтә. Бабаларыбыз табигатьне җимереп түгел, аның белән гармониядә, бер-берсенә ярдәм итеп яшәүне кулайрак күргәннәр. Гидрографик ойконимнарда бу ачык чагылыш таба.

**Орографик терминнарга нисбәтле ойконимнар**

Оронимия дигәннән без җир өсте рельефын, ландшафтын күз алдында тотабыз. Оронимнарга тау, калкулык, үрләрнең атамалары һәм аларның төрләре – үзәнлек, иңкүлек, чокыр атамалары һ.б. керә [Поспелов, 1969, с. 94; Саттаров, 1998, б. 75]. Терминнарны өч халәткә: таулы, тигез һәм чокырлы төркемнәргә бүлеп карыйлар. Бу бүленешкә тагын нәрсәдер өстәү авыр булыр иде, без дә шушы бүленешкә кушылабыз.

А) тауны белдерүче терминнан ясалган ойконимнар

Тау орографик термины белән Көнбатыш Кама аръягында түбәндәге ойконимнар ясалган: Кызыл Тау (Аксубай районы), Якты Тау (Чирмешән), Актау (Чистай районы).

Идел-Кама болгарлары телендә *тау* орографик термины, «тау» төшенчәсен белдерү белән бергә, күчерелмә мәгънәсендә, хәрби максатлардан чыгып, тау өстенә салынган кальга-крепостьны, ягъни кала-шәһәрне белдерү өчен дә хезмәт иткән булырга тиеш [Саттаров, 1998, б. 78]. Шушы мәгънәсендә Көнбатыш Кама аръягында Тубылгытау (Чистай районы), Каравыл Тавы (Норлат районы) ойконимнары ясалган. Болгар заманында бу регионда Җүкәтау, Калатау кебек атамалар булган. Рус телендә «тау» мәгънәсендәге *гора* сүзеннән Горка (Алексеев районы), Светлогорский (Чирмешән районы), Крутая Гора (Чистай районы) ойконимнары ясалган.

Э.М. Мурзаев *атау* сүзен «небольшой остров» дип аңлата [Мурзаев, 1984].

Г.Ф. Саттаров, «атау» сүзе чокыр белән уратып алынган калкулыкны белдерә, дип күрсәтә [Саттаров, 1998, б. 79]. Без бу фикергә кушылабыз. Кәкре Атау – Норлат районындагы авыл. Чынлап та, бу якларда авылга исем бирерлек утраулар (атау) юк, дип уйлыйбыз.

*Үр* термины да калкулыкны аңлата. Бу термин белән Үргәагар гидронимы, гидронимнан ойконимы ясалган.

Ә) тигез җир өстен белдерә торган орографик терминнар һәм алардан ясалган ойконимнар

Татар теленең тигез җир өстен, тигез рельефны белдерүче җирле орографик терминнары (кыр-басу, болын-печәнлек, көтүлек, туплавык, юл-сукмак, алан, үзәнлек, дала, урман, куак һ.б.) белдерә торган физик-географик объект һәрвакыт тигез җирдән, тигез урыннан гына гыйбарәт булмаска да мөмкин [Саттаров, 1998, б. 84].

Кыр. Борынгы төрки телдә *кыр* – «плоскогорье», *кыра* – «пашня» [ДТС, 1969]. Э.В. Мурзаев сүзлегендә «поле, степь, плато, увал, возвышенность, гора, гребень горы, берег, вы-

сокий берег, край, грань» мәгънәләре китерелгән [Мурзаев, 1984, с. 327]. Татар телендә «тигез җир» мәгънәсендә йөри. Ойконимнар: Кыркүл, Кыр Шонталасы (Алексеев районы).

Татар теле тарихында «дала», «тигезлек», «басу-кыр» мәгънәсендә йөргән *йаз* орографик термины да кулланылган. Бу сүз Идел-Кама болгарлары теленнән килә торган мирас булса кирәк. Аның генезисы борынгы төрки телдәге *jazï* – «степь, равнина» сүзенә [ДТС, 1969, с. 25] кайтып кала. Бу термин белән Норлат районында Төрнәс атамасы ясалган. *Төрнәс* сүзе *торна + яз* тезмәсеннән гыйбарәт, «торна кыры, басуы» мәгънәсен аңлата.

*Ялан* орографик термины катнашып, Чистай районында Кызыл Ялан ойконимы ясалган.

Гомумтатар теленә хас *таш* орографик термины белән Кече Акташ (Аксубай районы), Ташбилге (Әлки районы), Бакташ (Яңа Чишмә) ойконимнары ясалган. *Таш* орографик термины белән башта Ташбилге антропонимы ясалган, ә ойконим инде антропонимнан ясалган.

Идел-Кама болгарлары телендә *чаллы* сүзе «ташлы» мәгънәсендә кулланылган [Саттаров, 1998, б. 100]. Чаллы гидроорографик терминына нисбәтле рәвештә, VIII–XV гасырларда Идел-Кама болгарлары яшәгән Урта Идел – Урал регионында составларында әлеге термин булган байтак кына гидронимнар һәм ойконимнар барлыкка килгән, һәм күбесе безнең көннәргә килеп җиткән. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягында бу термин белән Бибай Чаллысы, Яңа Чаллы, Иске Чаллы (Әлки районы), Түбән Чаллы, Урта Чаллы, Иске Чаллы (Норлат районы), Чаллыбаш (Чистай районы) гидроойконимнары ясалган.

*Алан* орографик терминына нигезләнеп, татар топонимиясендә байтак кына татар һәм рус авылларының исемнәре барлыкка килгән. Урман эчендәге табигый ачык урын – аланга килеп утырып, авыл нигезләү, чәчүлек җирләре басу-кырлар барлыкка китерү өчен бик улай булган. Зур Алан – Әлки районындагы авыл.

*Юл* һәм *сукмак* терминнары, гомумтатар теленә хас лексик берәмлекләр буларак, татар теленең барлык сөйләшләрендә диярлек урын алалар. Кызыл Юл – Норлат районындагы авыл. Атама «социализм юлы, революция, азатлык юлы, яңа, якты юл» күчерелмә мәгънәсенә ия.

*Такталы.* Тигезлекне, тигез җирне белдерүче орографик термин. Бу термин белән Такталы (Аксубай районы), Яңа Такталы, Иске Такталы (Әлки районы), Татар Такталысы (Спас районы) ойконимнары ясалган.

Б) чокырны, чокырлы-батынкы урынны белдерүче җирле орографик терминнар

Алексеев районында Юеш Көрнәле һәм Коры Көрнәле дигән татар авыллары бар. Руслар да, татарлар да юеш, коры эпитетларын башлыча чокырлар, үзәннәр, елгалар, инешләргә һ.б. га карата кулланалар. Аларга юеш яки коры, кипкән-корыган булу үзенчәлеге хас. Димәк, Көрнәле топокомпонентының килеп чыгышын сулы яки сусыз физик географик объект (чокыр, үзән, саз, яр һ. б.) исеме белән бәяләп карарга кирәк [Саттаров, 1998, б. 128].

В.В. Радлов «Опыт словаря тюркских наречий» дигән хезмәтендә *күрәп, күрүп* сүзе «тирән чокыр, озын чокыр, иңкүлек, уйсу урын, баз» мәгънәсендә кулланылуын күрсәтә [Радлов, II т., II кисәк, 1899, с. 1454–1458]. Җир казу эше башкарыла торган коралны белдерүче *көрәк* сүзенең: 1) көрәк, 2) кискәк (тамыр өлеше *көр, күр,* шуннан *көрә, күрә* фигыле ясалган) «җирне казып керү» мәгънәләре бар. *Көрнәле* топокомпонентының да *көр (көрнә)* өлеше дә шул ук *көр* – «чокыр, уйсу җир, иңкү җир, батынкы урын» тамырына кайтып кала, *-ле* кушымчасы аның барлыгын, булуын белдерә, ягъни Көрнәле топокомпоненты «чокырлы, үзәнле, иңкүлекле, батынкы җир» дигән мәгънә аңлата. [Саттаров, 1998, б. 129]. Юеш Көрнәле атамасы «юеш (сулы) чокырлы авыл» мәгънәсен белдерә булып чыга.

Алексеев районындагы Зур Тигәнәле, Урта Тигәнәле, Түбән Тигәнәле дигән татар авыллары составында урын алган

*тигәнәле* топокомпоненты да *тигәнә* («тагарак») сүзенең метафорик рәвештә батынкы, чокырлы урынны, формасы белән тигәнәгә охшаш җирне белдерү өчен хезмәт итә, ягъни *тигәнәле* сүзе күчерелмә мәгънәдә «батынкы-иңкүлекле, чокырлы» дигән төшенчәне белдерә [Саттаров, 1998, б. 129]. Бу атаманың «тигәнәк» дигән үсемлек исеменә мөнәсәбәтле булу мөмкинлеген дә кире какмыйбыз.

**Фитонимнарга нисбәтле ойконимнар**

Татар халкы борынгыдан табигать белән, үсемлекләр дөньясы белән тыгыз бәйләнештә яшәгән. Шуңа күрә фитонимнар да (үсемлек атамалары) кешелек эшчәнлегендә актив катнашканнар. Алар ойконимнар составына да үтеп кергәннәр. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягында да фитоойконимнар шактый саллы төркемне тәшкил итәләр.

Урман. Шактый зур урын алып, тоташ күп булып үсеп утырган агачлар төркеме, шулай ук күп булып агачлар үскән мәйдан [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1981, III т. б. 313].

Идел буе татарларында һәм башкортларда *урман* термины теләсә нинди урманны – ылыслы, яфраклы, катнаш урманны яисә куе, үтә алмаслык урманны белдерү өчен дә хезмәт итә. Урта Азиядә, Казакстанда, Төрекмәнстанда, Төркиядә *орман* термины бары тик куе, үтә алмаслык чытырманлыкны атаубелдерү өчен генә йөри [Мурзаев, 1959, с. 239]. *Урман* топонигезе белән Алексеев районында – Урманасты Шонталасы, Аксубай районында – Урмандәй, Спас районында – Урманасты Йорткүл, Чирмешән районында Урманасты Үтәмеш фитоойконимнары ясалган.

*Балан* термины белән Аксубай районында Верхняя, Нижняя Баланда, Новая Баланда ойконимнары ясалган.

*Зирек ~ зирекле ~ ерыклы* (башкорт телендә *зирек*) фитотермины белән Алексеев, Яңа Чишмә, Норлат, Чистай районнарында Ерыклы (Зирекле) исемле авыл атамалары ясалган.

*Нарат* термины белән Нарат-Елга (Чистай районы) атамасы ясалган.

*Карама ~ карамалы* термины белән Әлки районында – Карамалы, Чирмешән районында – Верхнее Кармалка, Түбән Кармалка ойконимнары ясалган.

*Чия ~ чияле* термины белән Әлки районында – Рус Чиябашы, Татар Чиябашы, Норлат районында – Чияле ойконимнары ясалган.

Шомыртлы – Аксубай районындагы, Яңа һәм Иске Әлмәле – Чирмешән районындагы, Байтирәк – Чистай районындагы, Кычытканлы, Кечкенә Камышлы, Урта Камышлы – Норлат районындагы, Тубылгытау – Яңа Чишмә районындагы авыллар.

Фитотерминнар белән рус телендә дә байтак ойконимнар ясалган: Черемуха, Сосновка (3), Калиновка, Сосновой Ключ атамалары.

**Зоонимнарга нисбәтле ойконимнар**

Татарстанның Көнбатыш Кама аръягында зоонимнарга нисбәтле авыл атамалары күп түгел.

Спас районындагы Аграмаковка авылы атамасының нигезендә *аргамак* «лошадь» сүзе ята [Куряева, 1992, с. 39]: кырым татарлары телендә *аграмак* – «аргамак», татар, чагатай һ.б. төрки телләрдә – *аргамак* «кровная арабская лошадь». *Аргамак* сүзе борынгы төрки аргы «бежать крутым карьером» тамырына нисбәтле булса кирәк.

*Балык* зоологик терминыннан *балыкчы* профессиясе исеме, аннан кеше исеме, фамилиясе ясалган. Соңыннан гына инде ул ойконимга әйләнгән. Бүгенге көндә Балахчино Алексеев районындагы рус авылы. Бу очракта *балык* сүзенең «шәһәр» мәгънәсе кулланылмаган дип уйлыйбыз.

*Күтәмә* («ала балык», «форель») [Саттаров, 1998, б. 273] зоонимик термины белән Чирмешән районындагы рус авылы атамасы ясалган.

Каргалы орнитонимына нигезләнеп төрки-кыпчак кабиләләре этнонимы каргалы (карга, каргалы кабиләләре башкортларда, казакларда, үзбәкләрдә, каракалпакларда һ.б.да бар) барлыкка килгән. Татарстанның Чистай һәм Әлки районнарын-

дагы Каргалы дигән татар-мишәр авыллары атамасының килеп чыгышы әлеге *каргалы* этнонимына нисбәтле булырга тиеш. Кайбыч районында Каргалы дигән – рус, Мамадыш районында мари авыллары бар [Саттаров, 1998, б. 265].

Болгар-татарлар кыргый ау җәнлекләрен һәм кошларын гомумиләштереп киек зоологик термины белән атаганнар. Бүгенге көндә Киекле Норлат районындагы татар авылы.

Камка («божья коровка») дигән бөҗәк исеме белән Әлки районында Иске Камка, Яңа Камка дигән татар-мишәр авыллары атамалары ясалган.

Татарстан җирлегендә *торна* фитонимына нигезләнеп шактый күп географик атамалар ясалган. Татар халкы борын-борыннан бу мәһабәт кошны үз иткән, яраткан, хөрмәтләгән. Алар оя корган саз-күлләргә, елга-чишмәләргә, торналар яшәгән тау-калкулыкларга, кыр-басуларга, болыннарга торна сүзен кертеп исем кушканнар. Тора-бара бу исемнәр ойконимнарга да әйләнгәннәр. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягында мондый өч ойконим бар. Норлат районында Торнаяз, Төрнәс («торна кыры») һәм Тарн-Вар («торна елгасы») авыллар. *Тарн ~ тарна* сүзе чуваш телендә «торна» мәгънәсендә йөри [Чувашско-русский словарь, 1961, с. 406].

*Чабак* зоологик терминына нигезләнеп, иске татар телендә Чабак, Чапак, Чупак, Чабакай, Чупанай кебек кеше исемнәре ясалган [Саттаров, 1989, б. 28]. *Чабак* зоологик термины топонигез функциясен дә башкара. Чабаксар – Яңа Чишмә районындагы елгачык һәм авыллар исеме.

Регионда рус теленә нигезләнеп тә зооойконимнар ясалган. Лебедка, Татарская Волчья, Слобода Волчья (Яңа Чишмә районы), Лебяжье (Алексеев районы), Кузнечиха (Спас районы), Змеево (Чистай районы) атамалары әнә шундыйлардан.

Йомгак ясап шуны әйтәсе килә: лексик-семантик анализ күрсәтүенчә, чынлап та, ойконимнарда кеше тормышының, табигатьнең, тарих һәм мәдәниятнең, тел өлкәсенең бөтен яклары да чагылыш тапкан. Бу ойконимнарга карап, без әлеге төбәктә нинди кабиләләр булганлыгын, нинди кешеләр яшәгәнлеген,

аларның нәрсә эшләгәннәрен, нинди елга-күлләр барлыгын, нинди үсемлекләр үскәнлеген, нинди хайваннар булганлыгын һ.б.ны әйтеп бирә алабыз. Шуңа күрә дә ойконимнарны өйрәнү кирәк һәм зарури эш. Аның мәгълүматлары тел фәне өлкәләренә генә түгел, ә бәлки тарих, социология, культуралогия, биология, архитектура, экология, психология һ.б. фәннәр өчен дә кыйммәтле чыганак булып тора.

## 3.2. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы ойконимиясенең структур-ясалыш үзенчәлекләре

Ойконимнар үзләре урнашкан җирлектәге телдә сүз ясау законнарына нигезләнеп барлыкка киләләр. Шул ук вакытта ялгызлык исемнәре барлыкка килүдә сүз ясый торган чараларның бер өлеше генә кулланыла. Сүз ясау чаралары да, тарих белән бәйләнешле буларак, бер чорда еш кулланылсалар, икенчесендә телдән һәм язудан төшеп тә калырга мөмкин [Гарипова, 1994, б. 82]. Ойконимнарның ясалу чаралары һәм юллары һәр милли тел һәм охшаш телләр төркеменә керә торган телләр өчен уртак була. Ләкин шул ук вакытта аерым телләрнең үз үзенчәлекләре дә калку булып күренә ала.

Төрки телләрдә сүз ясалышы Э.В. Севортян, Н.А. Баскаков. П. Азимов, А.Г. Голямов, А.Ю. Базиев, Л.Н. Харитонов, Т.М. Гарипов, М.А. Хабичев, С.А. Джафаров һ.б.ның хезмәтләрендә яктыртыла. Татар теленә сүз ясалышы К. Насыйри, Г. Алпаров, Ш. Рамазанов, В. Хангильдин, Ф. Фәсиев, Д. Тумашева, Ф.А. Ганиев һ.б. тарафыннан өйрәнелгән.

Төрки топонимиядә төзелеш-ясалыш мәсьәләсенә кагылышлы классификацияләр байтак. Г.Ф. Саттаров, Г.Е. Корнилов, А.А. Камалов, Р.З. Шәкүров, А.А. Бонюхов, М.А. Булгарова, Ф.Г. Гарипова классификацияләре бар.

Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы ойконимнарын структур-ясалыш ягыннан тикшергәндә без аеруча Г.Ф. Саттаров һәм Ф.Г. Гарипова классификацияләренә таянып эш йөртәбез. Г.Ф. Саттаров татар теленең җирле географик термин-

нарын лексик-семантик, морфологик һәм синтаксик юл белән ясалган терминнарга аера. Ф.Г. Гарипова гидронимнарны ике зур төркемгә – гади һәм катлаулы атамаларга – бүлә.

### 3.2.1. Гади төзелешле ойконимнар

### Тамыр атамалар

Тамыр атамалар иң гади төзелешле атамаларга керәләр. Аларны бер, ике һәм өч иҗекле атамаларга аерып карарга мөмкин. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы татар атамалары арасында бер иҗеклеләр юк. Күпчелекне ике иҗекле атамалар алып тора. Өч иҗеклеләр азрак.

1) ике иҗектән торган тамыр ойконимнар: Азат, Кисы, Батыр, Тукай, Шәрбән – Аксубай районындагы авыллар; Шома, Сакон, Чишмә, Ялкын – Алексеев районындагы авыллар; Юксыл, Йолдыз, Чертуш – Яңа Чишмә районындагы авыллар; Гайтән, Кизләү, Үрнәк, Ака, Юган, Чишмә, Мамык, Тукай, Зүзәй, Чулпан – Норлат районындагы авыллар; Болгар, Каек, Вожи, Нәлет, Тукай, Ширбәт, Ярдәм, Йолдыз, Ирек, Үрнәк – Спас районындагы аыллар; Әмир, Лашман, Ясак, Тукай, Нагай – Чирмешән районындагы авыллар; Бахта, Мөслим, Ислэй, Чулпан – Чистай районындагы авыллар; Нократ – Әлки районындагы авыл.

2) өч иҗектән торган тамыр ойконимнар: Ромодан – Алексеев районы; Ялаур – Норлат районы; Балымәр – Спас районы; Бәркәтә, Күтәмә – Чирмешән районы. Моннан тыш ойконимик советизмнарга кергән Пионер, Культура, Октябрь (2) атамалары.

Гомумән алганда, Кама аръягы регионда 51 тамыр ойконим бар. Кайбер атамалар кабатлана: Тукай ойконимы өч тапкыр, Чишмә, Йолдыз, Үрнәк, Чулпан, Октябрь ойконимнары икешәр тапкыр.

### Ясалма төзелешле атамалар

Кушымчалар ярдәмендә сүз ясалышын морфологик юл белән сүз ясау, диләр. Телдәге сүзләрнең үсеш-үзгәрешләре электән яшәп килгән сүзләргә нигезләнеп яңа сүзләр ясалу хисабына була. Яңа сүзләр ясау телнең лексик составын

тулыландыра, баета. Башлыча, тамыр яки нигез сүзгә, түбәндәге кушымчалар кушылып, яңа барлыкка килгәннәр:

*-лы, -ле* кушымчасының: бер предметны икенчесенә билге итеп белдерү мәгънәсенә ия. Аның бу мәгънәсе каракалпак, кумык, азәрбайҗан телләрендә дә бар. *-лы*, *-ле* борынгы телдәге *-лыг*, *-лиг* кушымчасының фонетик үзгәреш кичерүе нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән. Исемгә *-лы*, *-ле* кушымчасы кушу юлы белән Аксубай районында Шомыртлы, Такталы, Сөлчәле атамалары, Алексеев районында Зирекле, Әлки районында Каргалы, Карамалы, Яңа Чишмә районында Зирекле, Норлат районында Киекле, Кычытканлы, Чияле, Ерыклы, Каргалы, Ишәле атамалары ясалган. Моннан тыш, бу кушылма катлаулы төзелеш тәшкил итүче атамалар составында да бар. Аларны икенче бүлекчәдә карап китәрбез.

*-мыш, -меш* кушымчасы хәзерге татар әдәби телендә сүз ясау өчен кулланылмый һәм шулай ук яңа атамалар да барлыкка китерми торган (нәтиҗәлелеген югалткан) кушымчалар рәтенә керә. Бу кушымча хәзерге көндә яңа сүз ясамый, бәлки сүзнең составында гына сакланган. *-мыш*, *-меш* кушымчасы хәзерге угыз телләрендә үткән заман сыйфат фигыль мәгънәсен бирә. Бу мәгънәсе аның кыпчак телләрендә дә булган [Гарипова, 1994, б. 86]. *-мыш*, *-меш* кушымчасы белән ясалган форма *-ган*, *-гән*, *-кан*, *-кән* кушымчасы мәгънәсен белдереп, сыйфат фигыль күрсәткече булып йөргән. Элек телебездә *-мыш*, *-меш* формалы фигыльләргә нигезләнеп байтак кына кеше исемнәре ясаганнар. Соңрак бу кеше исемнәре авыл исемнәренә күчеп сакланып калган. Кармыш (Карамыш) авылы Чирмешән районында урнашкан. Кармыш исеменең әүвәлге төзелеше *карамыш бала* яки *карамыш оглан* сүз тезмәсеннән гыйбарәт булган. Мондый сүзтезмәдә *-мыш* формасы фигыль үзе кергән исемнән алда килә, аергыч функциясен башкарып, предметның билгесен белдерә. Шушы грамматик билгеләре аның үткән заман сыйфат фигыль икәнлеген ачык күрсәтә. *-мыш* кушымчасы белән Норлат районында Кормыш атамасы да ясалган. -м*ыш*, *-меш* кушымчасының кыпчак альтернатив варианты *-ган*, *-гән*, *-кан*, *-кән* кушым-

часына беткән авыллар Татарстанның Көнбатыш Кама аръягында берәү дә очрамый.

*-лар, -ләр* кушымчасы күплекне белдерү өчен кулланыла. Бу суффикс белән ясалган атамалар казах, кыргыз, азәрбайҗан, Таулы Алтай төркиләре, башкорт телләрендә бар. Биләр – *би* (кенәз) + *ләр* (күплек кушымчасы) – хәзерге Алексеев районындагы татар-рус авылы. Шулай ук Байлар Сабасы.

*-га* юнәлеш килеш кушымчасы белән Аксубай районында Алга атамасы ясалган.

*-чы, -че* татар телендә сүз ясауда нәтиҗәле кулланылса да, географик атамалар барлыкка китерүдә актив түгел. Төрки халыклар яшәгән җирләрдә *-чы*, *-че* суффиксының кулланылыш дәрәҗәсе белән ясалган географик берәмлекләр күп очрамый, ягъни ул топонимнар ясауда продуктив түгел. Атамалар: Чирмешән районында – Яшәүче (*Яшәү + че*); Алексеев районында – Балахчино (*Балык + чы + ино*); Чистай районында – Уракчы.

*-кай, -кәй* кечерәйтү-иркәләү кушымчасы. Бу кушымча белән Норлат районында Салдакай, Алексеев районында Сабакайка исемле авыллар бар. *-кәй* кушымчасы борынгы кеше исемнәрен ясауда актив катнашкан: Йөзлекәй, Әлкәй һ. б.

Бу төрки-татар кушымчаларыннан тыш, байтак кына төрки-татар нигезле атамаларга рус кушымчалары кушылып та шактый ойконимнар ясалган.

*-ка* кечерәйтү кушымчасы белән Аксубай районында Ахматка, Тарханка, Котловка; Алексеев районында Сабакайка, Бутлеровка; Спас районында Аграмаковка, Бугровка, Тамкеевка, Чирмешән районында Казанка атамалары ясалган.

*-ино, -кино* кушымчалары белән Аксубай районында Илешкино, Уткино, Ерепкино, Алексеев районында Балахчино, Войкино, Ямкино, Норлат районында Илюткино, Якушкино; Спас районында Тамино ойконимнары ясалган.

*-ов, -ова, -ев* фамилия кушымчалары белән Аксубай районында Котловка; Алексеев районында Бутлеровка, Базяково; Әлки районында Садыков; Норлат районында Ахметово; Спас

районында Аграмаковка, Бугровка, Тамкеевка; Чистай районында Утяково атамалары ясалган.

*-иха* кушымчасы белән Алексеев районында Гоголиха авылы исеме бар.

*-ина* кушымчасы белән Норлат районында Октябрина ойконимы ясалган.

Гомумән алганда, Татарстанның Көнбатыш Кама аръягында сүз ясагыч кушымчалар белән генә ясалган 47 ойконим бар.

### 3.2.2. Катлаулы төзелешкә ия ойконимнар

Катлаулы төзелешле ойконимнарга (икенче төрле әйткәндә, синтаксик юл белән сүз ясалышына) кушма, парлы һәм тезмә ойконимнар керә. Ойконимнар нигездә ияртүче + ияртүче кисәкләр моделендә ясалганнар. Иярүче кисәк вазифасын исем, сыйфат, сан, рәвеш һ.б. сүз төркемнәре үти.

#### Кушма төзелешле авыл атамалары

Кушма һәм тезмә сүзләр ияртүле бәйләнешкә нигезләнгән сүзтезмәләрнең лексикалашуы нәтиҗәсендә барлыкка киләләр.

А) исемнең исемне янәшә тору чарасы аша ияртүеннән ясалган, изафә бәйләнешенең беренче тибына нигезләнгән атамалар: Мараса – *мора + са, су* («елга + елга»), Кыркүл – *кыр + күл* (Алексеев районы), Ташбилге – *таш + билге* (Әлки районы), Тубылгытау – *тубылгы + тау,* Сүлчәбаш – *Сүлчә + баш,* Шахмай – *шаһ + май* < Шаһмөхәммәттән (Яңа Чишмә), Норлат атамасы Нурдәүләт («нурлы дәүләт») дигән кеше исеменең фонетик үзгәреш кичерүе – икенче иҗекнең («дәү» нең) төшүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән, Чурабатыр – *чура + батыр,* Биккол – *бик* (бәк) + *кол* (Норлат районы), Чирмешән – *чирме + шән* («елга + елга», Чирмешән районы), Байтирәк – *бай + тирәк,* Яуширмә – *Яу + ширмә* (Чистай районы).

Ә) исемнең телгә янәшә тору һәм тартым кушымчасы аша иярүеннән ясалган, ягъни изафә бәйләнешнең икенче тибына нигезләнгән атама. Мондый атаманы без берне генә таптык, ул Норлат районындагы Бикүле атамасы. Бикүле – *би + күл + е.*

Б) ясалма сыйфат + исем. Чаллыбаш – *чал + лы + баш* (Яңа Чишмә районы). Карасу – *кара + су* (Аксубай районы), Каракүл – *кара + күл,* Суыксу – *суык + су* (Әлки районы), Акъяр – *ак + яр* (Яңа Чишмә районы), Каракүл – *кара + күл* (Норлат районы), Кызылъяр – *кызыл + яр,* Аккирей – *ак + гәрәй* (Чирмешән районы), Актау – *ак + тау,* Акбулат – *ак + булат* (Чистай районы).

В) «сан + ясалма сыйфат» моделеннән гыйбарәт ойконим: Дүртөйле – *дүрт + өй + ле* (Чистай районы).

Г) исем + фигыль моделеннән гыйбарәт ойконим. Ямьбакты – *ямь + бакты* (Спас районы). Категорик үткән заман хикәя фигыль формалы кеше исемнәренең төп моделен «исем + өченче зат берлек сандагы категорик үткән заман хикәя фигыль» төзелмәсе тәшкил итә: Туйкилде, Уразбакты, Байкилде, Дускилде, Алабирде, Ямьбакты һ.б.

Башлыча әлеге кеше исемнәрендә баланың дөньяга килүе, тууы һәм башка процесслар исем составындагы *килде, бакты, туды, калды, булды, бирде* һ.б. кебек III зат берлек санындагы категорик үткән заман хикәя фигыльләр урын алу юлы белән белдерелә. Бала туу, дөньяга килү процессының сөйләү максатыннан алда катгый рәвештә үтәлүе, тәмамлануы хәбәр ителә.

**Парлы сүздән торган ойконимнар**

Парлы сүзләр күпчелек очракта яңа лексик берәмлекләр тудырмыйлар, бәлки гамәлдәге сүзләрнең мәгънәләрен киңәйтәләр, җыелмалык, гомумиләштерү, көчәйтү һ.б. мәгънә төсмерләре өстиләр.

Татарстанның Көнбатыш Кама аръягында парлы сүзле ойконимнар күп түгел: барысы 8 атама. Мондагы ойконимнар төрле телләр белән кушылып беткәннәр. Без аларны ике төркемгә бүлеп карадык:

А) ике компоненты да төрки-татар теленә нисбәтле атамалар: Арбузов-Баран (Алексеев районы), Күлбай-Мораса, Тарн-Вар (Норлат районы), Нарат-Елга (Чистай районы).

Ә) бер компоненты – төрки-татар теленә, икенче компоненты рус теленә нисбәтле атамалар: Сидулово-Ерыклы (Аксубай

районы), Биляр-Озеро, Берлек-Михайловка (Норлат районы), Иж-Борискино (Спас районы).

**Тезмә сүздән гыйбарәт ойконимнар**

Ике яки берничә сүздән ияртүле тезмәләү (синтаксик ысул) белән ясалган атамалар тезмә сүз, тезмә термин дип йөртелә. Тезмә сүз һәм тезмә терминнар, исемләү-атау функциясе үти торган катлаулы лексик берәмлек буларак, бер-берсенә бик охшаш. Тезмә сүзләр – телдә күптәнге катлау, тезмә терминнар исә яңарак катлау булганга, әле лексик яктан тотрыкланып җитмәгәннәр, әмма тышкы күренешләре ничек кенә булмасын, тезмә сүз һәм тезмә терминнар,ербөтен предмет һәм төшенчәләрне атау максаты белән, башта ук катлаулы лексик берәмлек буларак төзеләләр һәм ирекле синтаксик сүз тезмәләреннән дә, тотрыклы фразеологик тәгъбирләрдән дә тамырыннан аерылалар [Саттаров, 1998, б. 346].

А) II төр изафә бәйләнешендәге ике исемнән торган тезмә терминнар (беренче компонент баш килештә, икенчесе тартым кушымчасы алган була): Татар Сөнчәлесе, Рус Кәрәмәте (Аксубай раоны), Рус Марасасы, Чуваш Майнасы, Урманасты Шонталасы, Мордва Болагы, Кыр Шонталасы (Алексеев районы), Рус Төгәлбәе, Татар Төгәлбәе, Татар Суыксуы, Анино Салманы, Рус Салманы, Абдул Салманы, Чуваш Шәпкесе, Бибай Чаллысы, Татар Әхмәте, Чуваш Кичүе, Татар Борнае, Чуваш Борнае (Әлки районы), Татар Утяшкиносы (Яңа Чишмә), Каравыл Тауы, Рус Мунчасы, Чуваш Мунчасы, Рус Тирмәннеге (Норлат районы), Татар Такталысы (Спас районы), Татар Гадельшасы, Рус Сарсазы, Мордва Баганалысы, Татар Баганалысы, Рус Ялтаны, Татар Ялтаны, Татар Талкышы, Керәшен Ялтаны, Чуваш Ялтаны (Чистай районы).

Ә) III төр изафә бәйләнешендәге ике сүздән (башлыча исемнән) торган тезмә терминнар. Бу төр тезмә терминнар «аергыч» (атрибутив кисәге + аерылмыш сүз) конструкциясеннән гыйбарәт булалар. Аергыч функциясендә башлыча исем, сыйфат, рәвеш килә. Кайсыбер атамаларның исем компоненты кушма сүз тәшкил итә яки сүз ясагыч кушымча ала.

1) ике сүздән торган ойконимнар: Яңа Үзи, Кәкре Күл, Кызыл Яр, Иске Мукшы, Яңа Ибрай, Яңа Дума, Яңа Кәрәмәт, Түбән Савруш, Иске Савруш, Иске Ибрай, Иске һәм Яңа Илдерәк, Кызыл Тау, Иске Кәрәмәт, Иске Үзи (Аксубай районы); Красный Баран, Кызыл Чишмә, Иске Муллино (Алексеев районы); Базарлы Матак, Югары Кәчи, Түбән Кәчи, Түбән Салман, Яңа Салман, Иске Камка, Иске Матак, Иске Салман, Түбән Сушка, Зур Алан, Югары Әлморза, Түбән Әлморза (Әлки районы); Яңа Чишмә, Яңа Авыл (Яңа Чишмә районы); Кызыл Юл, Яңа Әмзә, Иске Әмзә, Яңа Иглай, Якты Күл, Иске Иглай, Яңа Әхмәт, Кәкре Атау, Иске Авыл (Норлат районы); Иске Рәҗәп, Яңа Рәҗәп (Спас районы); Яңа Котыш, Иске Котыш, Югары Чыгтай, Түбән Чыгтай, Яңа Кади, Иске Кади, Якты Тау, Кече Чыгтай, Олы Талкыш, Кече Талкыш, Урта Талкыш, Яңа Урал, Иске Роман, Кызыл Болгар, Кызыл Ялан (Чистай районы); Югары Кондрата, Түбән Кондрата, Кызыл Чишмә (Алексеев районы);

2) өч сүздән торган ойконимнар: Зур Кызыл Яр (Алексеев районы), Иске Баллы Күл, Яңа Баллы Күл (Әлки районы).

3) икенче компоненты сүз ясагыч кушымча белән ясалган ойконимнар: Яңа Киезле, Иске Киезле, Кечкенә Сөнчәле (Аксубай районы); Зур Тигәнәле, Юеш Көрнәле, Кызыл Уракчы, Коры Көрнәле, Түбән Тигәнәле, Урта Тигәнәле (Алексеев районы); Яңа Ямкино, Иске Ямкино, Югары Әлки, Түбән Әлки, Урта Әлки, Яңа Такталы, Иске Такталы, Яңа Чаллы, Иске Чаллы (Әлки районы); Русская Чебоксарка, Чувашская Чебоксарка (Яңа Чишмә районы); Кечкенә Камышлы, Урта Камышлы, Түбән Чаллы, Урта Чаллы, Иске Чаллы (Норлат районы); Түбән Каменка, Югары Кармалка, Түбән Кармалка, Яңа Әлмәле, Иске Әлмәле, Урманасты Үтәмеш, Иске Үтәмеш (Чирмешән районы); Чирүле Шонталы (Чистай районы);

4) Икенче компоненты кушма сүз тәшкил иткән атамалар: Кече Аксубай, Яңа Аксубай (Аксубай районы); Түбән Биктимер, Югары Колчурино, Түбән Колчурино, Яңа Үргәагар, иске Үргәагар, Яңа Алпар (*алып* + *ар*), Иске Карата (*кара* + *та* (тау),

Урта Биктимер (Әлки районы); Югары Норлат (Норлат районы); Урманасты Йорткүл, Урта Йорткүл, Кырый Йорткүл (Спас районы).

Б) өч сүздән торган (сыйфат, рәвеш + исем + исем + тартым кушымчасы) катнаш атамалар: Яңа Чуваш Әдәмсуы, Иске Чуваш Әдәмсуы, Түбән Татар Майнасы, Яңа Татар Әдәмсуы, Иске Татар Әдәмсуы (Аксубай районы); Югары Татар Майнасы (Алексеев районы), Татар Мулла иле (Әлки районы); Иске Татар Әхмәте (Норлат районы).

Күреп үткәнебезчә, Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы ойконимнары арасында тезмә юл белән ясалганнары зур күпчелекне тәшкил итә. Без мондый ысул белән ясалган 164 ойконим санадык.

Шулай итеп, иң зур күпчелекне тезмә юл белән ясалган ойконимнар алып тора.

## ЙОМГАК

Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы, топонимика күзлегеннән караганда, гаять кызыклы һәм аз өйрәнелгән регион. Әлеге территориядә сигез районга караган 504 авыл бар, аларда 172 мең кеше яши. Безнең хезмәттә 300 ойконимга этимологик, лексик-семантик, төзелеш-структур яктан анализ ясалды. Моннан тыш, тагын 147 ойконим фактик материал буларак китерелде. Болары – рус атамалары. Без аларга тирән анализ ясамадык, кайбер урыннарда гына күрсәтеп үттек.

Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы ойконимнар системасы бик озак дәвер дәвамында катлаулы тарихи-географик һәм лингвистик шартларда формалашкан. Ул – Идел һәм Кама буенда яшәгән төрле халыкларның уртак хезмәт җимеше. Регион ойконимиясен тудыруда фин-угыр, борынгы төрки, татар, башкорт, чуваш, монгол һәм славян халыклары катнашкан.

Фәнни тикшеренүләр регион ойконимиясенең иң борынгы этнолингвистик катламын генезислары фин-угыр телләренә кайтып кала торган атамалар һәм җирле географик терминнар тәшкил итүен күрсәтә. Фин-угыр ойконимик катламы мари, мордва, коми кабиләләре һәм халыклары тарафыннан барлыкка китерелгән.

Регион ойконимнарының зур күпчелеге төрки-татар чыгышлы. Аларның күбесе борынгы гомумтөрки телдән үк килә һәм хәзерге төрки телләрнең барысында да диярлек урын ала торган лексик берәмлекләр булып санала. Төрки-татар ойконимнарын без борынгы төрки, татар, болгар, чуваш, башкорт катламнарына аерып карадык. Ойконимнарның күбесе борынгы төрки һәм татар телләренә нисбәтле.

Иң аз санлы катламнар – башкорт һәм монгол катламнары. Башкорт һәм монгол теленә караган ойконимнар катлам

алып тора дип әйтү бераз арттыру да хәтта, чөнки ике-өч ойконим гына тулы бер катлам хасил итүе шикле. Шулай да, ономастик традицияләргә ияреп, без аларны катлам дип атадык. Моннан монгол теленең татар теле формалашуда тәэсире бик аз булган, дип әйтә алабыз. Булган тәэсирләр дә күбрәк Алтай чоры белән бәйле. Һәрхәлдә монгол яуларыннан соң татар теленә, аерым алганда ойконимиясенә, монгол сүзләре бик аз кергән.

Нәкъ менә Көнбатыш җирләрендә Кама аръягы болгар бабаларыбыз Бөек Болгар дәүләтен төзеп җибәргәннәр. Ул чор турында да безгә ойконимнар кыйммәтле мәгълүматлар хәбәр итәләр. Кызганычка каршы, болгар теленә нисбәтле атамалар аз сакланган.

Славян катламы регион ойконимиясендәге иң югарыгы, ягъни иң яшь катламны тәшкил итә. Борынгы Болгар җирләренә русларны бик күпләп күчереп утырту була. Без моны рус хөкүмәтенең җирле халыкны ассимиляцияләштерергә, юкка чыгарырга омтылуы дип бәялибез. Бүгенге көндә рус теленә нисбәтле саналып йөргән атамаларның да күбесе (мәсәлән, Барское Енорускино, Бугровка, Гоголиха, Гайтанкино һ.б.) борынгы төрки телгә караганлыклары беленде.

Югарыда саналган статиграфик катламнар аерымланган халәттә яшәмиләр, киресенчә, күп катламлы һәм бер-берсе белән бик нык береккән, үзара керешкән, ифрат катлаулы этнолингвогенетик бәйләнешләре булган бербөтен система тәшкил итәләр.

Ифрат бай ойконимик материалны анализлаудан чыгып, регионда ике категория торак пункт атамалары бар, дигән төп нәтиҗәгә киләбез: болар онимик һәм апеллятив ясалышка ия ойконимнар. Беренче категориягә антропонимнарга, гидронимнарга, этнонимнарга нисбәтле ойконимнар керә. Икенче категориядә топонимик терминнар, фито- һәм зоотерминнар белән ясалган өй, йорт, авыл, тегермән, бүләк кебек торак пунктлар чагылдырган һәм каралты-кура терминнары белән ясалган ойконимнар урын алган.

Ислам дине белән бергә татар ойконимиясенә гарәп-фарсы сүзләре дә күп кергән. Ойконимнарның күпчелеге шәхси исемнәрдән һәм кушаматлардан ясалган. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы ойконимиясендә төрки һәм төрки булмаган чыгышлы этнонимнардан ясалган торак пункт атамалары да шактый. Табигатьнең җәмгыять тормышына зур йогынтысы турында топонимнардан ясалган ойконимнар сөйли.

Торак пункт атамаларын ясауда беренчелекне антропонимнарга бирергә кирәк (Биктимер, Татар Гаделшасы, Алпар һ.б.).

Лексик-семантик анализ ойконимнарда балымәр, кәчи, юган кебек онытылган һәм татар, рус, чуваш, мордва кебек бүгенге көндә дә кулланыла торган этнонимнар барлыгын күрсәтте. Шактый зур бүлекне гидронимнардан ясалган ойконимнар тәшкил итә. Халыкның специфик үзенчәлеге булып су чыганаклары буена урнашу тора. Бу факт су объектларының халык тормышында зур урын тотуын күрсәтә. Мондый ойконимнар борынгырак, елгалар үзләре дә торак пункларга караганда күпкә борынгырак.

Ойконимнарның табигать белән тыгыз бәйләнеше фито- һәм зооойконимнарда да чагылыш таба. Бу атамалар безгә борынгы бабаларыбызның урманнар, елгалар, күлләр белән уратып алынган гаҗәеп матур урыннарда яшәү урыны сайлаганлыкларын күрсәтә.

Лексик-семантик тикшерүләр барлык географик атамаларның да теге яки бу дәрәҗәдә тарихи сәбәпләрдән туганлыгын күрсәтә. Лингвистик һәм экстралингвистик факторлар атау өчен мотив булып торалар. Төзелеш-структур анализ ойконимнар ясалуның чыганаклары турында нәтиҗәләр ясарга, аларның структур типларын күрсәтергә мөмкинлек бирә. Атамаларны без гади һәм катлаулы төзелешлеләргә бүлеп карадык. Гади төзелешле атамалар тамыр һәм ясалма, аффикслы һәм аффикссызларга бүленә. Гади ойконимнар ясалышында сүз ясаучы кушымчалардан *-лы/-ле, -мыш/-меш, -чы/-че, -ов/-ова/-ев* кушымчалары шактый продуктив.

Катлаулы төзелешле ойконимнар ясалышында исем, сыйфат, сан, рәвеш, фигыль сүз төркемнәре катнашкан. Без аларны кушма, парлы һәм тезмә төзелешле ойконимнарга бүлеп карадык.

Гомуми нәтиҗә ясап, шуларны әйтергә кирәк: Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы ойконимнарының формалашу процессы борынгы чорлардан ук башланган. Бу процесста төрле төрки һәм төрки булмаган халыклар катнашкан. Бүгенге көндә регионның төп халкын татарлар тәшкил итә.

Көнбатыш диалектның ойконимнарга тәэсире зур түгел. Без моны торак пункт атамаларының борынгылыгы һәм тотрыклылыгы белән аңлатабыз. Мишәр диалекты йогынтысы Абдул Салманы, Ислай, Иглай, Рус һәм Чуваш Тирмәннеге (Тегермән) кебек ойконимнарда гына чагыла.

## КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

Абдрахманов А.А. К вопросу о методах этимологического исследования топонимов Казахстана // Тюркская ономастика. Алма-Ата, 1984.

Административно-территориальное деление Республики Татарстан. Казань: Барс, 1992.

Алишев С.Х. Исторические судйбы народов среднего Поволжья. М., 1990.

Алишев С.Х. Бай тарихлы авыллар // Татар календаре. Казан, 1993.

Алишина Х.Ч. Историко-лингвистическое исследование ономастикона сибирских татар (на материале Тюменской области): автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Казань, 1999.

Антонов Н.К. Материалы по исторической лексике якутского языка. Якутск, 1971.

Артемьев А.И. Древний болгарский город Жукотин. СПб., 1851.

Археологическая карта ТАССР. Ч.1. Западное Закамье. Казань, 1986.

Атаниязов С. Толковый словарь географических названий Туркменистана. Ашхабад, 1980.

Ахатова З.Ф. Топонимия Нижнего Прикамья Татарстана: автореф. дис. ... канд. филол. наук / АН РТ. Казань, 1994.

Ахметгалиева Я.С. Исследования тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы». М., 1979.

Ахметьянов Р.Г. К происхождению топонима Урал/Оно-мастика Татарии. Казань: ИЯЛИ им Г.Ибрагимова, 1989.

Ахунзянов Э.М. Общее языкознание. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1981.

Ашмарин Н.И. Болгары и чуваши. Казань, 1902.

Ашмарин Н.И. Словарь чувашского языка. Вып. VI–VII. Чебоксары, 1934, 1935.

Әхәтов Г.Х. Татар диалектологиясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

Барашков В.Ф. Монголизмы в топонимии Среднего Поволжья // Ономастика Поволжья. Сб. 3. Уфа: БФАН СССР, 1973.

Бартольд В.В. Сочинения. Т. 1–9. М.: Наука, 1963–1977.

Баскаков Н.А. Тюркские языки (Общие сведения и типологическая характеристика.) Тюркские языки // Языки народов СССР. Т. 2. М.: Наука, 1966.

Баскаков Н.А. Географическая номенклатура Горного Алтая // Топонимика Востока. Л.: Наука, 1969.

Баскаков Н.А. Принципы избирательности наименования гор у алтайцев Горного Алтая // Оронимика. М.: Наука, 1969.

Баскаков Н.А. Русские фамилии тюркского происхождения. М.: Наука, 1979.

Боровков А.К. Лексика среднеазиатского тэфсира XII–XIII вв. М.: Изд-во вост. лит., 1963.

Борһанова Н.Б. Татар телендә авылы төзелешенә караган лексик-семантик төркемнәр // Исследования по диалектологии и истории татарского языка. Казан, 1982.

Будагов Л.З. Сравнительный словарь турецко-татарских наречий. Т. 1, СПб., 1869.

Булгарова М.А. Ногайская топонимия. Ставрополь, 1999.

Бушуева Е.Н. Словарь географических терминов и других слов, встречающихся в топонимии Азербайджана. М.: Наука, 1971.

Вендина Т.И. Гидронимы фитонического и зоономического происхождения // Топонимика. Вып. 5. М.:Наука, 1971.

Владимирцев В.Я. Общественный строй монголов. Л., 1934.

Волков В.И. Край родимый Аксубай.Казань: Таткнигоиздат, 1993.

Ганиев Ф.А. Суффиксальное словообразование в современном татарском литературном языке. Казань: Таткнигоиздат, 1974.

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. Казан, 1965.

Гарипова Ф.Г. Татарстан гидронимнары сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., Т.1-2, 1984–1990.

Гарипова ФГ. Борынгы Болгар шәһәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.

Гарипова Ф.Г. Елгалар дөньясына сәяхәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.

Гарипова Ф.Г. Татарстан микротопонимнары сүзлеге. 2 нче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.

Гарипова Ф.Г. Исемнәрдә ил тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.

Гарипова Ф.Г. Авылларны сөям җаным-тәнем белән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.

Гарипова Ф.Г. Инешләрдән иңгән моңнар бар. Казан, 1995.

Гарипова Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.

Гордеев Ф.И. Балтийские и иранские заимствования в марийском языке // Происхождение марийского народа. Йошкар-Ола, 1967.

Губаева С.С. Одна из особенностей тюркской топонимии // Диалекты и топонимия Поволжья. Вып.1. Чебоксары, 1972.

Гусейнзаде А.А. К этимологии топонима Ku§gu // Советская тюркология. 1971. № 6.

Гусейнзаде А.А. Доогузские топонимы Кавказа // Вопросы географии. М.: Мысль, 1979. Вып. 110: Топонимика на службе географии.

Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан, 1999.

Дерфер Г. О некоторых спорных вопросах реконструкции фонологической системы тюркского праязыка // Тюркские исследования. М., 1976.

Дмитриев Н.К. Строй тюркских языков. М., 1962.

Добродонов И.Г. Оскол // Русская речь. 1986, № 3.

Донидзе Г.И. Гидронимические термины в тюркских языках // Ономастика. М.:Наука, 1969.

ДТС – Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969.

Егоров В.Г. Этимологический словарь чувашского языка. Чебоксары, 1964.

Еремия А.И. Географические названия рассказывают. Кишинев, 1982.

Жаримбетов А. Тюркизмы в названиях растений: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1976.

Закиев М.З. Татары: проблемы языка и истории. Казань: АН РТ, 1993.

Закирова Г.К. Историко-лингвистический анализ ойконимии Казанского ханства: дис. ... канд. фил. наук. Казань, 1998.

Зәкиев М.З. Татар халкы теленең барлыкка килүе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977.

Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле синтаксисы һәм пунктуациясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

Зәкиев М.З. Төрки-татар этногенезы. Казан: Фикер, 1998.

Золотницкий Н.И. Заметка о названиях Булгар, Биляр и Моркваши. Казань, 1884.

Износков И.А. Список населенных мест Казанского уезда с кратким их описанием. Казань, 1885.

Изысканный дар тюркскому языку (Грамматический трактат XIV в. на арабском языке). Ташкент, 1978.

Инжеватов И.К. Этимология мордовских топонимов и гидронимов с компонентом *сар* // Ономастика Поволжья. Саранск, 1974. Вып. 4.

Ишмухаметов Г. Төрки, фарсы, гарәп һәм казахча, татарча, русча сүзлек. Казан, 1954.

Кадралиева К.Я. Историко-лингвистические особенности формирования и развития ойконимии Заказанья ТАССР // Ономастика Татарстана. Казань, 1989.

Казаринов В. О мишарях в Чистопольском уезде Казанской губернии. Казань, 1884.

Кайдаров А.Т. Способы выражения топонимических представлений и понятий у казахов // I Всесоюз. конф. по тюркской ономастике. Фрунзе, 1986.

Камалов А.А. Гидронимия Башкири: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 1969.

Камалов А.А. Некоторые вопросы изучения топонимии Башкирии // Ономастика Поволжья. 3. Уфа, 1973.

Камалов А.А. Башкирская топонимия. Уфа, 1994.

Камалов А.А. Башкирские географические термины и топонимия. Уфа, 1997.

Киекбаев Д.Г. Личные формы глаголов в урало-алтайских языках // Вопросы башкирского языкознания.–Уфа, 1973.

Клоусон Дж. Лексико-статистическая оценка алтайской теории // Вопросы языкознания. 1969. № 5.

Ковалевский А.П. Книга Ахмеда ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Харьков, 1956.

Койчубаев Е. Нецветовая сущность топонимических компонентов *ак, кара, кок, соры* // Всесоюзная конференция по топонимике СССР. Л., 1965.

Койчубаев Е. Краткий толковый словарь топонимов Казахстана. Алма-Ата, 1974.

Конкашпаев Г.К. Цветовые слова в тюркских топонимах// Географические науки. Алма-Ата, 1969.

Кононов А.Н. О семантике слов *кара* и *ак* в тюркской географической терминологии // Изв. отд. общ-х наук АН Тадж.ССР. Вып. 5. Сталинабад, 1954.

Кочин Е.Г. Материалы для терминологического словаря Древней России. М.-Л., 1937.

Куряева Р.И. Русская ойконимия среднего Поволжья тюркского происхождения: дис. ... канд. фил. наук. Казань: КГУ, 1990.

Лезина И.Н., Суперанская А.В. Ономастика: словарь-справочник тюркских родо-племенных названий. М., 1994.

Лыткин В.И., Гуляев Е.С. Краткий этимологический словарь коми языка. М.: Наука, 1970.

Магницкий В.К. Чувашские языческие имена. Казань, 1905.

Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности. М.-Л., 1951.

Малов С.Е. Енисейская письменность тюрков. М.-Л., 1952.

Марийско-русский словарь. М.: Гос. изд-во иностранных и национальных словарей, 1956.

Матвеев А.К. Взаимодействие языков и методы топонимических исследований // Вопросы языкознания. 1972. № 3.

Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан, 1910.

Мокшанско-русский словарь. М., 1949.

Молчанова О.Т. Географический термин булак в топонимии// Ономастика Поволжья, № 4, Саранск, 1976.

Молчанова О.Т. Топонимический словарь Горного Алтая. Горно-Алтайск, 1979.

Молчанова О.Т. Прилагательные семантических полей «черный цвет» и «белый цвет» в ономастиконе алтайцев // Советская тюркология. 1985. № 3.

Мурзаевы Э. и В. Словарь местных географических терминов. М., 1959.

Мурзаев Э.М. Топонимика и география // Вестник МГУ, 1968. № 3.

Мурзаев Э.М. Словарь народных географических терминов. М.: Мысль, 1984.

Мурзаев Э.М. Тюркские географические названия. М.: Вост. литература, 1996.

Нестеров В.А. Происхождение топонимов Чебоксары и Шобашкар // Ономастика Поволжья. 4. Саранск, 1976.

Нестеров В.А. Над картой Чувашии. Историко-топонимические заметки. Чебоксары, 1980.

Никонов В.А. Краткий топонимический словарь. М., 1966.

Никонов Н.А. Имя и общество. М.: Наука, 1974.

Нуруллин И. Тукай. М.: Молодая гвардия, 1977.

Орлов А.М. Мещера, мещеряки, мешаре. Казань, 1992.

Остроумов Н. Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещеных татар Казанской губернии. Казань, 1876.

Подольская Н.В., Суперанская А.В. Терминология ономастики // Вопросы языкознания. 1969. № 4.

Полное собрание русских летописей. СПб., 1896.

Полный иллюстрированный словарь иностранных слов / сост. Н. Вайсблит. М.-Л., 1936.

Пономарев П.А. Булгарский город Кашан. Казань, 1883.

Попов А.И. Следы времен минувших. Л., 1981.

Поспелов Е.М. Оронимика СССР: состояние и проблемы // Оронимика. М., 1969.

Прманова Н.А. Историко-лингвистический анализ тюркской ойконимии Кызылординской области Казахстана: автореф.дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1997.

Радлов В.В. Опыт словаря тюркских наречий. СПб., 1893. Т. 1.

Радлов В.В. Опыт словаря тюркских наречий. СПб., 1899. Т. 2.

Радлов В.В. Опыт словаря тюркских наречий. СПб., 1905. Т. 3.

Радлов В.В. Опыт словаря тюркских наречий. СПб., 1911. Т. 4.

Розен М.Ф. Словарь географических терминов Западной Сибири. Л., 1970.

Саттаров Г.Ф. Татарстан АССРның микротопонимиясе. Казан: КДУ, 1965.

Саттаров Г.Ф. Этапы развития и очередные задачи татарской ономастики. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1970.

Саттаров Г.Ф. Категория ласкательных в татарских личных именах // Антропонимика. М.: Наука, 1970.

Саттаров Г.Ф. Антропонимика. М.: Наука, 1970.

Саттаров Г.Ф. Ни өчен шулай аталган? Казан: Татар. кит. нәшр., 1971.

Саттаров Г.Ф. Татарстан ономастикасында *ак* һәм *кара* сүзләре // Татар тел белеме мәсьәләләре. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1972. V китап.

Саттаров Г.Ф. Татарстан АССРның антропотопонимнары. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1973.

Саттаров Г.Ф. К этимологии топонима Набережные Челны // Советская тюркология. 1974. № 3.

Саттаров Г.Ф. Этнонимы в топонимии и антропонимии Татарии // Исследования по татарскому яззыку. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977.

Саттаров Г.Ф. Названия населенных пунктов в Татарии, производные от древних тюрко-татарских личных имен // Советская тюркология. 1979. № 2.

Саттаров Г.Ф. Этнотопонимы Татарии // Советская тюркология. 1980, № 1.

Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.

Саттаров Г.Ф. Мәктәптә туган як ономастикасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

Саттаров Г.Ф. Булгарский пласт топонимии и антропонимии казанских татар // Ономастика Татарстана. Казань, 1989.

Саттаров Г.Ф. Башкиризмы в топонимии Татарии // Советская тюркология. 1989, № 3.

Саттаров Г.Ф. Исемең матур, кемнәр куйган? Казан, 1989.

Саттаров Г.Ф. Атамалар дөньясына сәяхәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.

Саттаров Г.Ф. Ономастика һәм энциклопедия // Казан утлары. 1995. № 1.

Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре ни сөйли? Казан: Раннур, 1998.

Саттаров Г.Ф. Татар топонимиясе. Казан, 1998.

Сборник материалов по истории Казанского края. – Казань, 1908, № 7, 36.

Севортян Э.В. Этимологический словарь тюркских языков. Т. 1. М.: Наука, 1974.

Скворцов М.И. Этнические названия в чувашской топонимике и антропотопонимике // Диалекты и топонимия Поволжья. Вып. 5. 1977.

Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951.

Список населенных мест по сведениям 1859 г. XXXVI. Самарская губерния / Обработан А.Аригальевым. СПб., 1866. № 3327.

Список населенных мест Пермской области: Екатерининский уезд. Пермь, 1908. № 163.

Список селений Казанской провинции за 1771–1773 гг. с подразделением провинции на даруги и «Ведомость о наместничестве Казанском, составляющемся в тринадцати уездах 1780–1783 гг.» // Сб. материалов по истории Казанского края в XVIII в. / под ред. Д.А. Корсанова. Казань, 1908. № 56.

Список с писцовой и межевой книги г. Свияжска и уезда Н.В. Борисова и Д.А. Кикина 1565–1567 гг. Казань, 1909.

Срезневский И.И. Материалы для словаря древнерусского языка. СПб., 1893–1903.

СТБ. Словарь топонимов Башкирской АССР. Уфа, 1980.

Субаева Р.Х. О названиях рек и озер Среднего Поволжья // Известия Казанского филиала АН СССР / Серия энергетики и водного хозяйства. Вып. 3. 1961.

Тайсин Ә.С., Хуҗиев Р.Г. Татарстан географиясе. Казан. 1995.

Татарстан АССР тарихы. Казан, 1970.

Татарча-русча сүзлек. М., 1966.

Татарская грамматика. 2 т. Морфология. Казань, 1993.

Татарская грамматика. 3 т. Синтаксис. Казань, 1992.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. Казан, 1977, 1979, 1981.

Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан, 1969.

Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан, 1993.

Татищев В.Н. Лексикон Российский, исторический, географический, политический и гражданский. СПб., 1793.

Титова А.С. Словарь транскрипции терминов и слов, часто встречающихся в географических названиях Казахской ССР. М., 1960.

Сравнительный словарь тунгусо-маньчжурских языков. Т. 1, 1975.

Трубе Л.Л. Личные мордовские имена в топонимии Горьковской области и некоторые вопросы формирования ее населения // Ономастика Поволжья. Вып. 3, Уфа, 1973.

Тюменцева Л.А. Антропонимы Астраханской области // Антропонимика. М., 1970. С. 309–311.

Ушаков Д.Н. Толковый словарь русского языка. М.: Гос. изд-во иностранных и национальных словарей. 1938–1966, Т. 1–4.

Фасмер М.Р. Этимологический словарь русского языка. М., 1964. Т. 1.

Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. Казань, 1975.

Фәсиев Ф.С. XVIII гасырда иске татар телендәге эш кәгазьләре. Казан, 1981.

Фәхретдинов Р.Г. Татар халкы һәм Татарстан тарихы. Казан, 1996.

Хакимзянов Ф.С. Язык эпитафий волжских булгар. М., 1978.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле тарихы буенча очерклар. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1965.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле тарихы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993.

Халиков А.Х. Происхождение татар Поволжья и Приуралья. Казань: Таткнигоиздат, 1978.

Хвольсон Д.А. Известия о хазарах, буртасах, болгарах, мадьярах, словенах и руссах Абу Али-Ахелда Бен-Омар ибн-Даста. СПб., 1869.

Хисаметдин бине Шәрәфетдин Мөслими. Тәварихы Болгария. Казан, 1870.

Хисамова Ф.М. XVIII гасырдагы татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1981.

Цогаева А.Дз. Топонимия Северной Осетии. Орджоникидзе, 1971.

Чувашско-русский словарь. М.: Гос. изд-во иностранных и национальных словарей, 1961.

Шакуров Р.З. Топонимия бассейна реки Демы: дис. ... канд. филол. наук. М., 1973.

Шанский Н.М. Этимологический словарь русского языка. Т. 1. Вып. 2. М: Изд-во Московск. ун-та, 1965.

Шипова Е.Н. Словарь тюркизмов в русском языке. Алма-Ата, 1976.

Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. Казань, 1877.

Энциклопедический словарь. М: Советская энциклопедия, 1963. Т. 3.

Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.-Л., 1960.

Юсупов Г.В. Булгаро-татарская эпиграфика и топонимика как источник исследования этногенеза казанских татар. Казань, 1971.

Абдул Салманы – гарәп-төрки. Абдул – гарәп телендәге Габдулла исеменең диалекталь формасы. Габдулла исә «Аллаһ колы» дигәнне аңлата. *Салман* элементы антропонимга нисбәтле. Төзелеше буенча *сал* «таза, нык, батыр» һәм *ман* (мән ~ мин) – «кеше» компонентларыннан тора.

Авыл (Яңа) – борынгы төрки-татар. Борынгы төрки телдәге *агыл* (загон для скота) сүзенә мөнәсәбәтле.

Аграмаковка – борынгы төрки. *Аграмак = аргамак.* Чабыш атын аңлата. Метатеза күренеше.

Азат – фарсы. Азат, ирек хөр мәгънәләрен аңлата.

Азеево – татар-чуваш. Татар диалектларында очрый торган *әзи* (старший брат) сүзенә нисбәтле.

Ака – чуваш. Атама чуваш телендәге *ака* (страший брат) сүзенә мөнәсәбәтле.

Акбулат – борынгы төрки. *Ак + булат* – антропоним. Булат – кеше исеме, шул ук вакытта корычның төрен, кылычны аңлата.

Аксубай – борынгы төрки. *Ак + субай/сыбай. Сыбай* сүзе борынгы төрки телдә атлы сугышчыны аңлаткан.

Актау – борынгы төрки-татар. *Ак + тау* – бела гора.

Акташ – борынгы төрки-татар. *Ак + таш* – белый камень.

Акъяр – борынгы төрки-татар. *Ак + яр* – белая скала.

Алан (Зур, Кече) – борынгы төрки-татар. Урман эчендәге агачлар үсмәгән буш урынны аңлата.

Алкин (Татар Алкины) – чуваш. Чуваш кеше исеменә нисбәтле.

Алпар – борынгы төрки. *Алып + ар.* Пәһлевәндәй гәүдәле, батыр ир. Антропонимга нисбәтле.

Апак – борынгы төрки. Антропонимнан ясалган. *Аппак* – чиста, *пак* сүзеннән.

Арбузов-Баран. Арбузов – фарсы. Атама фарсы телендәге Карбуза (ишәк кыяры) сүзенә мөнәсәбәтле. Баран – болгар. Атама

болгар кабиләсе исеме бәрәнҗәргә нисбәтле (Николаев Баран, Кызыл Баран).

Ахматка – гарәп. Гарәп телендәге Әхмәт антропонимына нисбәтле. «Иң данлыклы иң мактаулы» дигәнне аңлата.

Ахметовка – кара: Ахматка.

Әдәмсу... – гарәп-төрки. Әдәмсу елгасы исеменнән алынган. Гарәп телендә Әдәм «человек, люди» мәгънәсен бирә һәм кеше исеме булып йөри.

Әлки (Югары, Түбән, Урта) – борынгы төрки. Әлки авылларының атамасы Әлкәй дигән борынгы кеше исеменә нисбәтле.

Әлмәт – гарәп. Ойконим Әлмөхәммәт дигән кеше исемен кыскарту, аның икенче һәм өченче иҗеген ташлап, беренче һәм дүртенче иҗекне янәшә әйтү нәтиҗәсендә барлыкка килгән.

Әлморза – фарсы. *Әл* һәм *морза* элементларыннан тора. Әлморза исеме «бөек, данлыклы морза» дигәнне аңлата. Морза титулы гарәп телендәге *әмир* һәм фарсы телендәге *задә* сүзләрен кушып ясалган.

Әмир – гарәп. *Әмир* сүзе гарәпчә «хәрби начальник, идарә итүче» мәгънәләрен аңлатучы титул.

Әшнәк (Олы, Кече) – борынгы төрки. Ашина этнонимына нисбәтле.

Баганалысы (Татар Баганалысы) – гомумтөрки атама. Авыл буласы урынга бер кеше килеп багана утырткан, авыл исеме шуннан калган.

Багалинский – чуваш. Мәҗүси чуваш Багай исеменә нисбәтле.

Базарлы Матак – фарсы, чуваш. Фарсы телендә *базар* сүзе «сәүдә итү көне, базар, бәйрәм көн» төшенчәсен белдерә. Гомумтатар телендәге *базар* «сәүдә итү урыны һәм корылмалары» мәгънәсен бирә. *Матак* элементы чуваш телендә ир кеше исеме һәм аның кушаматы булып йөргән.

Базякова – чуваш. Мәҗүси чуваш Базяк исеменә нисбәтле.

Байтирәк – борынгы төрки. Антропонимга нигезләнгән. Байтирәк борынгы төркиләрдә изге агач, ыру символы саналган.

Балохчино – борынгы төрки. Ойконимның нигезендә Балохчин дигән кеше фамилиясе ята. Фамилия борынгы төрки Балукчы исеменнән ясалган.

Баллы Күл (Иске, Яңа) – борынгы төрки. Күл исеменнән алынган. Күл, үз чиратында, аның янында агачтагы умарта оясыннан бал ташып торганга шулай аталган.

Барское Енорускино – борынгы төрки. Барское – барин – боярин – бояр – *бай+ ар* = бай кеше. Енорус – Енарас – Януразз. *Яңа + ураз* (бәхет) сүзләреннән ясалган.

Батыр – борынгы төрки. Борынгы төрки сүзлектә *бахты* сүзе «бәхет» мәгънәсендә күрсәтелгән [ДТС, 1969, с. 98].

Батбай Чаллысы – борынгы төрки, болгар. Би + бай. Ике сыйнфый катлам титулы бергә килеп исем ясалган. Чаллы (Иске, Яңа, Урта, Түбән) болгар телендә *чал/чул* сүзе «таш» төшенчәсен белдергән. Чаллы «ташлы» дигәнне аңлата. Атама, гадәттә, төбе ташлы булган елгаларга бирелгән.

Биккол – борынгы төрки. Бинең, бәкнең колы.

Биктимер (Түбән, Урта) – борынгы төрки. Борынгы төрки кеше исеме. *Бик + тимер.*

Бикүле – борынгы төрки. *Би + күле.* Бинең, бәкнең күле.

Биләр – борынгы төрки. Биләр шәһәре, анда күп биләр (бәкләр) яшәгән шәһәр, ягъни башкала.

Болгар – болгар. «Булуг» ар – булган ир, булган кеше, булган халык мәгънәсен аңлата.

Болымер – болгар. Атаманы Идел болгарлары составына кергән Болымәр/ Бүләмәр кабиләсе теленә нисбәтлибез.

Борнай (Татар, Чуваш) – татар. Борнай дигән шәхес яки нәсел кушаматына нисбәтле рәвештә барлыкка килгән.

Борнаш – татар. Борнашның этимологиясе *борын* сүзенә нисбәтле.

Бугровка – борынгы төрки. Борынгы төрки телдә *букри/бөкре* (горбатый).

Булдирь – борынгы төрки, татар. Татар телендәге *булдыр* дигән боерык фигыленә мөнәсәбәтле.

Вожи – коми. *Вож* сүзе коми телендә елга кушылдыгы мәгънәсен бирә.

Гадельша (Татар Гадельшасы) – гарәп-фарсы. *Гадел* сүзе гарәп телендә турылыклы, гадел мәгънәсен бирә *Шаh* сүзе фарсы теленнән кергән һәм шаh, патша мәгънәсен аңлата. Ике сүзне бергә кушып Гадельшаh (справедливый правитель) исеме ясалган.

Гайтанкино – татар. Татар телендә *гәйтән* (шурок) сүзе бар.

Гоголиха – борынгы төрки. *Когул-когол-гогол*. Күгәрчен сүзеннән ясалган.

Ерыклы – башкорт. Ерыклы – Зирекле атамасының башкортча варианты.

Зирекле – татар. Агач исеменә нисбәтле.

Ибрай (Яңа, Иске) – гарәп-яһүд. Ибрай – Ибраһим исеменең диалекталь варианты.

Иглай – гарәп. Игълян (игълан) сүзенә мөнәсәбәтле.

Илюткино – борынгы төрки. Борынгы төрки телдә илләт.

Ирек – татар. Татар телендә *ирек* сүзенең «азатлык, бәйсезлек» мәгънәләре бар.

Ислай – гарәп. Ислай гарәп телендәге *ислам* сүзеннән ясалган.

Ишәле – татар. Татар телендәге *ишәй* фигыленнән ясалган.

Йолдыз – борынгы төрки, татар. Борынгы телдә – *йулдуз* (звезда).

Йорткүл (Урманасты, Урта, Кырый) – борынгы төрки. *Йорт* + *күл.*

Кади – гарәп. Антропонимга нисбәтле. Гарәп телендәге *кадый* (судья) сүзенә мөнәсәбәтле.

Каек – борынгы төрки. Борынгы төрки телдә дә *каек, Qajriq* сүзе бүгенге көндәге мәгънәсендә йөргән (көймә, рус. лодка).

Казанка – борынгы төрки. Гидронимга мөнәсәбәтле.

Камка (Иске) – борынгы төрки. Бөҗәк исеме (божья коровка) белән ясалган.

Камкино (Новая) – борынгы төрки. Борынгы төрки телдәге *кам* (шаман) сүзенә нисбәтле.

Камышлы (Кечкенә, Урта) – борынгы төрки. *Камыш* сүзенә *-лы* ясагыч кушымчасы кушылып ясалган. Су буенда үсә торган үсемлек исеменнән.

Каравыл Тауы – борынгы төрки. Тау өстенә салынган кальга-крепостьны аңлата.

Каракүл – борынгы төрки. *Кара* + *күл* – «черное озеро».

Карамалы – татар. Карама – элпәсыманнар семьялыгыннан киң ябалдашлы агач.

Караса – борынгы төрки. *Кара* + *са* (су) – «черная вода».

Карасу – борынгы төрки. *Кара* + *су.*

Карата – борынгы төрки. *Кара* + *та* (тау) – «черная гора».

Каратаевка – төрки. Мордваларда этноним буларак кулланылышта йөргән.

Каратай – борынгы төрки. *Кара тай* (елга) – «черная река».

Каргалы – башкорт. *Карга* дигән башкорт этнонимына нисбәтле.

Кармыш – борынгы төрки. Карамыш (Карамыш бала) антропонимына нисбәтле.

Кашанова – борынгы төрки. Антропонимнан ясалган. Борынгы төрки *кош* сүзенә нисбәтле.

Кәкре Күл – татар. Атаманың беренче компоненты *кәкре* татар телендә «туры, төз булмаган, бөгелгән яки кәкерәйтелгән» дигән мәгънәне аңлата.

Кәрәмәт (Иске, Яңа) – чуваш. *Кәрәмәт ~ кирәмәт* – чувашларның иң яраткан табыну объекты.

Кәчи (Югары, Түбән) – борынгы төрки. Атама төркиләрдәге этнонимга нисбәтле.

Киекле – борынгы төрки. *Киек* (кыргый хайван) + *ле.*

Кирпичное – борынгы төрки. Авыл атамасы татар телендәге *кирпеч* сүзеннән ясалган. Төзелеш материалын аңлата.

Колчура (Түбән, Югары) – борынгы төрки. *Кол + чура* (кол, кара халык).

Кормыш – борынгы төрки. *Кор + мыш* = корган.

Котловка, Котыш, Кутлушкино атамалары борынгы төрки телдәге *кот* сүзенә нисбәтле.

Кулаковка (Большая, Малая) – борынгы төрки. Борынгы төрки, татар *кул* «рука)» сүзенә нисбәтле.

Кураново – борынгы төрки. Куранов фамилиясеннән ясалган. Татар телендә Куран дигән кеше исеме дә булган.

Күлбай-Мораса – төрки-татар атамасы. *Кол + бай* титуллары кушылып ясалган.

Күтәмә – төрки. «Ала балык, форель» дигәнне аңлата.

Кызыл Уракчы – борынгы төрки. *Уракчы* сүзе борынгы төрки телдә *orjak* (арт). *Кызыл* сүзе совет символикасын аңлата.

Кыркүл – борынгы төрки. *Кыр + күл* «степное озеро».

Кычытканлы – төрки-татар. Борынгы төрки телдәге *kici, kicit* сүзенә барып тоташа.

Лашман – татар. XVII–XVIII гасырларда хәрби корабльләр төзү өчен казна урманнарында агач кисү һәм аны мул сулы елга буйларына тарттыру хезмәте белән шөгыльләнгән дәүләт крестьяннарын «лашман» дип атаганнар.

Мамык – татар. Физик яки рухи яктан бик йомшак булган кешегә мамык кушаматы тагылган. Мамык кушаматын йөрткән аерым шәхес яки нәсел-токым эшчәнлеге аша бу кушамат Мамык авылы атамасына әверелгән.

Миләүшә – гарәп-фарсы. Мәүлишаһ исеменә нисбәтле. Миләүшә исеме Мәүлешаһның диалекталь формасы. Атама гарәп телендәге *мәүлә* һәм фарсы телендәге *шаһ* сүзләрен кушып ясалган.

Мордва Булагы – мордва-төрки. Жордва/мордва бүгенге көндә яшәүче халыкның атамасы. *Булак/болак* – «чыганак канал» дигәнне аңлата.

Мөслим – гарәп. Ислам динендәге ир кешене аңлата.

Мукшы (Яңа, Иске) – мордва. Этнонимга нисбәтле.

Мулланур Вахитов – гарәп. *Мулла + нур.* Мулла – рухани, дин әһеле. Вахит – кеше исеме. Гарәп телендә *Вахит – Вахид* «бердәнбер, беренче бала» дигәнне аңлата.

Муллино, Татар Мулла Авылы, Муллин атамалары шулай ук *мулла* рухани титулына нисбәтле.

Нагай – монгол. Антропонимга нисбәтле. Исем монгол телендәге *нокай* «эт» сүзенә карый. Эт елында туган балага бирелгән булса кирәк.

Нарат-Елга – төрки-татар. Атама *нарат* һәм *елга* сүзләреннән тора. Елга буенда нарат агачлары үскәнгә шулай аталган.

Нариман – борынгы төрки. Антропонимга нисбәтле. Ул «көчле рухлы, кыю, батыр» дигәнне аңлата.

Норлат – борынгы төрки. Ойконим Нурдәүләт дигән кешенең исеменең фонетик үзгәреш кичерүе – икенче иҗеге «дәү»нең төшүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән.

Русская Менча. Менча – борынгы төрки. Борынгы төрки *Mencik* антропонимыннан.

Русская Чабаксарка – чуваш. Атама икенчел. Чабаксар шәһәре исеменнән алынган.

Русская Шибаши. Шибаши – татар. Шибаши атамасы Чиябашы атамасының диалекталь формасы булып тора. Чия елгасының башланган урынына урнашканга шулай аталган.

Русский Студенец. Атама татар теленнән алына. Татарча – Суыксу.

Ромодан – гарәп. Антропонимга нисбәтле. Ромадан/рамазан – ай календаре буенча тугызынчы ай исеме.

Рәҗәп – гарәп. Антропонимга нисбәтле. Мөселман ай календаре буенча җиденче ай.

Сабакайка – чуваш. Сабакай дигән мәҗүси чуваш исеменә нисбәтле.

Садыково – гарәп. Антропонимга нисбәтле. Гарәп телендә Садыйк «туры, дөрес, чын, эчкерсез» дигәнне аңлата.

Салдакай – чуваш. Мәҗүси чуваш Салтак исеменә мөнәсәбәтле. Чуваш телендә *салтак* сүзе «солдат» мәгънәсендә йөри.

Сарсаз (Рус, Татар) – фин-угыр-төрки. *Сар* сүзе мари телендә «саз» дигәнне аңлата. *Сар* + *саз* конструкциясе.

Саурыш (Иске, Түбән) – болгар-чуваш. Антропонимга нисбәтле. Саурыш (сауыш) – «савыгырга булыш, ярдәм ит».

Сихтермә (Новое) – чуваш. Чуваш телендәге *сихтерме* сүзе татар телендә *бишек* дигәнне аңлата.

Сөнчәле (Татар Сөнчәлесе) – татар. Атама татар телендәге Сөенечгали атамасының диалекталь формасы булган Сөнчәләй исеменә мөнәсәбәтле.

Суыксу (Татар Суыксуы) – борынгы төрки-татар. *Суык – салкын* + *су* сүзләре кушылып ясалган.

Сүлчәбаш – борынгы төрки-татар. Сүлчә елгасының башланган урынына утырганга шулай аталган.

Такталы – фарсы. Фарсыча *tahte* – «такта, калкан, күкрәк читлеге, тигез, яссы» мәгънәләрен бирә.

Талкыш (Олы, Кече, Урта, Татар) – төрки-болгар-татар-чуваш. Борынгы төрки телдә *talkis* – «волять войлок».

Тамкеевка, Тамино – борынгы төрки телдәге *tampaci* «ясак җыючы», *tompa* «печать, билге, тамга» сүзләренә нисбәтле.

Тарн-Вар – болгар-чуваш. *Тарн* – торна, *вар* – елга. Торна елгасы дигән сүз.

Тарханка – борынгы төрки. Борынгы төрки сословие титулыннан ясалган.

Ташбилге – борынгы төрки. Антропонимга нисбәтле.

Тигәнәле (Урта, Зур, Түбән) – татар. *Тигәнә* сүзе татар телендә бер бөтен агач кисәгеннән чокып ясалган озынча улак, савыт, тагарак мәгънәсен аңлата.

Тигән Бүләк – татар. Озак көткәннән соң туган балага кушыла.

Тирмән (Рус, Чуваш Тирмәннеге) – татар. *Тирмән* сүзе мишәр диалектының Чистай сөйләшендә тегермәнне аңлата. Бөртекле ашлыкларны ярма яки он итеп тарту өчен корылган.

Төгәлбай (Татар, Рус төгәлбае) – борынгы төрки. Антропонимнан ясалган.

Төрнәс – борынгы төрки. *Торна* + *яз* (кыр, рус. поле). Торна кыры, басуы.

Тубылгытау – болгар-татар. Тау өстенә салынган кальга-крепостьны, ягъни кала-шәһәрне белдерә.

Урал – борынгы төрки. Төрки телдәге *ура* «окружить» фигыленә нисбәтле.

Урмандәй – борынгы төрки-монгол. Атама географик терминнан ясалган. Бу термин белән Урманасты Шанталасы, Урманасты Йорткүл, Урманасты Үтәмеш атамалары ясалган.

Уткино – борынгы төрки. Үтәк антропонимына нисбәтле.

Утяково – борынгы төрки. Үтәк антропонимына нисбәтле.

Утяшкино (Татар Утяшкиносы) – борынгы төрки. *Үтәш* антропонимыннан ясалган.

Үргәагар (Яңа, Иске) – борынгы төрки. *Үргә* сүзе югарыга, өскә таба мәгънәсен бирсә, *агар* сүзе *ага* + *р* булып ясалып «суның югарыга таба агачагы» мәгънәсен бирә.

Үтәмеш (Урман асты, Иске) – борынгы төрки. Антропонимнан ясалган.

Чаллыбаш – болгар. Чаллы елгасының башланган урынына урнашкан авылга бирелгән.

Черемушка – рус. Авыл атамасы татар телендәге *шомырт* сүзеннән калька. Татарлар авылны Шомыртлы дип йөртәләр.

Чирмешән – борынгы төрки-болгар. Елга + елга конструкциясен тәшкил итә. *Чирме*/*чирмә* болгар телендә, *шән*/*шан*/*сан* борынгы төрки телдә елга дигәнне аңлата.

Чирүле Шонтала – борынгы төрки. Борынгы төрки телдәге *чирү* (гаскәр), *чирүле* сүзенә нисбәтле.

Чиябашы – борынгы төрки-татар. Чия елгасының башланган урынына утырганга шулай аталган.

Чуваш Кичүе – чуваш борынгы төрки. Этнонимга һәм борынгы төрки *кес* «кичеп чыгу, буа» сүзенә нисбәтле.

Чуваш Шәпкесе – чуваш. Этнонимга һәм Шапкин дигән мәҗүси чуваш исеменә нисбәтле.

Чулпан – борынгы төрки. Төрки Чулпан дигән кеше исеменә нигезләнгән.

Чурабатыр – борынгы төрки. *Чура + батыр.*

Чыгтай – монгол. Чагатай антропонимына нисбәтле.

Шахмай – фарсы-төрки. *Шаһ* һәм *май/бай* сүзләреннән тора.

Ширбәт – гарәп. Эчемлекне аңлата.

Шома – мордва. Атама мукшы телендәге *шома* (бит) сүзенә нисбәтле булган Шома кушаматыннан ясалган.

Шомыртлы – татар. Агачны аңлата.

Юган – болгар. Борынгы болгар Йупан этнонимына нисбәтле.

Юксыл – татар. Ярлы кешене аңлата. Авыл халкы аеруча ярлы булганга бирелгән.

Якушкино – гарәп-яһүди. Якуб антропонимыннан ясалган. Исем гарәп-яһүди Якуб исеменең диалекталь формасы. *Якуб* «ияреп баручы» дигәнне аңлата.

Ялаур – борынгы төрки. Борынгы телдә *jal* тамырына мөнәсәбәтле. Бу сүз «ташлы калкулык» мәгънәсен бирә.

Ялтан (Рус, Татар) – борынгы төрки. Борынгы телдәге *jal* тамырына мөнәсәбәтле (ташлы калкулык).

Ямбакты – борынгы төрки кеше исеменә нисбәтле.

Ямкино – борынгы төрки кеше исеменә нисбәтле.

Яңа Чишмә – фарсы. *Чишмә* фарсы телендә «күз яше» дигәнне аңлата.

Ясак – борынгы төрки. Алпавыт файдасына алына торган салымны аңлата.

Яуширмә – болгар. Атама Яуширмә дигән елгачык исеменнән алынган.

Яшәүче – татар. *Яшәү* фигыленә *-че* кушымчасы ялганып яшәүче исеме ясалган.

ЭЧТӘЛЕК

**Кереш** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
**1. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягының тарихи-географик үзенчәлекләре** . . . . . . . . . . . . . 9
1.1. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы территориясенә физик-географик характеристика . . . . . . . . 9
1.2. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы халкы этник составының формалашу тарихы . . . . . . . . . . . 11
**2. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы торак пункт атамаларының этнолингвистик катламнары** . . . . . . . 25
2.1. Төрки катлам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
2.1.1. Борынгы төрки катлам . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
2.1.2. Болгар теленә нисбәтле ойконимнар . . . . . . . . . . 57
2.1.3. Татар катламы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
2.1.4. Чуваш катламы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
2.1.5. Башкорт катламы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
2.2. Фин-угыр катламы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
2.3. Монгол катламы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
2.4. Гарәп-фарсы катламы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
2.5. Рус катламы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
**3. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы ойконимнарының структур-ясалыш калыплары** . . . . . . . . . . . 87
3.1 Лексик-семантик үзенчәлекләр . . . . . . . . . . . . . . 87
3.1.1. Апеллятив ойконимнар . . . . . . . . . . . . . . . . 88
3.1. Онимик ойконимнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
3.1.1. Антропонимнарга нисбәтле ойконимнар . . . . . . . . . 101
3.1.2. Этнонимнарга нисбәтле ойконимнар . . . . . . . . . . 118
3.1.3. Топонимнарга нисбәтле ойконимнар . . . . . . . . . . 122
3.2. Татарстанның Көнбатыш Кама аръягы ойконимиясенең структур-ясалыш үзенчәлекләре . . . . . . . . . 140
3.2.1. Гади төзелешле ойконимнар . . . . . . . . . . . . . . 141
3.2.2. Катлаулы төзелешкә ия ойконимнар . . . . . . . . . . 144
**Йомгак** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
**Кулланылган әдәбият исемлеге** . . . . . . . . . . . . . . 153
**Кушымта** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162

Научное издание

**Хисамов Олег Ришатович**

**ОЙКОНИМИЯ ЗАПАДНОГО ЗАКАМЬЯ ТАТАРСТАНА**
(на татарском языке)

Редактор *Я.М. Абдулкадырова*
Компьютерная верстка *Л.Ш. Давлетшиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Подписано в печать: 24.10.2017.
Печать офсетная. Гарнитура «Times».
Формат: 60×84 1/16.
Усл.-печ. л. 10,2. Уч.-изд. л. 7,34. Тираж 200 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

ООО "ТКС Контакт"
420021, Казань, ул. Г. Тукая, 91